1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН

№ 1 / 2023

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398


ӘЛФИЯ АВЗАЛОВА
хәтер-хатирә

«Z буын»
БАЛАЛАРЫ
алар нинди

Бурятия
күчтәнәче
ТАЙГА БӘЛЕШЕ

Сажидә
БАТТАЛОВА:
«Тамырларга кайтып, алга барам!»





СӨЕМБИКӘ

110

Елъязма

Без бүген: «Журналыбызны яратып, җан җылысын кушып эшлибез!» – дип кабатларга яратабыз. Алар, ягъни бездән алда килгәннәр дә шулай эшләгән... Араларында репрессияләргә дучар булганнар да бар... Төрмә салкынлыгы, гаделсезлекләр кичерүчеләр дә... Исемнәре аклану шатлыгын күтеп алучылар да... Журнал кызыклы, файдалы булсын, укучыны уй-гамьнәргә салсын дип иҗат газапларында янганнар... «Сөембикә» журналы битләре әнә шулай тарихка керә барган... Менә хәзер безгә шушы фотосурәтләрдән караучы шәхесләр аша «Сөембикә» бүгенге көнгә килеп җиткән. Кыйбласын да, максатларын да югалтмаган! Бу сәхифәбез – кайчандыр журналыбыз өчен җан атып яшәүчеләр хакында.

«Сөембикә»нең беренче саны чыгуга быел 110 ел була! 1913 елда ул нәкъ менә «Сөембикә» исеме белән нәшер ителә башлый, революциядән соң «Азат хатын» дип үзгәртелә, ә аннан соң кабат үз исеменә – асылына әйләнеп кайта.




Мәдинә Гайнетдинова. 1939–1941 елларда «Азат хатын» журналында хезмәткәр.



Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2023



Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

Баш мөхәррир
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зәлия Ахунова, Ирада Әюпова, Зилә Вәлиева, Гөлүсә Батталова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Альбина Насыйрова, Алсу Нәбиева, Сәрия Сабурская, Гүзәл Сәгыйтова, Нурия Һашимова, Рафаэль Шәвәлиев.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Баш мөхәррир урынбасарлары 222-09-78
Мәликә Әсәтуллина
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Алсу Шакирова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррире
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Рекламаның эчтәлеге (фото, текст) аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Тышлыкта:
Саҗидә Батталова
Фото: Анна Арахамия

Мөхәррирләр
Чулпан Галиәхмәтова
Лилия Гәрәева
Фәгыйлә Шакирова
Верстка
Резеда Галиуллина
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Фотокорреспондент
Анна Арахамия
Гамәли хезмәткәрләр
Ильмира Сөләйманова
Павел Фадеев

Формат: 225x290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 19.12.2022 ел.
Чыгу көне: 3.01.2023 ел.
Заказ О-3749
Тираж 7075

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы
ПАП рәсми каталогы буенча:
Татарстанда П2204 (ярты еллык),
П8299 (берьеллык)
Татарстаннан читтә: ПО279

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

16+



Баш мөхәррир сүзе



Кадерле укучым!

Бу юлларны укыйсың икән, димәк, яңа 2023 елга – журналыбыз чыга башлауга 110 ел туласы елга бергәләп кердек дигән сүз. Димәк, без тагын бергә!

Игътибар иткәнегез бармы икән: җәйге эссе көннәрдә ялгыз үсеп утырган агачларның яфраклары эсселектән шәлперәеп кала, ә менә урманда алар ямь-яшел булып утыра. Сәбәбе бик гади: урманда, паркта алар күп, агачлар анда бер-берсенең күләгәсендә – ышыкта. Без дә бергә булыйк, бердәм булыйк!.. Һәм бер-беребезгә җылы сүзләр, якты карашыбызны, ягымлы елмаюларыбызны җәлләмик. Бу уңайдан озак еллар редакциябездә эшләп киткән журналист Фәния Сабирова белән булган бер сөйләшү искә төште. «Елмаю савап икән ул. Мин хәзер гел елмаям. Иремне эштән елмаеп каршы алам. Гаҗәпләнә: «Сиңа нәрсә булды?» – ди. Елмаерга кирәк! Ире – хатынына, хатыны – иренә, килене – кайнанасына, кайнана килененә елмайсын иде. Гомумән, бөтен кешегә – күршеләргә, урамда яныңнан узып баручыларга – барысына елмаерга кирәк», – ди ул.

Яраткан персонажым барон Мюнхгаузен сүзләре искә төшә: «Җитди йөз ул әле акыл билгесе түгел... Елмаегыз, җәмәгать, елмаегыз!»

Матур киңәш!

Яратып, Лариса МАЛИКОВА




Безнең тышлыкта

«Кая гына яшәсәк тә, без, татарлар, күңелебез белән гел Татарстанда. Аның казанышлары – безнең зур куанычыбыз, аның җиңүләре – безнең дә горурлыгыбыз!»

10

Тауларны күчереп була!
Алсу Шакирова

6



Кризис үсешкә китерә
Чулпан Галиәхмәтова

14



Кайсы халыктан, дисәләр...
Ләйсән Сафина

22



Татар дөньясы

Казыклар
Алсу Шакирова

ЭЧТӘЛЕК

Заман һәм без

Фоторепортаж. «Могҗиза дәвам итә» 9
Чулпан Галиәхмәтова

Китап уку – үзең белән сөйләшү ул 17

Икс, игрек һәм зет 18
Лилия Гәрәева

Мәдәни тормыш

Сагынасым килми... сагынам! 30
Флёра Шәрипова

Фоторепортаж. «Борынгыдан килгән гадәт ул...» 32

Кунак мунчасы 34
Дилбәр Булатова

Яшәеш

Коңгырт күзле кызый 46
Гөлнур Сафиуллина

«Исәнме, Ана-Тау!» 50
Мөнирә Сәгыйдуллина

«Тормышны бергә тартсаң җиңелрәк» 54
Гөлнур Сафиуллина

Хуҗабикә

Сорау–җавап 56

Телефоннан сөйләшү этикеты 58

Каллиграфия – хәятемнең бер өлеше 64
Зилә Нигъмәтуллина

26




Ничек түзәрбез соң сагынмый?
Эльмира Закирова

40



Таңда исеп куя җил
Асия Юнысова

60



Тайга бәлеше
Лариса Сәхиева тәкъдим итә

»



КРИЗИС ҮСЕШКӘ КИТЕРӘ



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

Киләчәккә кемдер өметләнеп, кемдер, киресенчә, хәвефләнеп карый. Бигрәк тә хәзер, дөньялар тынгысыз чакта. Күп вакыт безне нәрсә көтә дигән риторик сорау куябыз. Ә бәлки, сынауларга бирешмәс өчен, «мин нинди булырга тиеш» дигән сорау кую дөресрәктер. Геополитик вазгыятьне үзгәртү безнең кулдан килми, ә менә якыннарыбызны бәхетле итү, өйдә җылылык саклау турыдан-туры безгә – хатын-кызларга бәйле. Күңел тынычлыгын ничек саклап калырга? Гомумән, тормыштагы үзгәрешләргә ничек карарга? Бу хакта җәмгыять җитешсезлекләренең тамырын анализлап, аларны бетерү алымнарын өйрәнгән Россия галим-психологы һәм психотерапевты, дистәдән артык китаплар чыгарган, язучы, публицист, иҗади проектлар авторы, актив гражданлык позициясе булган КФУның психология һәм мәгариф институты доценты, психология фәннәре кандидаты, республиканың атказанган мәдәният хезмәткәре Рамил ГАРИФУЛЛИН белән сөйләштек.

Рамил Рәмзиевич, кешеләр Яңа елда бер-берсенә яңа бәхет, яңа шатлыклар тели. Кайберәүләр яңа елдан яңа тормыш башлануына чын күңелдән ышана. Бу нәрсә белән бәйле икән?

– Минем уйлавымча, бу иҗади фикерләү белән бәйле. Җәмгыятьтә иҗади фикер йөртеп яшәүчеләр күп түгел. Менә шундыйлар могҗизаны ниндидер бәйрәм, әйтик, Яңа ел белән бәйли. Ә иҗади, мәсәлән, Аня (редакция фотографы Анна Арахамия – *Ч. Г.*) кебек кешеләр өчен могҗиза һәр көн туа, алар аны һәр көн күрә һәм соклана белә. Шуңа да Яңа елда могҗиза көтеп утырмыйлар, чөнки могҗизада яши. Һәм бу бик шәп!

Психотерапевт буларак сезнең үз күзәтүләрегез бардыр. Гадәттә, кешеләр ничә яшьтә тормышларын тамырдан үзгәртергә тели?

– Тормышларын гына үзгәртергә теләсәләр, рәхмәт, кайберәүләр шәхесләрен үзгәртергә тели әле. Ә шәхесне һич тә үзгәртергә ярамый. Миссиябез бозылачак. Тормышны үзгәртергә теләү билгеле бер яшь белән бәйле түгел. Гадәттә, ниндидер кризис вакытында үзгәрешләр килеп туа. Шәхсән үземдә дә шулай булды. Әгәр дә кеше һәрвакыт шат күңелле, анда берниндн күңел төшенкелеге, депрессия булмый икән, ул үзгәрми, үсештә дә була алмый. Күңел төшенкелеге үз-үзеңә карата канәгатьсезлек, тормыштагы кыйммәтләрнең шатландырмавы белән бәйле. Ә яңа кыйммәтләр әле юк. Бу халәт кризис дип атала да инде. «Режиссёр мозга» дигән кино чыкты минем. Бик озак һәм бик авырдан төшердем. Сценарийны үзем яздым, төп рольдә уйнадым. Нигә бу фильмга алындым икән дигән сорауны куйдым һәм җавабын да таптым: миндә рухи кризис. Ул вакытта диссертация якланган, фәндә инде казанышларым күп иде, әдәби хикәяләрем дә чыкты. Тормышымда бушлык барлыкка килде. Мин ул чакта бик интектем. Медицина психологиясеннән Мәдәният һәм сәнгать институтына киттем. Булачак режиссёрлар, актёрлар белән аралаша башладым. Ул минем үз психотерапиям булды. Кино сәнгате белән шөгыльләнү мине коткарды. Тормышны үзгәртә алу минем өчен бөек кыйммәт. Эшчәнлекләрен үзгәртергә көч тапкан кешеләрнең кулларын кысам. Үзгәрүдән курыкмаганнар гына алга бара бит! (Аняга мөрәҗәгать итеп. – *Ч. Г.*) Менә сез, Аня, фотографиягә нинди сферадан килдегез?

– Химия технологиясе өлкәсеннән.

– Күрдегезме! Ә мин психологиягә физика өлкәсеннән килдем. Юк, бу хәзерге психологлар кебек психологик проблемаларымны хәл итү максатыннан күчү түгел иде, ул вакытта психология буенча лекторларга җәмәгать линиясе буенча күп түлиләр иде. Яңа тормыш ихтыяр көченнән башлана, чөнки өйрәнелмәгән кырга кереп, аны үзләштерү зур көч сорый. Журнал укучыларына да әйтәсем килә, үзгәрешләрдән курыкмагыз! Яңа белемнәр үзләштерегез, беркемне тыңламагыз, якыннарыгызны гаҗәпләндерегез. Әмма бер нәрсәдә ялгышмагыз: яңа тормыш хатын йә ир алыштырудан түгел, ә яңа эшчәнлек үзләштерүдән башлана.

Олыгаю кризисын җиңеп, картаюны ничек кабул итәргә?

– Бернәрсә эшләми кул кушырып утырырга да була. Монысы – бер алым. Ә мин икенче алым яклы. «Шәхес иллюзиясе» дигән китабым бар. Анда нәкъ менә шушы темага кагылышлы мәсьәлә күтәрелгән. Хайваннардан без акыл эшчәнлеге, иллюзияләр кора белүебез белән аерылабыз. Кешеләр иллюзияләр белән үз-үзен яклый. Мин ышанам: талантлы кеше иллюзияләре нигезендә үзенә канат куя, әллә ниләр уйлап чыгара ала. Көчле кешеләр соңга кадәр очып, очышта якты дөнья белән хушлаша. Бу бик лаеклы кешеләр. Минем әти шундый иде. Әтием Рәмзи Гарифуллин – театр училищесының беренче чыгарылыштагы актёры. «Мин сәхнәдә үләчәкмен», – дип әйтә торган иде ул. Шулай булды да. Сәхнәдә уйнап чыкты да, китеп барды. Бервакытта да үзен җәлләмәде, сузылып ятып үлем көтмәде. Австрия психиатры Виктор Франкл фашистлар концлагеренда тоткыннарның газ камерасы алдында үзләрен ничек тотуларын күзәткән. Аның бу хакта бик шәп китабы да бар. Иң соңга кадәр иллюзияләр белән яшәүчеләр дә, газ камерасына керүдән куркып үлеп китүчеләр дә булган. Өметен югалтмаган, ниндидер иллюзияләр корырга сәләтле кешеләр исән калган. Виктор Франкл – үзе шундыйлардан. Андый кешеләргә язмыш елмаймый калмый ул. Ә инде картайганда тышкы кыяфәтләрен кабул итә алмаучыларга шуны әйтер идем: тышкы кыяфәт декорация генә ул. Вакыт үткән саен, декорацияләр кызыксындырмый башлый. Миңа да 60 яшь тулды. Әмма үз яшемне сизмим әле. Көн саен 10 чакрым йөгерәм, актив баш мие эшчәнлеге алып барам. Мин – укучы. Ә укучы булып яшәп, һәрвакыт белемгә, дөнья танырга сусаган кеше картаймый ул. Өлкән яшьтәге әбибабайларның төрле лекцияләргә йөрүенә, ниндидер яңа шөгыль үзләштерүләренә бик шатланам. Телевизор алдында үлем көтеп утырмыйлар, яшиләр бит! Искиткеч кешеләр!

Узган ел бик борчулы булды. Күпләрнең тормышы тамырдан үзгәрде, кемдер якыннарын югалтты. Халыкта күңел тынычлыгы югалды. Илгә килгән хәсрәт өйдәгесенә караганда авыррак бит әле ул. Сабыр итәргә, өмет-ышанычны югалтмаска кирәген дә аңлыйбыз. Борчуга күмелеп, депрессиягә бирелмәс өчен, белгеч буларак нинди киңәш бирә аласыз?

– Иң элек борчылуыгызның нәкъ менә шушы вазгыять белән бәйлеме-түгелме икәнен аңлагыз. Холкы буенча үтә хафалы кешеләр дә була бит әле. Андыйларга бары тик белгечләр генә ярдәм итә ала.

Фото: Анна Арахамия



Әгәр дә инде борчылулар нәкъ менә дөньяда барган хәлләр белән бәйле икән, бер генә киңәш әйтә алам: һөнәри эшчәнлегегез активлыгын киметмәгез. Һәрвакыт эштә кайнагыз, баш мие эшчәнлеге актив булсын. Эш белән мавыгу – иң яхшысы булыр. Җәмгыятькә файдалы кеше булырга тырышыгыз. Мин ничек ярдәм итә алам дип уйлагыз. Шушы урында, шушы минутта! Сезне куркыткан образ каршына барыгыз. Без бит нәрсәнедер күз алдына китерәбез һәм шуннан куркып йөрибез. Бу әлеге образга төрле яклап, «якыннан» карагыз – курку кимиячәк. Бу – психология кануны. Аннан соң даими рәвештә борчу тудырган чыганакны табарга тырышыгыз. Бәлки, ул телевизордыр, бәлки, мессенджерлардагы төркемнәрдер, бәлки, аралашкан берәр кешегездер. Алардан ераграк торырга тырышыгыз. Әгәр аңлы рәвештә моны эшләргә теләмисез икән, димәк, сез, гафу итегез, садомазохист: борчулы хәбәрләр тыңлап, хәвефләнеп, ниндидер бер рәхәтлек аласыз. Юрган астыннан карап ләззәтләнү дип атыйм мин моны. Кызганыч, күпләр шулай яшәүчән. Бу кешеләргә берничек тә ярдәм итеп булмый, чөнки яшәү рәвешләре шундый. Сезнең аң белән идарә итәргә теләгән коллектив Көнбатыш хезмәтчеләренең курчаклары булмагыз. Гомумән, интернеттан төрле сәхифәләр укып утырганчы, тарих, классик әдәбият белән кызыксыныгыз. Анда сорауларыгызга җавап таба алырсыз.

Әйе, хәзер чынлап та мәгълүмат агымы бик зур. Бик нык сайлап, анализлап укырга кирәк. Ә күпчелек нигәдер негатив мәгълүматны үз итә, шуны гына эзли...

– Бу психологик установкалар белән бәйле. Психологиядә шундый төшенчә бар. Установка, гади итеп кенә әйткәндә, билгеле бер нәрсәне көтү, өмет итү дигән сүз ул. Без дөньяга көтү призмасы аша карыйбыз. Менә хәзер мин Аняга карыйм һәм үзем күрергә теләгәнне генә күрәм. Аны кемгәдер охшатам, чагыштырам. Кешеләрне, әйберләрне, хәбәрләрне берьяклырак, ягъни субъективизм аша кабул итәбез. Өмет ихтыяҗларыбыздан чыгып формалаша. Әгәр дә кеше бары начарлык кына көтә һәм күрә икән, нинди генә яхшы хәбәр укыса да, аны кирегә борачак. Позитив кешеләр, белгәнегезчә, исән булса, чыгу юлы булмаган хәлдән дә чыга ала. Шуны әйтергә телим: тирәягының нинди булуы кешенең үзеннән тора. Безнең установкалар психик хәләтебезгә турыдан-туры бәйле. Мәсәлән, кеше депрессиягә китүчән икән, ул дөньяны бары негатив хисләр аша гына кабул итә. Шуңа күрә дә бар нәрсәдән кара төсмерләр эзли. Һәм, киресенчә, оптимизм белән яшәүчеләр һәрвакыт позитив кына күрә. Бу – кешенең психофизиологиясе, аны үзгәртеп булмый. Алайса психологлар нигә кирәк соң, дип сорарсыз. Без кешенең асылын бары «төзәткәләп» кенә алырга мөмкинбез. Психологлар программист кебек ул. Программист та бит компьютерны үзгәртә алмый, машинаның мөмкинлекләреннән чыгып кына эшли.

Узган ел күпләрнең тормыш кыйммәтләре үзгәрде. Гаилә кыйммәтләренә игътибар артты кебек. Гомумән, иң төп терәгебез гаилә булды. Килешәсезме?

– Әйе, сез хаклы. Махсус хәрби операция башлангач, кыйммәтләр үзгәрде. Кеше шундук гаиләсенә елышты. Якыннарын югалтырга мөмкин бит, аннан соң киләчәк образы да үзгәрде. Киләчәк якты булганда гына кеше бәхетле яши ала. Кеше психологиясе шулай төзелгән инде. Депрессиягә китмәс өчен үз-үзебезне рухландырырга тырышабыз, әлбәттә. Бәяләмәгән кыйммәтләрне бәяли башладык. Шәфкатьлелек, кешелеклелек сыйфатлары калкып чыкты. Ә тормышта иң зур кыйммәт – ул гаилә! Ялгыз эчкечеләр белән эшләве авыр, алар нәрсәгә дәваланганнарын аңламый. «Нәрсәгә аек тормыш алып барырга инде?» – диләр. Чын бәхет бары гаиләдә генә була ала. Чын, бәхетле яратышу да гаиләдә генә, каядыр читтә түгел. Читкә йөрүдән кеше тиз туя ул. Андыйлар тормышы тоташ газап кына. Бигрәк тә ирләр өчен. Без, ир-атлар, бары тик гаиләдә генә бәхетле була алабыз. Статистика буенча, гаилә белән яшәгән ирләрнең, ялгызларга караганда, гомерләре озынрак. Шунысы да кызык: ялгыз хатыннарга бу кагылмый. Алар арасында озын гомерлеләр бар. Шәхсән үзем хатынымнан уңдым. Гомумән, хатын-кызларга сокланам мин. Аларның бик шәп бер сәләтләре бар – мәхәббәтне үстерә беләләр. Күп хатын-кызлар башта кияүгә чыга, аннан соң гына иренә гашыйк була. Бу бит уникаль сәләт. Ир-атлар менә андый түгел. Алар башта гашыйк була, аннан соң гына өйләнү турында уйлый. Ә хатын-кызларның бу искиткеч мөмкинлеге кешелекне тотып тора дип әйтер идем. Гомумән, кешелекне хатын-кыз яшәтә! Әлбәттә, ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләр җитлеккән булырга тиеш. Шул вакытта гына матур тормыш кора аласың. Мондый мөнәсәбәтләрне менә ничек тикшереп була: каядыр барасың һәм янында булуын, син күргәнне аның да күрүен телисең.

Рамил Рәмзиевич, узган ел сезнең юбилей елыгыз иде. 60 яшь тулды. Ир-ат өчен 60 яшь нинди ул? Тормыш кыйммәтләре, дөньяга караш үзгәрәме?

– Юк, кисәк кенә берни үзгәрми. 60 яшь – артка карап нәтиҗәләр чыгару яше дә түгел ул. Хәер, нәтиҗәләрне ел саен ясыйм. (Ул калын блокнотын ачып күрсәтә. Анда ел дәвамында нәрсә эшләнгәне, нинди уңышлар казанганы, пунктларга бүлеп, бөртекләп саналган. – *Ч. Г.*) Шуны әйтер идем, соңгы елларда интеллектуаль мөмкинлекләрем куәтләнде. Хәзер бик нәтиҗәле эшлим. Фән белән дә шөгыльләнәм, федераль газетада күзәтүләр дә алып барам, китап язам, кино төшерәм. Кыскасы, профессиональ формада мин. Күрәсең, 60 яшь – эшләү өчен оптималь яшь. Гомер юлының биек ноктасы дип атар идем. Әле картлык деградациясе юк, ә тупланган тәҗрибә җитәрлек. Озаккарак сузылсын иде ул. Минем әле иҗади амбицияләрем җитәрлек. Үземнән канәгать түгелмен, һәм бу бик яхшы. Димәк, алга барырга стимул бар, үсеш булачак. Очышта яшәргә иде әле.

Мәрхәмәткә – мәрхәбә

МОГҖИЗА ДӘВАМ ИТӘ

Укыгансыздыр, декабрь санныбызда «Могҗиза» дип аталган язма чыкты. Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында мөмкинлекләре чикләнгән һәм Даун синдромлы балалар өчен «Могҗиза» татар театры студиясенә багышланган иде ул. Тырыш, талантлы балаларга сокланып кайттык без. Аларны куандыру теләге туды. Яңа ел бәйрәме алды – могҗизалар чоры бит. Ә балалар өчен ул аеруча бәхетле, серле вакыт. Һәр баланың Кыш бабайдан нәрсә көтүе турында сер итеп кенә белештек тә, бүләкләр әзерләргә булдык.

Ел ахырында студиянең ачык дәресе узды. Анда балалар ничек шөгыльләнгәннәрен, үз талантларын күрсәтте. Әмир, Айрат, Карина, Әлфия шигырь сөйләгәндә, «кояш кызы» Лиза биегәндә, Анель җырлаганда тамашачы кунаклар күз яшьләрен тыя алмады. Ул минутта күңелләр пакьләнеп киткәндәй булды. Бәйрәмгә килгән Дәүләт Советының Социаль сәясәт буенча комитет рәисе Светлана Захарова түзмәде, балаларны кочаклап ук алды. «Сез көчле һәм талантлы балалар. Чын-чынлап сокландырдыгыз», – диде баш мөхәрриребез Лариса Маликова. Алып килгән бүләкләребезгә бик куанды балалар. Кечкенә хыяллары чынга ашты бит! Сабыйлар сөенечен, бигрәк тә үзенчәлекле балаларныкын күрү – үзе бер куаныч. Кечкенә артистларның хыялларын чынга ашыруда журналыбызның дуслары – иганәчеләребез шәхсән ярдәм күрсәтте. Олы йөрәкле җитәкчеләребез, эшмәкәрләребез булганда дөньяда мәрхәмәтлелек артмый калмый.

Балаларны шатландырырга ярдәм итүчеләр:

- Татарстан Республикасы Финанс министры Радик Гайзатуллин;
- Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, «Татэнергосбыт» АҖ директоры Рифнур Сөләйманов;
- Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, «Бала-Сити» мәктәбе директоры Альбина Насыйрова;
- Росприроднадзор федераль хезмәтенең Идел-Чулман төбәкара идарәсе башлыгы Фаяз Шакиров;
- «ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры Шамил Садыйков;
- Идел буе физик культура, спорт һәм туристлык дәүләт университеты ректоры Рафис Борһанов;
- «Сельхозснаб-Киндери» компаниясенең Директорлар Советы рәисе Фәнис Гатин;
- «Ак барс» банк ААҖ Идарәсе рәисе Зөфәр Гәрәев;
- Татарстанның атказанган артисты Данир Сабиров;
- шәхси эшмәкәрләр Илүсә һәм Марсель Низаметдиновлар;
- шәхси эшмәкәр Илсур Юнысов.

Журнал битләре аша иганәчеләребезгә тагын бер кат зур рәхмәтебезне юллыйбыз.



Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз. Фото: Анна Арахамия



ТАУЛАРНЫ КҮЧЕРЕП БУЛА!





Алсу ШАКИРОВА

«Алга – тамырларга барам, дисәм, тамырлар артта бит, диләр миңа. Ә мин тамырларым аша гына алга бара алганымны аңладым. Бөтен барлыгыбыз, байлыгыбыз, киләчәгебез тамырларыбызга бәйләнгән. Татарлар азлап яшәгән төбәктә эшләп, мин моны төгәл беләм!»
Педагогика фәннәре кандидаты, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Россиянең Халыклар ассамблеясе советы әгъзасы, Бурятия татарларының төбәк милли-мәдәни автономиясе рәисе, Бурятия халыклары ассоциациясе рәисе Саҗидә БАТТАЛОВАны Бурятия Республикасында яшәүче татарлар гына түгел, башка халыклар да «безнең Саҗидә Рәстәмовна» дип үз итәләр. Бу татар кызының чанасына утырсаң, төшеп калмаячакларын аңлыйлар...

Әтием токмачлары

– Байкал күлен кочагына алып тибрәтүче бу төбәккә татарлар 1930–1950 елларда килеп төпләнгән. Минем нәсел тамырларым Татарстанның Буа районы Янтуган авылына барып тоташа. 30 нчы елларда Мөхетдин бабабызны кулак дип, Себергә – Байкал артына алтын прискларына сөрәләр. (Бу хакта тулырак алдагы санда яздык. – *Авт.*) Алар белән уллары Шиһап, килене Халисә, әле яңа гына туган беренче оныклары Расихны да эшелонга төяп, Итака поселениесенә сөрәләр. «Безгә мондый сынау бирелгән икән, димәк, аны күтәрә алырлык көч тә бар бездә», – дигән Мөхетдин бабай. Бары тик 1953 елда, Сталинның вафатыннан соң гына, аларга поселениедән күчеп китәргә рөхсәт бирәләр. Туган якларына кире әйләнеп кайтмыйлар. Нигә шулай хәл иткәннәрдер, билгесез... Кызганыч, бу хәлләрне инде Шиһап бабай да, Халисә әбием дә вафат булгач кына белдек. Шулкадәр гыйлемле, диндар, шул ук вакытта сәясәтне белүче акыллы карчык иде әбиебез!

Без бәләкәй чакта еш кына аларда кунакка җыела идек. Әти-әниләребез иркенләп, рәхәтләнеп татарча сөйләшә, көлешәләр. Батталовларның ниндидер бер үзләренә хас юмор хисе бар иде. Бер-берсенә төртмәле сүзләр әйтеп, шаяртып алалар. Аннары Илһам Шакиров, Әлфия Афзалова, Фәридә Кудашева пластинкаларын тыңлыйбыз, алар кушылып җырлыйлар. Елыйлар... Мин дә, төрле татар көйләре табып, фортепианода уйнап күрсәтәм. И куаналар! Тагын бер генә уйна әле, дип, кабат-кабат сорыйлар. Безгә сиздермәскә тырышып, эчтән генә сагыну сагышында яну булган ул. Мин моны соңыннан, гаиләбезнең тарихын белгәч кенә аңлый башладым... Ул әти белән урманга чыгып китүләр! Әти безне дә,

туганнарын да җыеп тайгага алып барырга ярата иде. Алар тайга белән бер телдә сөйләшәләр, аның белән бергә сулыйлар кебек. Җиләкне соскыч белән ничек оста җыйганнарын күрсәгез! Ләкин берсе дә Халисә әби белән узыша алмый. Әби ике куллап җыеп, чиләген иң беренче тутыра. Бер җиләкне дә авызына капмый. Бу – «тегендә», сөргендә чакта кереп калган гадәте. Һәр бөртеге исәптә булган... Балаларын да табигать белән бер булырга, аның нигъмәтләрен кулланырга өйрәткән. Әтиләребез – бертуган Батталовлар бер дигән балыкчылар! Фәим абый белән әти Бурятиянең атказанган машина йөртүчеләре. Республикага килгән зур кунакларны әтигә утыртып җибәрә торган булганнар. Тайгада ял иттереп, балык тотып – сыйлап озаткан әти. Халисә әби улларын өй эшләренә дә өйрәтеп үстергән. Лагман, пылау дисеңме – искиткеч пешерәләр! Тотып кайткан балыкларын һәрвакыт бары тик үзләре чистарта. Ә токмач кисүләрен карап торсаң, күзләр камаша! «Токмач-баттл» бәйгесенең тамырлары да шул балачагыма барып тоташа. Байкал Сабан туенда кызлар иң нәзек токмач кисү буенча ярыша хәзер бездә. «Тук, так, тукыран / Тукылдатып утырам. / Кайчан токмач китерәсең, / Шуны көтеп утырам!» дип, такмаклап та торабыз. Анысы да – балачактан...



«Төрле программалар, проектлар ярдәмендә тарихи ватаныбыз белән бергә атлыйбыз, бердәм һәм нәтиҗәле эшлибез. Читтә яшәп тә, Рөстәм Нургалиевичның әтиләрчә кайгыртуын тоябыз».

Фото: шәхси архивтан.

Димәк, без сезгә киләбез!

Хәзер Бурятиядә яшәүче татарлар халык саны буенча өченче урында торалар. Ел саен исәпне күзәтеп барам. Артабыз! Менә соңгы ел эчендә генә дә йөз кешегә артканбыз. Милләттәшләребезнең күбесе Бурятиягә 1937–1953 елларда, Бөтенсоюз күченү программасы буенча килеп төпләнгәннәр. 20 000 тирәсе татар килә монда. Тырыш, эшчән булганнары өчен бу төбәктә татарларны көтеп, хәтта махсус соратып алганнар. Бик җылы каршылаганнар! Йорт салырга булышканнар, сыер биргәннәр, биш елга салымнардан азат иткәннәр. Татарларның компактлы яшәү урыннарында ассимиляциядән, ягъни милләтләрнең кушылуыннан, кызганыч, качып булмаган. Бурятиядә җирләр бик күп, шул сәбәпле, авыллар да бер-берсеннән ерак. Татар кызына өйләнер өчен барып җитеп кара күрше авылга! Бергә күчеп килгән гаиләләр балаларын кавыштырырга тырышса да, яңа буын туган саен, бу мәсьәлә кискенләшә. Катнаш гаиләләр барлыкка килә. Бурят, татар, рус гаиләләре кушыла. Тайга уртасында җәелеп ятучы Тэгда авылында аның үзенә күрә бер атамасы да бар – БТР диләр, шаяртып.

Бурятия Республикасының татар милли мәдәни үзәге 1997 елда төзелгән. 2004 елда үзәккә мин килдем. 2005 елда автономия төзеп, июнь аенда беренче республика Сабан туе уздырдык. Без бәйрәмне Улан-Удэ шәһәрендә түгел, башкаладан ике йөз чакрым тирәсе ераклыкта урнашкан Харашибирь авылына алып бардык. Нигә алай ерак йөрисез, дип сорыйлар. Авылларда яшәүче татарларның күбесе шәһәргә барыбер килеп җитмәячәк. Ә минем мөмкин кадәр күбрәк кешегә үзенең татар булуын искә төшертәсем килә! Күбрәк кеше күрсен, татарлар үзләре генә түгел, авылдашлары, күршеләре дә татарларның кем икәнен белсен, дим. Нинди генә уеннар уйнатмадык, ат чабышына кадәр оештырдык. Милли мәдәниятkә баштанаяк чуму булды ул. Бәйрәмнән соң яныбызга килеп, онытылган туган телләрендә, татар телендә рәхмәт әйттеләр безгә! Елый-елый рәхмәт әйттеләр... Димәк, максатыбызга ирештек, уята алдык. Алар инде башка кешеләр иде. Үзләренең мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, җырларын, моңнарын, телләрен сагынып яшәүче икенче кешеләр... Уңдырышлы җирдә орлык та тамырны тиз җибәрә. Бу авылда, бу районда алга таба эшләр өчен җирлек әзер, димәк. Әҗерен соңыннан күрдек без моның: авылда «Харашибирь – иртәнге тургайлар җире» бренды үсеш алды, «Тургай» балалар мәйданчыгы ачылды. Сабантуй узган һәр авылда фольклор коллективлары, якшәмбе мәктәпләре, музейлар бар хәзер.

Шул ук җәйне 2005 елда үз гомеремдә беренче мәртәбә Казанга килдем. Казанның меңьеллыгына очраклы гына эләктек кебек ул вакытта. Инде исемлекләр тупланганнан соң гына безне – Бурятия Республикасы делегациясен иң соңгылардан булып теркәделәр. Хәзер шул чакларга кайтып уйлыйм – вакыты җиткән булгандыр. Асылыма кайтыр вакытым. Әти-әниләр вафатыннан соң бушап калган дөньям яңадан тулылана башлады. Барысы да үз урынына басты. Очып килеп кердем мин татар мохитенә. Колшәриф мәчетенең ачылышы, бөтен дөньядан җыелган милләттәшләр, никадәр вакыйга, очрашулар, дуслашулар! Шул елны иманыма кайттым... Һәм үз гомеремдә беренче тапкыр уразаны ай буе тоттым...

Быел Автономия төзүгә 25 ел булды. Ничек башлаганыбызны искә алам да, горурланам – Бурятиядә Татарстан Президентын каршы алуга ирештек бит! Милли мәдәниятне үстерү юнәлешендә кырыктан артык грант оттык!

Әтиләр юлы белән

Юл – минем өчен әти ул. Ерак юлларга чыгарга яратам. Бигрәк тә тайга якларына. Әти безгә урманда булган бер генә үзгәрешне дә күрсәтмичә калмый иде. Бөрлегән, чикләвек, мүк җиләге өлгерәме, каеннарның суы җитешәме, байгөл чәчәк атамы – барысын да күреп үстем. Зур кунакларны тайгага алып барганда кайвакыт мине дә



■ «Барган җирдән яңа бренд идеясе белән кайту бер күркәм традициягә әйләнде инде. Һәр брендны логотип, үзенчәлекле сувенир, мәгънәле аңлатма белән баетабыз».

иярттә иде әти. Арткы утыргычта утырып, күзем белән тәрәзә аша ачыла барган табигатьне «ашыйм»... Нәселебез тарихы белән таныштыручы «Янтуган – байгөл чәчәк аткан таулар» исемле гаилә брендры да этнотур кысаларында эшли бүген.

Сабантуйларны әле дә татарлар яшәгән авылларда оештырабыз. Традицияләрне авыл саклый. Шуңа күрә үсеш нокталарын дөрес билгеләү зарур. Унбиш Байкал Сабан туе уздырдык инде! Гомумән, Сабантуй бәйрәме – үзебезне таныту өчен иң үтемле һәм көчле чара. Тэгда авылында бер гаилә яши – алда искә алган БТР гаиләсенең гадәти моделе. Илнур исемле дүрт яшьлек малайдан: «Ә син милләтең буенча кем соң?» – дип сорадым «Мин – Россия», – дип җавап бирде бала, ул инде катнаш гаиләдә үзенең кем булырга тиешлеген дә аңламый иде кебек. Әйе, күпмилләтле Россиянең бик ачык мисалы бер гаиләдә чагыла. Бер Сабантуйда мин Илнур турында сәхнәдән сөйләдем, баланың шулкадәр тирән җавабы мине, галимәне, шулкадәр сокландырган иде. Бер елдан бу гаилә белән яңадан очраштым. Илнур миңа, беләсезме, нәрсә диде? «Мин – татар!» Баксаң, ул Сабантуйга килгән, беренче рәттә утырган икән. Һәм ул үзенең күпмилләтле гаиләдә үсеп тә, үзенең татар булуы белән горурлана хәзер! Ул үзен тапкан!

Бөтен дөнья белсен әле!

Һәр төбәкнең брендры, үзенчәлеге, аерылып торган имиджы булырга тиеш. Без нигә бу урында яшибез, нигә бу җиргә ябышып ятабыз? Шул матурлыкны, уникальлекне күрсәтә белсәк, уңышка ирешәсебез бәхәссез.

Методика, план, максат төшенчәләре миңа кечкенәдән сеңгән. Әнием үзе инглиз теле укытучысы. Минем укытучы белеме алуыма каршы булса да, бәләкәй чактан ук аның балалар тәрбияләү буенча эш китапларын укып үскәнемне исәпкә алмаган, күрәсең.

Усть-Кяхта авылында бер очрашу вакытында авыл советы башлыгы һәм депутат – милләтләре буенча берсе бурят, берсе рус – миннән ярдәм сорадылар. «Безнең шулкадәр яхшы татарларыбыз бар. Алар турында сөйлисебез, ишеттерәсебез килә. Алар үз телләрендә сөйләшсеннәр, милли киемнәрен кисеннәр, мәдәниятләренә кайтсыннар иде», – диделәр. Шулкадәр күңелемә тиде бу сүзләр. Очрашу хакында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановка сөйләдем. Әлбәттә, ул да битараф калмады. Татарстан ярдәме белән Усть-Кяхта авылында «Алмагачлар» татар милли үзәге төзелде. 40 сантиметрлы иң затлы нарат бүрәнәләреннән агач йорт күтәреп, татар йорты музее булдырдык. Ә капкалары – Байкал күле төсендә! Моны тулысынча Татарстанның матди ярдәме белән башкарып чыктык. Җирле халык бу эшләрнең кыйммәтен бик яхшы аңлый. «Без хәзер татарларга ярдәм итсәк, алар безгә булышачак», – диләр. Мәктәптә ачылган Туган тел кабинеты – шулай ук Татарстан бүләге. Укучылар бурят телен дә, татар телен дә өйрәнәләр анда. Шулай эшләгәндә авыл да, туган тел дә бетмәячәк. Бөтен авыл халкы үз татарларына киеем тегү өчен акча җыйды... Сабантуй уздырганда депутат Наталья Яковлевна район буйлап яшәүче бөтен авылларны йөреп чыкты, татарларның исемлеген төзеде, һәммәсен Сабантуйга чакырды. Авылның тагын бер үзенчәлекле ягы бар. 50 нче елларда монда күченеп килгән татарлар үзләре белән бер мең төп алмагач үсентесе алып килеп, бакча утырткан булганнар. Ул бакча сакланмаган. Хәзер авылдашлар барысы бергә җыелып, алма бакчасын яңадан утырттылар. Татарстанның вице-премьеры Васил Шәйхразыев Усть-Кяхта алмагачларын бөтен дөнья буйлап утыртып чыгарга кирәк дигән тәкъдим ясады: «Бу авыл мисалында татарларны бөтен дөньяга танытырга кирәк. Алмагачларга күмелсен әле дөнья!» – диде.

«Усть-Кяхта алмагачлары» этнотуры идеясе менә шулай барлыкка килде, шундук тормышка да ашырыла башлады. Хәзер без бу авылга туристларны алып киләбез. Авыл халкы кунакларны татар милли киемнәреннән каршы алып коймак белән сыйлый, тарихы белән таныштыра.

«Татар!» диеп язып куйдым...

Усть-Кяхта үрнәген башка авылларга да йоктырдык. Онохой исемле авыл бар Бурятиядә. Аның атамасында «Ана кое» сүзе ярылып ята лабаса! Уйлап табасы да юк, үстерә белергә генә кирәк. «Ана кое суын эчсәң, кызың – матур, улың батыр була. Өлкәннәр яшьлеген таба, тормышлар шат була!» дип, матур мәгънә белән үреп җибәрдек бу брендны. Хәзер бу авылны «Ана кое» аша таныйлар. Кунакларга коедан су эчертәбез, «Ана кое»ның сихәте турында сөйлибез, тарихка кагылырга мөмкинлек бирәбез. Беркемнең дә битараф калганы юк. Көч бирә, хәл кертә аның суы, диләр. «Ана кое»дан су эчәр өчен авылга туристлар килә – авыл яши. Татарларга рәхмәт әйтәләр!

Тэгда авылы турында да искә алмый мөмкин түгел. Халык санын алу вакытында бу эшне башкаручы бурят хатыны татарларны кайгыртуына ничек битараф буласың? «Татар дип языгыз, сез болай да аз, сезне сакларга кирәк», – дип аңлаткан ул апа.

Бу авылда яшәүче Костя исемле малай мине үзе эзләп тапты. Сабантуй уздырабыз, Татарстан кунакларын каршы алып, озатып йөрү, оештыру минем өстә. Кунаклар инде автобуска юл тоттылар, артларыннан мин дә ашы-

гам. Шулчак каршыма бер малай килеп чыкты. «Тиздән минем әбиемнең 80 яше тула. Аңа татарча тәбрикнамә бүләк итәргә телим, татарча текст язып бирегез әле!» – ди. Никадәр ашыксам да, котыла алмадым, язып бирдем. Шул көннән без Костя белән дуслашып киттек. Аның искиткеч БТР гаиләсе белән таныштык. Әбисе Флера апа әле дә исән-сау. Әнисе Лариса белән Тэгда авылында «Умырзая» татар мәдәни үзәге ачтык. Ул балаларны татар мәдәнияте, теле белән таныштыра. Тайганың хуш исле үләннәрен тутырып эшләгән сувенир «өчпочмаклар» ясап саталар, конференцияләрдә катнашып җиңү яулыйлар. Костя үзе Идел буе федераль университеты студенты хәзер. Бәлки, берәр татар кызы белән кавышып, яңа татар гаиләсе төзерләр әле. Әбисе Флера апа да «Амин!» дип теләп торганда, булыр, нигә булмасын...

Туристларны бер тапкыр этнотур юлы белән алып барсаң, аларга әнә шул «Ана кое», авыл йортындагы салкын баз, киез итек кирәк. Кызганыч, үз кыйммәтебезне, үз бәябезне үзебез белмибез кайчак... Иң актив, җитез таянычларым – Батталовлар нәселе кызлары, туганнарым Гүзәл, Рәйсә, Нәсимә. Тагын бер алтын бөртегебез – Фәния Гәрәева мине үзе эзләп тапты. Ул мине таптымы, мин анымы... Әле дә Фәниянең барлыгына куанып бетә алмыйм. Үзе кул эшләренә оста, үзе шулкадәр күп мәгълүмат белә, тарихны бик яхшы сөйли. Аның «Күңелле бизәкләре» исемле үз брендын булдырдык. Фәниянең этно остаханәсе урнашкан Бичура районы да хәзер этнотурга керә.

Бергә таулар күчереп була!

Кешеләр белән аралашканда энергия белән алмашасың, үзең үсәсең, масштаблырак идеяләргә тотынасың. Безнең Бурятиядә туган күп проектлар илкүләм үсеш алды. Әле дә хәтерлим, бәләкәй чакта күршедә сул якта Степаныч яшәде, уң якта – Вова бабай. Берсе бурят, берсе рус. Шулкадәр дус яшәдек алар белән. Бер-беребезне бәйрәмнәр белән котлыйбыз, урам хәлләрен сөйләшәбез. Шул балачакта күреп үскән истәлекләрне «Яхшы күршеләр урамы» проектына салдым. «Дуслык караваны» оештырып, Сабантуйда шатёрлар корабыз. Һәр халык кунакларны үз милли



Батталовлар нәселе кызлары.

Бу кадәр дус, тату авылны **бөтен дөньяга танытырга кирәк!**

ризыгы белән сыйлый. Безнең Сабантуйда «Яхшы күршеләр урамы»на җиде меңгә якын кунак килде. Мәскәүдәге коллегаларга да шундый проект эшләргә ярдәм иттем. Анда 250 мең кунакны кабул итте инде проект!

Милләт бит ул җыр-бию генә түгел. Тирәннәнрәк тотынырга кирәк. Мин боларның барысын да логик мәгънәгә ия образлар аша аңлатам. Күбрәк эшләгән саен, тәҗрибә дә арта бит. Безнең төп аудиториябез балалар гына түгел, укытучылар икәнен аңлагач, «Байкал этникасы» укыту-методик комплексы эшләдек. Алай гына да түгел, проект Президент грантлары фонды бәйгесенең җиңүчесе дип табылды! Комплекста этно сүзлек, әйтемнәр, өй, гаилә, агачлар кебек модульләр бар, төрле халыкларда аның атамалары бирелә. Укытучы – балаларга, алар әти-әниләренә, әби-бабаларына бирә бу белемнәрен. Өстәл уены форматын да керттек. Безнең балалар хәзер бу комплекс ярдәмендә бөтен Бурятия буйлап сәяхәт итә, төрле халыклар белән, аларның мәдәнияте белән таныша. Турнирлар уздырабыз хәтта! «Татар этникасы» комплексын Татар федераль милли-мәдәни автономиясе һәм Милли эшләр буенча федераль агентлыгы да зур бәя бирделәр. Россиянең Дәүләт Думасы депутаты Илдар Гыйльметдинов теләктәшлеге белән илебезнең кырык биш регионына өч мең басма бүләк ителде. Эшеңне шул дәрәҗәдә бәяләү – мең мактаудан кыйммәт. «Байкал этникасы» һәм «Татар этникасы» проектлары белән Владивостокка, Амур өлкәсенә, Якутиягә баргач, андагы милләттәшләрне дә таныштырдым. Чын мәгънәсендә горурлыгыбыз ул. Ерак Көнчыгыш Бөтендөнья татар конгрессын активлаштырып җибәрдек. Татар активистлары аркылы территорияләрне ничек үстереп буласын мин инде күз алдыма китерәм, фикерләремне Васил Шәйхразыевка да тәкъдим иттем. Шунысы кызык, хезмәт юлымда миңа татарлар гына иярми. Эшебез башка милләтләргә дә кызык. Милли сәясәт өлкәсендә эшләгәндә беркемгә дә зыян итмәскә, беркемне дә кыерсытмаска кирәк. Бөтен кешегә дә рәхәт булсын! Шулай бергә атлыйбыз. Бурятиянең Халыклар дуслыгы йортын да мин җитәклим: анда 34 милли-мәдәни оешма эшләп килә, 11 ел эчендә 300 дән артык проект тормышка ашырылды. Кул кулны юа, ике кул битне юа, диләр безнең халыкта. 2022 елда Татарстан ярдәме белән автономиябез «Байкалда – татар бизәкләре» проектында җиңү яулады. «Татары в Бурятии: приезжай, покочуем!» проекты исә Бурятия җитәкчелегенең теләктәшлеге белән бик уңышлы тормышка ашырыла. Әнә шулай бергәләп яңа брендлар, этнотурлар, өлкәннәр һәм балалар өчен мохит тудырабыз.

Дөнья буйлап сибелгән татарларны гына түгел, туган илебезне саклар өчен көчебездән килгәнчә тырышабыз, яктылык, шатлык өләшәбез. Бергә таулар күчерергә була! Уйлагач, бөтен дөньяны алмагачка да күмәрбез әле, Ходай бирсә! Яшәргә, яратырга һәм ышанырга кирәк!

Казан–Бурятия–Казан

PRESSA


Фото: Татьяна Афонина

Фәридә Бәгыйс кызы ИСМӘГЫЙЛЕВА

- 1959 елның 1 гыйнварында Азнакай районы Карамалы авылында туа.
- 1985 елда Казан дәүләт университетын тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы белгечлеге буенча тәмамлый.
- 1986 елда Нәдер мәдәният йортында сәнгать җитәкчесе булып эшли башлый.
- 1991 елда Әлмәттә татар гимназиясен ачу инициативасы белән чыга һәм 15 ел дәвамында Ризаэтдин Фәхретдин исемендәге гимназиядә эшли.
- 2005 елның февраленнән – Әлмәт дәүләт драма театры директоры.
- Татарстан Республикасының атказанган укытучысы.
- Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре.
- «Казанның 1000 еллыгы» медале, Татарстан Мәдәният министрлыгының «Мәдәнияттәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе белән бүләкләнә. «Россиянең 100 яхшы товары» программасының «Сыйфат отличнигы» дигән мактаулы иseme бар.

КАЙСЫ ХАЛЫКТАН, ДИСӘЛӘР...



Ләйсән САФИНА

– Әни, Фәридә апа дәрестә кулларын шундый итеп кушырып куя, алар сөяк турысыннан агарып китә хәтта! Ник алай итә икән?
– Сез аңласын дип борчыла инде ул шулай, кызым! Белеп-аңлап китсеннәр, ди...

Әлеге соравымны мин хәтерләмим дә инде. Фәридә Бәгыйсовна турында сүз чыкса, әни гел шул сөйләшүебезне искә төшерә... Әнигә биргән соравым онытылган, ә бармаклары һаман күз алдымда менә! Кулларын нигә шулкадәр каты итеп кыса икән, дип бик аптырый идем.

Дөресен генә әйткәндә, без аннан бераз шөлли дә идек әле. Менә шундый курку катыш ихтирам булды аңа карата. Фәридә апа янында гәүдәне төз тотасы, фикерне туплап, дөрес итеп әйтәсе килә. Хәзер дә шулай. Гимназия ачылганнан башлап Әлмәт театрына киткәнче, ул бездә укытты. Укучылары хәзер дә сагыналар үзен.

Әлмәт шәһәренең Ризаэтдин Фәхретдин исемендәге татар гимназиясенә укырга имтихан тапшырып керәсе иде. Уку-язу, сызу-рәсем ясау, җыр-бию... Бар яклап сыныйлар, күнекмәләреңне тикшерәләр. 1994 ел. Без укырга кергән елны өч класс җыелды. Гимназия ул вакытта интернат белән бер бинада урнашкан. Биек түшәмнәр, киң коридорлар... Форма күлмәктән, ак алъяпкычлардан гимназиягә укырга килдек. Рус теленнән кала, бар дәресләр дә татар телендә бара. Расписаниедә шахмат, ритмика дәресләре дә бар. Икенче сыйныфтан гарәп һәм инглиз телләре укытыла башлады. Яңартылган бинага күчкәндә без инде өченче сыйныфта идек. Монда инде бассейнга йөрибез, мантыйк (логика) дәресләрен кызыксынып өйрәнәбез. Татар телендә генә укыган бу балалар ничек югары уку йортына керер дигән уй башка да килмәде. Гимназияне тәмамлап чыккан берсе университет-институтларга керә бара! Без дә кердек, шөкер!

Җиденче-сигезенче сыйныфта Татарстан тарихы дәресләре укытыла башлады. Бездә курку, чөнки Фәридә Бәгыйсовна укыта...

Фәридә Бәгыйсовна коридордан узса, чапкан җирдән туктап каласың, йөзенче мәртәбә булса да аның белән исәнләшеп үтәсең. Аның дәресендә генә йөз процент тынлык

Фәридә Бәгыйсовна коридордан узса, чапкан җирдән туктап каласың, йөзенче мәртәбә булса да аның белән исәнләшеп үтәсең.



■ Бүген дә Фәридә Бәгыйсовна белән аралашып торабыз. Хәзер инде мин укучы түгел, тик ул минем остазым. Еллар уза, ә аның фикере бүген дә минем өчен кадерле.

урнаша. Тарих үзе кызык фән, ләкин даталары, тарихи шәхесләрнең исемнәре башта бутала... Һун империясеннән башлап бүгенге көнгә кадәрге тарихны истә калдырып кара син! Бер дәрестә Фәридә апа әдәбият программасыннан алдарак Гаяз Исхакыйның «Зөләйха» драмасы эчтәлеген сөйләде. Ахырда: «Күпме авырлык, газаплар кичкән татар... Күз алдына гына китереп карагыз сез... Бүген дә исән, бүген дә тырыша-тырмаша! Мәктәптән соң югары уку йортларына керерсез, әллә нинди зур, җаваплы эшләргә алынырсыз... Шунда үзегезнең кайсы милләт баласы булуыгызны онытмагыз. Сез кайсы халыктан, дисәләр, кем икәнлегегезне күрсәтегез. Сезнең эш-гамәлләрдән чыгып, татарлар турында фикер йөртерләр», – дигәне онытылмаслык булып күңелгә сеңеп калган.

Тугызынчы сыйныфта кемнең кайда укырга керәсен зур комиссия каршында сорашып, 10–11 нче сыйныфларга безне математиклар һәм гуманитар фәннәр төркемнәренә бүлделәр. Шул комиссия каршында мин ике дә уйламыйча: «Журфакка барам!» – дип, бөтенесен шаккаттырдым. Ул хакта әле өйдәгеләр дә белми! Ата-аналар җыелышыннан соң кухняда әти-әнием каршында елмаеп утырам. Казанда бер туганыбыз да юк.

– Әнә, нефтянойга керәсең дә укыйсың! – диләр миңа.

– Йә Казанда укыйм, йә беркайда да укымыйм! – дим, үҗәтләнеп.

Шулай итеп, журфакка керү хыялы үзенекен итте.

Без әле БДИсыз тәмамлап өлгердек мәктәпне. Алгебрадан һәм рус теленнән чыгарылыш имтиханнары тапшырасы. Өстәмә фән буларак, җәмгыять белемен сайладым. Мин мәктәп елларында бию белән җенләнгән кеше. Бөтен классташлар имтиханнарга әзерләнә, ә мин йә Президент чыршысына, йә «Әлмәтем» ансамбле белән берәр фестивальгә китеп барам. Ел саен шәһәр Сабан туенда да төп мәйданда биибез. Иртәгә җәмгыять белеменнән имтихан дигән көнне генераль репетициядә айкалам. Нәкъ уртада басып торам. Ә Фәридә Бәгыйсовна – Сабантуйның алып баручысы. Мине күрмәсә ярар иде дип биим. Бермәлне күреп алмасынмы... Иртән имтиханга киттем. Билетымны алып, языштыргалап әзерләндем. Җавап бирергә килеп утырдым.

Үзегезнең кайсы милләт баласы булуыгызны онытмагыз. Сезнең эш-гамәлләрдән чыгып, татарлар турында фикер йөртерләр.



■ 1 сентябрь. Белем көне.



■ Гимназист сафларына кабул итү тантанасы. Фәридә Бәгыйсовна – Белем алиһәсе.

Комиссиядә, билгеле, Фәридә апа да бар.

– Бу баланы кичә кайда күрдем дип уйлыйсыз? – ди, башка укытучыларга карап.

– Биеп йөридер инде!

– Әйе шул! Сабантуйга әзерләнеп йөри иде... Имтиханга ничекләр генә әзерләндең соң син, Ләйсән?

Каушадым. Фәридә апа бөтен кешегә сатты бит мине. Алай да «бишле» куеп чыгардылар.

Унберенче сыйныфта без Татарстан тарихыннан да имтихан тапшырдык. «Өчле»не «автомат» итеп тә алып була. «Дүртле» кирәксә – А4 форматындагы дүрт биттәге барча даталарны ятлыйсың. «Бишле» алам дисәң, ул даталарга сораулар да өстәлә. Мисал өчен бер сорау: «Алтын Урда чорына тулы характеристика (сәяси төзелеше, икътисады, мәдәнияте, ханнары һәм башкалар, һәм башкалар)». Миңа «бишле» кирәк. Мин хәзер дә Орхон-Енисей төбәгендә Күлтәгин баһадирның кабер ташларында беренче төркирун язулары табылганын хәтерлим. Ул язмалар 732 елга карый. Имтиханга кердем. Даталарны яхшылап ятлаган идем. Билетны тартып чыгардым... «Советлар чорында Татарстан» эләкте. Яратмаган, укымаган сорау.

– Фәридә апа, бу сорауга әзерләнмәдем. «Дүртле» куегыз! – дим.

– Син бит Казанга китәргә җыенасың, бала! Анда да шулай кире кайтырлык булма! Башка билет ал! – ди коры гына.

Шул сүзе Казанда укыган биш елымда да истән чыкмады никтер...

Тагын бер хәл турында сөйлим әле.

Журфакка укырга кергәндә, матбугатта басылып чыккан материалларны да тапшырырга кирәк иде. Ә мин аларга редакциядә печать куйдырмаганмын. Әни папкамны күтәреп Әлмәткә кайтып китте. Бер көн дигәндә әйләнеп тә килде Казанга. Нindидер сөенече бар кебек үзенең. «Фәридә апаңны күрдем, кызым, – ди елмаеп. – Медаль да алырлык иде Ләйсән, биеп йөрде шул, диде...»

Укытучымның ул сүзләре күкләргә күтәрде! Медаль турында уйлаган да юк иде югыйсә.

Университетта татар тарихыннан Гамирҗан Дәүләтшин укытты безне. Беренче дәрестә үк: «Чыңгызханның чын исеме ничек?» – дип сорады. «Темучин», – дим. Кайда, нинди мәктәп тәмамлавым белән кызыксынды, дәрес саен җавап биргәч, миңа автомат рәвештә «бишле» куеп чыгарды. Фәридә Бәгыйсовнадан соң Татарстан тарихын укыйсы булмады миңа. Кире дә кайтасы булмады. Биш елдан соң кызыл дипломым белән Әлмәткә кайтып күрендем дә, кабат Казанга китеп бардым.

Укытучыларыннан уңган кеше бик бәхетле. Укытучылары белән аралашып яшәүче кеше тагын да бәхетлерәк.

Мин ул яктан уңдым. Фәридә Бәгыйсовна кебек педагоглар аздыр ул. Теләгеңнән ваз кичмәскә, туры юлыңнан тайпылмаска, үз дигәнеңә ирешергә яшьли өйрәнгән кешегә тормыш итү җиңелрәк. Без хәзер дә Фәридә апа белән аралашып торабыз. Аның «бала» дип эндәшүе үзе ни тора! «Абый», «апа» дип дәшкән остазларыңның: «Без синең белән горурланабыз!» – дигән сүзләренә ни җитә!

Беренче карашка кырыс, таләпчән күренгән укытучыларны еш искә алабыз. Мөстәкыйль тормышка аяк баскач, акыллы киңәшләре, тирәнтен дәресләре ничек кенә булыша әле. Фәридә апа Исмәгыйлева безне тагын бер нәрсәгә өйрәтте: күргән-ишеткән, укыган һәрнәрсәгә шундук ышанмаска. Төрле яклап уйларга, фикер йөртергә.

Күрешкәч, аркамнан сөеп торган укытучыма, күп нәрсәгә өйрәткән остазыма мең рәхмәт!

КИТАП УКУ – ҮЗЕҢ БЕЛӘН СӨЙЛӘШҮ УЛ

КИТАП УКУ УЛ...

– Китап уку – ул сөйләшү. Шәхес белән, үзең булмаган урын, үзең күрмәгән чор белән. Иң мөһиме – үзең белән!

УКЫРГА МӘХӘББӘТ УЯТКАН КИТАП...

– 10 яшьләр чамасы булган микән миңа, Даниель Дефоның «Робинзон Крузо» мажаралаларын татарча укыганым истә. Чын-чынлап, сюжетка кереп китеп, хисләремне герой аша уздырган әсәр – шул. Ул яшь өчен күләмле әсәрне тулысынча укып, уку – ләззәт икәнен төшендергән әсәр дә шул.

МИНЕ /ДӨНЬЯГА КАРАШЫМНЫ/ ҮЗГӘРТКӘН КИТАП...

– Монда бер китап белән генә чикләнү мөмкин түгел, әлбәттә. Джек Лондонның «Мартин Иден»ын аерым әйтә алам. Әлеге әсәр аша кешеләрнең бер-берсенә мөнәсәбәтен читтән күрдем. Герой урынына өлешчә үземне куеп карадым. Мин еш рефлексия кичерә торган кеше. Бу китапны укыганда үз-үземне өйрәндем дип әйтә алам. «Яхшы китап тәкъдим ит әле», – дисәләр, беренчеләрдән булып, «Мартин Иден»ны телгә алам.

ҮСМЕР ВАКЫТЫМДАГЫ ДУСТЫМ-КИТАП...

– Рафаил Төхфәтуллинның «Җиләкле аланнар»ы. Әлеге әсәрдәге вакыйгаларның төп өлеше мин үскән авылда – Арча районы Кышкар авылында бара. Гадәттә, китап укыганда сюжеттагы урыннарны фантазиядә үзең белгән урыннар белән тутырасың бит. Һәр укучы – китап дөньясында режиссёр-куючы. Ә менә бу әсәрдә тәгаен беләм: автор нәкъ мин белгән, мин күргән урамнарны, аланнарны, су буйларын сурәтли. Язучы белән укучының визуаль дөньясы уртак булган сирәк күренеш бу. Шул фактны аңлау мине аеруча канатландырганы истә.

ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДАГЫ ӨЧ ЯРАТКАН ӘСӘРЕМ ҺӘМ АВТОРЫМ....

– Мөхәммәт Мәһдиев, Гомәр Бәширов – әлеге шәхесләр минем якташларым булу үзе бер горурлык. Аларның һәр әсәре миңа кадерле. Ә менә өченче яраткан авторым Нур Әхмәдиев булсын әле. Аның белән шәхсән күрешеп, әдәбият турында сөйләшеп утырган булуым да авторны миңа якынайта. Китап аша гына язучыны тулысынча аңламаска мөмкин бит. Автор белән күрешеп, сөйләшү китаптан алган тәэсирне көчәйтә, сорауларыңа җавап алырга булыша. Бу – яраткан авторлар булды. Ә менә яраткан әсәрләрем: Мостай Кәримнең «Озын-озак балачак» әсәре, Фатих Хөснинең «Йөзек кашы», Фатыйх Әмирханның «Габделбасыйр гыйшкы».

ӨСТӘЛ КИТАБЫМ (НИ ӨЧЕН НӘКЪ ӘЛЕГЕ КИТАП?)...

– Коръән. Һәр мөселман өчен яшәү кодексы да, инструкциясе дә, конституциясе дә, тормыш фәлсәфәсе дә биредә китерелә. Һәр көнне, һәр очракта мөрәҗәгать итә алган, иң мөһиме – һәр мөселман укырга тиеш булган китап ул Коръән.

БАЛАГА УКЫГАН КИТАПЛАРЫМ...

– Кызыма әле 2 яшь тә тулмады. Аңа укыган китапларның төгәл исемнәрен дә хәтерләмим. Предметлар, төсләр, саннар өйрәтә торган китаплар. Алар бик күп, төрле. Туксан проценты татарча. Татарча булмаганнарын да татарчалаштырып укыйм. Мин аңа күбрәк үзем әкиятләр уйлап чыгарып сөйләргә яратам.

ХӘЗЕР УКЫЙМ...

– Джорджд Оруэллның «1984»ен янәдән укыйм. Моннан ун ел элек тә тетрәнеп укыган идем. Дөньядагы, илдәге хәзерге вазгыятьтә бу әсәрне, тетрәнеп, үзем аша уздырам. Әлеге китаптан алган эмоциональ киеренкелекне азрак нейтральләштерер өчен, параллель рәвештә Александр Цыпкинның «Девочка, которая всегда смеялась последней» юмористик җыентыгын укыйм.

БАСМА ҺӘМ ЭЛЕКТРОН КИТАПНЫҢ УҢАЙ ҺӘМ ТИСКӘРЕ ЯКЛАРЫ...

– Укыганда миндә бер әсәрнең өч варианты да – басма, электрон һәм аудио булырга мөмкин. Һәрберсе үз урынында. Сәяхәттә – электрон, руль артында, урамда саф һава сулап йөргәндә – аудио, өйдә яраткан кәнәфиемдә – басма китап.

УКЫРГА КИҢӘШ ИТӘМ...

– Алда әйткәнемчә, Джек Лондон «Мартин Иден». Сорауларыгыз арасында яраткан авторым Сергей Довлатовны телгә алырга форсат чыгармадыгыз. Шуңа соңгы җавапка аны да өстим. Сергей Довлатовның «Чемодан»ы.

МИН УКЫЙМ

Айваз САДЫЙРОВ,
алып баручы,
шоумен,
«Тәртип» радиосының
башкарма
продюсеры



PRESSA



ИКС, ИГРЕК ҺӘМ ЗЕТ



Лилия
ГӘРӘЕВА

Алар китап укырга яратмый, дип зарлана укытучылар. Алар – кулланучылар, өй эшләрендә булышмыйлар, телефоннан аерып алырлык түгел, ди әти-әниләр. Хәзерге балалар урамда уйный белми, дип аптырый әби-бабай. Әйе, «Z буыны» балалары шундый, дип тынычландырырга ашыга психологлар.

Беренче тапкыр әлеге терминны Америка язучылары Уильям Штраус һәм Нил Хоу «Социаль буын» дип аталган уртак хезмәтләрендә тәкъдим итә. Алар теориясе буенча, билгеле бер вакыт узган саен, Җир шарында яңа бер буын барлыкка килә һәм аларның һәрберсе үзенә генә хас сыйфатлары белән аерылып тора. Мәсәлән, 1967–1984 елларда туган «X буыны» кешеләренә прагматизм, артык җаваплылык, авырлыклардан курыкмау, эшкә бирелгәнлек хас. Алардан соң туган «Y»лар исә – Россиядә яңадан барлыкка килгән капитализм һәм ирекле базар мөнәсәбәтләре шартларда үскән буын, алар үзләре өчен нәрсәнең кирәкле һәм файдалы булуын тиз күреп алалар, үзгәрешләрдән курыкмыйлар, яңалык яраталар. 2000–2011 елларда туганнарны «Z буыны», «зуммер»лар яки «цифрлы кешеләр» дип атыйлар. «Туганда ук кулларында гаджет булган» дип, нәкъ менә шушы буын хакында әйтәләр инде. Әйе, алар интернеттан башка тормышны күз алдына да китерә алмый, урамда чана шуугa караганда, телефонда

стратегик уеннар уйнауны кулайрак күрәләр. Кулларыннан җитәкләп алып чыкмасаң, атна, хәтта айлар буена да урамга уйнарга чыкмаска мөмкиннәр. Социаль челтәрләрдә дуслары йөзләп, ә чын тормышта исә ялгызлыкны өстен күрәләр. Бу «зуммер»лар – безнең – «X буын»ның балалары.

Без мондый түгел идек...

Бала чакта дәү әни, әниләрнең: «Без мондый түгел идек, хәзерге балалар безгә охшамаган», – дип әйткәнен еш ишетергә туры килде. Бүген ул көн үзебезгә дә килеп җитте. Балаларыбызга карыйбыз да: «Без мондый түгел идек», – дибез. Өйдә булышырга теләмиләр, кушканны үтәмиләр, бәхәсләшәләр, күпне таләп итәләр...

– Бала ул кайсы чорда туса да бала инде – төрле холыклы, төрлечә сәләтле, тирә-якны, дөньяны танып белергә омтылучан. Ләкин хәзерге яшүсмерләр тәрбия һәм белем бирү метод-системалаларының үзгәрүе, заманча техникалар йогынтысы аркасында, чынлап та, элеккегеләрдән аерылып тора, – ди Түбән Кама шәһәренең Бакый Урманче исемендәге 2 нче гимназия укытучысы Зилия Хаҗиева. – Юк, элеккеге чорныкылар белән чагыштырганда замана балалары начаррак та, яхшырак та түгел, алар бары башка төрле генә. Алар үз-үзләренә ышанучан, кыю, әрсезрәк дисәң дә ярыйдыр. Таләпчәннәр. Монысы бигрәк тә ата-аналарына мөнәсәбәттә сизелә. Бир, ал, тап... Аларга күп һәм тиз кирәк. Үз-үзләрен яратучан, тышкы кыяфәтләренә зур игътибар бирәләр, сәләтлеләр, чөнки мөмкинлекләре елдан-ел үсә бара. Тәнкыйтьне яратмыйлар, киңәшкә колак салалар. Яңалыктан, әйләнә-тирәдәге үзгәрешләрдән хәбәрдар, чөнки информация белән җиңел һәм тиз эш итәләр.

«Зуммер»ларга хас иң беренче һәм төп сыйфат – нәкъ менә мәгълүмат белән эшли белү. Алар искиткеч зур мәгълүмат ташкыны тәэсирендә үсә. Үзләренә кирәкле мәгълүматны бик тиз эзләп таба һәм куллана белә.



Фото: Анна Арахамия

«Сердәш» балалар һәм яшүсмерләргә психологик-педагогик ярдәм үзәгенең клиник психологы Зәринә НӘФИЕВА: «Бүгенге яшүсмерләр интернетсыз тормышны күз алдына да китерә алмый. Телефоннан мәхрүм итү алар өчен чамадан тыш авыр җәза. Әти-әниләргә бу ысулны кулланмаска киңәш итәм».

– Аларны бернәрсәгә дә өйрәтәсе юк, – ди дүрт бала үстерүче журналист Эльмира Сираҗиева. – Улыбыз Арысланга 10 яшь иде. Кайсыдыр бер конкурста катнашу өчен үзең белән таныштыру видеосы ясарга кирәк булды. Кемгә әйтергә дип аптырап торганда: «Әни, үзем эшлим мин аны», – диде Арыслан. Һәм башкарып та чыкты! Шундый зур конкурс өчен бала ясаган бу видео гына ярармы соң, дип укытучысына җибәрдем. Барысын да дөрес итеп, җиренә җиткереп эшләгән булып чыкты. Кирәкле программасын да, видеосын да, музыкасын да тапкан. Үзлегеннән шул программада эшләргә дә өйрәнгән.

– Олы кызыбыз Сөмбеләгә 20 яшь, гаджетлардан башка яши алмый, – ди Актаныштан өч бала әнисе Гөлназ Хөҗҗәтова. – Йокыдан торуга ук телефонга үрелә. Йоклап киткән чагында да кулында телефон була. Менә шундагы тормыш канына сеңгән инде аның. Без моңа каршы башта көрәшеп карадык, әмма файдасыз булуын күреп, туктадык. Ул интернетта теләсә кайсы сайтта түгел, үзенә кызыклыларында гына утыра. Яшүсмер вакыттан ук Корея поп-музыкасы кызыксындыра аны. Анда күчле музыкаль группалар бар. Тормышлары тәүлек әйләнәсе эфирда яктыртылып тора. Сөмбелә дә шул эфирларны карый, фан-клубтагылар белән аралаша. Моның файдалы ягы да булды. Аларның корея телендә сөйләшүләре инглизчә субтитрлар белән бирелеп бара. Кызым шуларны карап, инглизчәсен камилләштерде, корея телен өйрәнә башлады. Хәзер ул өченче курс студенты, инглизчә камил сөйләшә.

Гөлназ ханым үзе дә психолог булып эшли һәм «Z буыны» балаларының йомшак якларын да, көчле якларын да яхшы белә.

– Алар укырга кирәклеген үзләре дә бик яхшы аңлый, – ди ул. – Бу буын яшүсмерләре арасында ниндидер бер шөгыльең яки кызыксынуың булу абруйлы санала. Акыллы кеше – уңышлы кеше дип уйлый алар. Үзләрен кызыксындырган предметларны бик теләп үзләштерәләр, дәлиллисе, исбатлап күрсәтәсе юк. Мәсәлән, өч баламның берсенә дә укыгыз дип тукыганым, өй эшен эшләгез, дип, өсләрендә торганым булмады. Өчесе дә яхшы укыйлар, чөнки укырга кирәклеген аңлыйлар. Ләкин күп нәрсәнең асылына ук төшенеп тормыйлар, өстәнөстән генә караган әйберләре дә күп. Ә инде үзләренә кирәкле дип саныйлар икән, алларында бернинди киртәләрне дә күрмиләр.

Гөлназның фикерен Зилия Хаҗиева да раслый.

– Элеккеге укучылар мәктәптә дәресләрнең барысын да тиз үзләштерәләр һәм тирәнтен беләләр иде. Ә хәзерге балалар үзләре сайлаган фәннәргә генә зур игътибар бирә. Барысы да югары белем кирәклеген яхшы аңлый. Мәктәпне бетергәч, һәрберсе кайдадыр белем алырга омтыла, – ди 47 еллык педагогик стажы булган укытучы.

Элеккеге чорныкылар белән чагыштырганда замана балалары начаррак та, яхшырак та түгел, алар бары башка төрле генә.

Әлеге буынга хас төп сыйфатлардан тагын берсе – алар клиплы фикерле. Замана балалары – визуалистлар, текст укыганда аларга күз алдында картинкалар булуы мөһим. Зур текстларны укырга яратмыйлар. Ярты битне тутырып тасвирланган пейзажлар, архитектура күренешләре алар өчен түгел. Аларга текст кыска, шул ук вакытта эчтәлекле дә булсын.

– Хәзерге балалар арасында китап укучылар бик сирәк. Сөйләм телләре ярлыланды. Элеккеге укучылар туган телдән иншаны бишәр-алтышар бит язса, хәзер көчкә өч биткә җитә, – ди Зилия Галиевна. – Тормышларын телефоннан башка күз алдына да китермиләр, компьютер белән эш итәргә мәктәпкә кергәнче үк өйрәнәләр. Өй эшләрен дә күбесе интернеттан гына күчереп яза.

Бөтен яшәеш телефонга сыйган!

– Бүгенге яшүсмерләр туганнан ук гаджетларны күреп үскән беренче буын, – ди «Сердәш» балалар һәм яшүсмерләргә психологик-педагогик ярдәм үзәгенең клиник психологы Зәринә Нәфиева. – Замана баласының телефонына бөтен яшәеше сыйган дип әйтерлек – дуслары, кирәкле мәгълүматы, расписаниесе, почтасы, хәтта көндәлеге дә... Телефонсыз калу – алар белән дөньяда булырга мөмкин иң куркыныч хәлләрнең берсе. Кайбер әти-әниләр, яшүсмергә җәза бирү максатыннан, аны телефоннан мәхрүм итә. Өй эшен эшләмәгән, сүзне тыңламаган, савыт-сабаны юмаган өчен генә телефонын алу – артык кырыс, гаделсез җәза дип саныйм. Балага интернеттан чынлап та куркыныч янамаса, әти-әниләргә әлеге ысулны кулланмаска киңәш итәм. Нигә яшереп торырга, өйдән телефонсыз чыксак, үзебез дә кире борылып кайтабыз бит. Безнең дә кулыбызда күп вакыт телефон була. Әгәр дә әти-әни белән бала арасында ышанычка корылган мөнәсәбәт, баланың кызыклы мавыгуы, шөгыле бар икән, аның көне буена телефонда утыру ихтыяҗы булмаячак.

«Зуммер»ларның күпчелеге – интровертлар. Шау-шулы зур компанияләргә караганда ялгызлыкны якынрак күрәләр, күзгә-күз аралашырга яратмыйлар. Реаль тормышта дуслары берничә генә, аның каравы, социаль челтәрдәгеләре күп.

– Телефоннан аралашу безнең балаларның өчесе өчен дә күзгә-күз аралашуга караганда җайлырак. Кешенең янына килеп сөйләшергә кыенсыналар. Кайчагында кызым Камилә, дустын сагынып, аның белән уйнап кайтам дип китә дә, алып кайтырга килсәң, өчесе өч почмакта телефонга текәлеп утыралар, бөтен аралашулары менә шул, – дип, әлеге фикерне дәвам итә Гөлназ ханым.

– «Z буыны» балалары аралашу ихтыяҗын интернет аша тулыландыра. Интернеттан аралашкан ул кешене син күрмисең, шуңа да аңа эчендәге серләрне сөйләве җайлырак. Поездда беренче һәм соңгы тапкыр күргән юлдашыңа барлык сереңне сөйләп кайткан кебек бу, – дип аңлата моны психолог. – «Дусларың бармы?» – дип сорыйм үземә килгән яшүсмерләрдән. «Класста берәү-икәү генә, интернетта күп», – диләр. «Балабыз аз аралаша, үз эченә йомыла, безгә үз тормышын сөйләми», – ди әти-әниләр. Психолог булып эшләү дәверемдә сөйләшергә яратмаган яшүсмерне очратканым юк әле. Алар аралашырга бик ярата, ләкин үзләрен кызыксындырган темаларга гына. Тик ул темаларны әти-әниләре өчен кызыксыз дип саный һәм бу хакта сөйләми.

Мәктәптә ата-аналар җыелышында чыгыш ясаганда мин еш кына бер сорауны бирәм: «Эштән кайткач баладанниләр сорыйсыз? Ничәле алдың, ашадыңмы, соңга калмадыңмы, ник башыңа кимәдең, дипме? Әйе, әти-әни өчен бу сораулар да мөһим. Ләкин болар баланың эчке дөньясын ачмый. «Бүген мәктәптә нинди кызыклы хәлләр булды? Тәнәфестә нишләдең? Ниләр турында сөйләштегез?» – дигән сорауны сирәкләр генә бирәдер. Кайбер гаиләләр баласының ниләр белән кызыксынуын да белми. Нинди җырлар тыңлый ул, кумиры кем, нинди блогерларны карый? Ихластан болар белән кызыксынсаң, үзең дә шул блогерларның нәрсә хакында сөйләүләрен белсәң, бала белән аралашу өчен бик күп темалар табарга мөмкин. Яшүсмер өчен әти-әнисенең аны мәктәп укучысы гына итеп түгел, ә шәхес итеп күрүләре бик мөһим.

Бер кыз мөрәҗәгать итте. Чыгарылыш кичәсенә әнисе бик матур күлмәк алган. Кыйммәтле, затлы күлмәк. Кызның үзенә үлчәп теккән кебек, шундый килешә. Ә ул исә күз яшьләре белән елый. Әнисенең аның белән киңәшләшмәгәне, аның фикере белән исәпләшмәгәне, аны әле дә балага санаганы өчен үртәлә. Аның үзе эзләп, үзе киеп карап, дус кызлары белән киңәшләшә-киңәшләшә аласы килгән күлмәкне. Бик аңлыйм бу кызның кичерешләрен. Үз фикерләре белән исәпләшү – һәркем өчен, ә тизрәк олы кеше булырга омтылган яшүсмерләр өчен аеруча әһәмиятле.

Көч түгәсе булмасын...

Сер түгел, әлеге буын көндәлек йорт эшләрен башкаруга караганда, ял итү, күңел ачуны өстен күрә. Әти-әнигә булышу алар өчен арткы планда.

– Бала чактан ук өйдә безнең үз вазыйфаларыбыз бар иде, – дип сөйли Эльмира Сиражиева. – Идән юу, өй җыештыру, әниләр эштән кайтканчы ашарга әзерләп тору, савыт-сабаны юу – безнең өстә булды. Безгә аны беркем кушмады, үзебез шулай булырга тиеш дип кабул итә идек. Безнең балаларда бу юк. Кызларыбызның берсенә – 19, икенчесенә 17 яшь. Идән юасы булса, бәхәс чыкмый калмый. Алар моны

ялт итеп эшләп куя ала, ләкин эшләмәс өчен мең төрле сәбәбе бар: идән әле чиста, минем эчемне пошырмый, теге юлы да мин юган идем... Ахыр чиктә, акча бирсәң, юам диярга мөмкиннәр.

Замана балалары яшьтән үк акча эшләү юлларын белә. Ләкин әти-әниләреннән аермалы буларак, алар иртәдән кичкә кадәр офиста утыруны күз алдына да китерә алмый. Ирек яратучы әлеге буынга иректе графиклы, күңелгә ошаган эш булсын, күңел ачу, сәяхәт итү өчен дә вакыт калсын. Карьерага ирешәм дип, 24 сәгать тир түгә торган буын түгел бу.

– Сөмбелә 2 нче курста укыганда ук онлайн-дәресләр биреп акча эшли башлады, – дип, шушы фикерне куәтли Гөлназ Хөҗҗәтова да. – Иртәдән кичкә кадәр эштә утыру аның өчен кабул итми торган әйбер. Эшләвен эшләячәк, әйбәт итеп эшләячәк, ләкин аның өчен эш сәгатьләре иректе булу кирәк.

Улыбыз Газизнең классташлары инде бүгеннән үк акцияләр сатып алып, биржаларда торып, акча эшлиләр. Ничек акча эшләп була, танылган кешеләрнең машиналары, киемнәре нинди – шулар белән кызыксыналар. Күп көч түкми генә, үзләрен куркыныч астына куймыйча күп акча эшлиселәре, яхшы киенәселәре, мул яшиселәре килә.

Без – «Z буыны»н үстерүче әти-әниләр – халыкның күпчелеге матди яктан чагыштырмача тигез булган шартларда үстек. Дефицит заманнарын кичердек. Кибетләрдә сайлап алырга әйбер аз иде. Хәзерге балаларныкы кебек мөмкинлекләребез булмады. Булганына канәгатьләнергә өйрәндек. Ә менә балаларыбыз – моның киресе. Аларга күп кирәк, яхшысы, сыйфатлысы кирәк.

«Миңа бу кроссовкалар ошамый. Болар брендлы түгел», – ди аяк киеме сайларга кергәч үземнең дә 17 яшьлек кызым Зилә. Акчаң җитәрлекме, башка планнарың юкмы – анысы кызыксындырмый. «Акчаң булмагач, нигә дип бала таптың?» – диярга дә мөмкин. Безнең кызга гына түгел, аның яшьтәшләренең күбесенә хас бу.

– Без үскәндә бар да тигез иде, барыбыз да «Спартак» теккән сандалидан, өстә абыйдан яки ападан калган күлмәк, барыбыз да ишегалдындагы иң якын мәктәпкә укырга йөрибез... Ә хәзер әти-әниләр үзләре үк балаларына мәктәпнең яхшырагын сайларга тырыша. Гади мәктәп түгел, гимназия яки лицей булсын... Билгеле, андый мәктәптә төрле катлам балалары очраша. Алар бер-берсенекен күрә, чагыштыра. Балаларның үз иерархияләре. Башкалардан аерылып тормау яшүсмер өчен бик мөһим, – дип ачыклык кертә Зәринә Нәфиева. – Балага куллану культурасын сирәк әти-әни өйрәтә. Безне кечкенәдән: «Моны ала алабызмы?» – дип сорарга өйрәттеләр. Әгәр дә балагызга, әлегә мөмкинлек менә шулай, хәзергә менә боларны гына ала алабыз, дип әйтә килгән булсагыз, мондый проблема чыгарга тиеш түгел. Әйтик, ул кыйммәтле айфон сорый. Ни өчен айфон кирәк аңа, башкаларда да булган өчен генәме? Әгәр дә айфондагы функцияләр арзанлырак телефонда да бар икән, бренд өчен генә дип нигә артыгын түләргә? Әлбәттә, бу сүзләрне әти-әни әйтеп, яшүсмер аны кабул итмәячәк. Моны чит кешедән ишетергә тиеш ул. Бу яшьтә балага яшьтәшләренең йә танылган берәр кешенең фикере мөһимрәк. Социаль челтәрләрдә әлеге теманы күтәрүче блогерлар бар. Менә аларны ул тыңлаячак.

Балагызда шәхес күрегез

– Психологик ярдәм сорап килгән әти-әниләр үсмер балаларында укырга мотивация булмаудан еш зарлана. Балалар белән аралаша башлагач: «Нигә кирәк миңа химия йә булмаса география, геометрия?!» – диләр. «Әйе, килешәм, кайбер фәннәрнең тормышта кирәге чыкмаска да мөмкин. Ләкин алга таба бары тик дипломлы белгечләр генә башкара торган һөнәр сайлыйсың икән, сиңа бит укырга кирәк, – дип аңлатам. – Диплом ул – әлеге һөнәр өлкәсенә үтеп керү өчен ачкыч. Ә диплом алу өчен ачкыч – мәктәптә бирелгән аттестат. Аттестат булмаса, диплом да булмый».

Географияне яратмыйм, аның миңа кирәге юк, ди бер кыз. «Сәяхәт итәргә яратасыңмы?» – дип сорыйм. Әлбәттә, ярата. «Ә сәяхәт итәр өчен географияне белү кирәк. Мәсәлән, Таиландка җәй көне барудан файда юк, бу вакытта анда тропик яңгырлар ява. Анда кыш көне бару кулай. Һәр илнең үзенчәлекләрен география дәресендә укыталар», – дигәч, ул бу предметка башкача күзлектән, кызыксыныбрак карый башлады. Бүгенге яшүсмерләр коры сүзгә түгел, дәлилләргә, аргументларга ышана. Бу яхшы, димәк, аларның тәнкыйтьчел фикерләү сәләте бар.

Психолог фикеренчә, нинди генә чорда яшәсәк тә, бала белән әти-әни арасында ышанычка корылган мөнәсәбәтләр булырга тиеш. «Баланың кичерешләреннән көлмәгез, аларга юк нәрсә итеп карамагыз, – ди ул. Кызыгыз: «Илнур миңа игътибар итми», – дип, сезгә килеп сөйли икән, «Андый Илнурлар әле күп булачак, исең китмәсен», – дип, баланың хисен кадерсезләмәгез. Аңа шушы мизгелдә нәкъ менә шушы хистән дә мөһимрәге юктыр кебек тоела. «Әйе, мин сине бик аңлыйм», – дип, хәленә керегез. Әти-әниләр балаларына үзләре турында бик аз сөйли. Балачагы ничек узган, мәктәптә укыганда нинди кызыклы вакыйгалар булган, нинди фәннәрне яраткан – болар балаларга бик тә кызык. Бала белән күбрәк сөйләшергә кирәк дип саныйм. Өйдә үзеннән көлмәячәкләрен, ачуланмаячакларын белсә, ул таянычны читтән түгел, нәкъ менә сездән эзләячәк».

«Z буыны» балаларының бер өлеше инде үсмерлектән чыгып, мөстәкыйль тормышка аяк басты. Аларга алмашка яңа буын – «альфа» буыны үсеп килә. Белгечләр фикеренчә, болар – 2011–2015 елдан соң туган балалар. Нинди булыр алар? Безнең балалар тормышларын интернеттан башка күз алдына да китерә алмаган шикелле, алар дөньясы роботлар, ясалма аң белән бәйле булырмы – монысын киләчәк күрсәтер.

КАЗЫКЛАР



Алсу
ШАКИРОВА

– Бер көнне арткы якка – бәрәңге бакчасы җиренә чыксам, Раушан казыклар кагып ята. «И улым, нәрсә була бу? Ничекләр эшләп чыгарсың моны?» – дип борчылам, тезелеп киткән казыклар мәйданын күреп. Ул кадәр зур төзелешне күргәнем дә юк иде... Холкы шундый – уйласа, эшли. Тотынгач, ахырына кадәр җиткерә. Үзе каккан шул казыклардан төзелгән тормыш инде бу, – дип, улы белән горурлану хисләрен яшерә алмый Рәмзия апа.
Балтач районы Югары Субаш авылында яшәүче ХӘБРИЕВләр гаиләсендә кунакта без. Җир җимертеп эшләп, күпләргә үрнәк булып, бер түбә астында өч буын яшәп ята. Ничек кенә әле! Берәүләр каланы сайлаганда, Раушан белән Алия саланы үз итә.
Раушанның шушы җиргә суккан казыклары буйлап китик әле.
Авылда корган мул, бәхетле, түгәрәк тормышын нинди нигезләргә утырттым икән авыл егете...



Язмыш

Төп казык бу түгел, әлбәттә. Аны Раушан үзе какмаган да. Ләкин тормышына саллы өлеш керткән ул. Гаиләдә дүрт кыздан соң зур бүләк булып дөньяга килгән бердәнбер малай Раушан. Алдагы дүрт кызын да бер үк акушерка белән тапкан Рәмзия апа, шаяртып, бишенче тапкырында бала табу бүлмәсенә аның белән керүдән баш тарта. «Тукта, син кермә әле, гел кызлар бирәсең», – ди акушеркага. Ул вакытта УЗИ аппаратлары бармы соң? Балаң белән тәүге күрешүеңдә генә кем икәнен беләсең ләбаса. Ни хикмәт, күкрәгенә ир бала салып куялар бит Рәмзия апаның. Раушан! Бу сөенечне, авылга – күршеләренә шалтыратып, Рәфкать абыйга палатадаш хатын җиткерә. Бәхетле әти шул көнне бәби тәпиен өч литр самогон белән бик яхшылап юганын гаиләдә әле дә көлеп искә алалар.

Рәмзия апа үзе 35 ел колхозда хезмәт куйган: 17 ел сыер сауган, 15 ел бозау караган. Рәфкать абый колхозда тракторда эшли, күп еллар район буенча алдынгы комбайнчы исеменә лаек була. Үз гомерләрендә бергәләп өч йорт күтәргәннәр. Өстәл кадәр ташларны берүзе күтәреп сала торган өрлек кадәрле ир булган ул. Кайсы эшкә тотынса да, Рәфкать эшләгәне күренеп тора, аныкы гел икенче була дип мактаганнар авылда. Кызганыч, кыска гомер насыйп була аңа. 52 яшендә үк бакыйлыка күчә Рәфкать абый... Тормыш йөге, йорттагы ир-ат эше тулысынча Раушан өстенә кала. «Рәхәт күрмәде инде», – дип авыр сулый әнисе, ул елларны искә алып...

> *Мондый хезмәт мохитен авылда гына тудырып була. Улларыбыз бары тик татарча гына сөйләшә. Әби тәрбиясенең дә җимешләре бу.*

Кечкенәдән техника тирәсендә чуала Раушан. Әтисе дә мәктәптә инструктор булып эшләгән вакытлар бу. Булган инде Югары Субаш мәктәбенең көчле чаклары: тракторы, автобусы, машиналары... Егетләрне, укытып, мәктәптән үк права белән чыгарганнар. Күңеле яткач, бөтен деталь-запчастьларны тотып, җыеп карап өйрәнә малай. Интернет юк – бөтен кызыксындырган мәгълүматны китаптан укып ятлый. Әтисез калган елны ук – 16 яшендә Мари якларыннан беренче тимер атын барып ала – ярым сүтелгән хәлдәге «ЮМЗ» тракторы була ул. Аны яңадан җыя Раушан. Колхоз эшеннән дә тартынмый: Т-150 тракторына утыра, «Дон» комбайнында – ярдәмче, «Нива»да берүзе эшли. Туры килсә, очкычны да һавага күтәрә алыр иде егет!

Әтисе исән чакта ветеринар белгечлеге турында хыялланса да, башка тормыш мәктәбе узарга туры килә аңа. Әнисен калдырып китеп буламы инде?! Була, әлбәттә... Ләкин Раушан өчен бу башка сыймаслык кебек тоела. Һөнәри лицейда машина йөртүче, тракторчы, эретеп ябыштыручы белгечлеген алып, ватан алдында бурычын үтәп кайтырга да өлгерә.

Ә калган казыклар турында Раушан үзе сөйли...

Җир кадере

– Армиядән кайткач, әнинең, апаларның, туганнарның пай җирләрен алып, шулар белән эшли башладым. Кеше башына 4,8 гектар җирләр бүленгән иде. Шунда печән әзерлим дә, аренда өчен хуҗасына печән белән түлим. Аннары Мари Иле якларыннан җир рәсмиләштердем. Ул чакта ук: «Күбрәк ал, аннары булмый әле ул», – дип кисәттеләр. Кая инде, илле гектары да җитә кебек иде...

Үз җирләремдә эш тәмамлангач, Мари Иле, Киров якларына юл тотабыз. Анда да җирне арендага алып эшкәртәбез, печән әзерлибез. Хәзер 150 гектар җирем бар. Авылда – иркенлек. Патша кебек яшибез дип көләбез. Узган чакрымнарны, киң басуларны, чиксез кырларны күреп үскән, шуның белән яшәгән авыл кешесен бер бүлмәле фатирга ябып куй инде менә... Югыйсә Балтачка – район үзәгенә китеп өй салырга да мөмкинлегем бар. Ләкин үз авылымнан беркая китәсе килми. Күршеләребез йортларын сатып күченеп киттеләр. Сатып алырга теләүчеләр килеп йөри башлаганын күргәч, туктале, нишләп чит кешегә бирик әле моны, дип, ул җирне дә үзебез сатып алдык.

Күрше төбәкләрдә эшкәртелмәгән кайсы җиргә барып тотынсаң да, шундук хуҗасы табыла. Киләчәктә зур проблемага әйләнәчәк әле бу җир мәсьәләсе. Кемгә кирәк ул авылдагы җир, димәгез. Иң туклыклы, уңдырышлы туфрак авыл җирендә. Җир кешесе кадерен дә, аермасын да белә аның. Хәзер аңлыйм: әти исән булса да шәһәргә китмәс идем... Җир кешесе мин.

Алия

– Армиядән кайткач, бер дустым ашка чакырды. Ул да хезмәт итеп кайткан гына иде әле. Шул хөрмәткә Коръән укыттылар. Алия белән шунда таныштык. Ул табын әзерләшергә, ярдәм итәргә килгән. Очрашып йөргәндә үк авылда каласымны белде. Минем киләчәгем Субаш белән генә бәйле булганын аңлый иде. Алай да: «Авылда да шәһәрчә – сыер саумыйча яшәп була», – дип ышандырган идем. *(Көлә).* Бер түгел, кырыкка якын сыер саварга туры килде менә. Алияне дә эш белән куркытып булмый. Авыл кызы бит ул! Тормыш йөген бергә тартабыз.

Туй мәсьәләсен дә җиңел генә хәл иттек. Ноябрьдә дусларның туена баргач, Алия кәләш бәйләмен тотты, мин – кияү аткан буманы. Декабрьдә инде безнең туебыз булды. Алдагы ел – кәбисә елы иде. Шуңадырмы, бер кафеда да буш көн юк. Шуңа туйны авыл мәктәбе ашханәсендә уздырдык. Аның каравы, шулкадәр күңелле узды! Кунакларны чак озаттык. Биер өчен бөтен музыканы үзем сайлап, яздырып куйдым. Хәер, бөтен оештыру эшләрен дә үз җилкәмә алдым. Безнең туйны дуслар-туганнар әле дә сагынып искә алалар.

Авылыбызда фельдшер булып эшли Алия. Әнигә укол йә система куясы булса, бик җайлы ул яктан да. Алты операция кичерде әни. Беренче ярдәм күрсәтер кешесе

янында булуга ул бик куана. Шәһәргә китик дип бер тапкыр да үгетләмәде Алия. Кайсы җирегез шәһәрдән ким дип сорасалар, аптырый хәтта... «Ким түгел, артык әле!» – ди.

Улларым

– Өч малай бүләк итте миңа Алия! Бик зур горурлыгым инде алар. Олысы Раянга 9 яшь. Аның үскәнен хәтерләмим дә кебек. Ул вакытта трактор белән эшләп йөргән чаклар – еш ватыла. Мин йә ремонтта, йә эштә... Рияз 7 яшьтә, Ренальгә 3 яшь тулды. Кая барсам да, үзем белән алып йөрергә тырышам. Шуңадырмы, «әти кебек» дигән сүзне еш кабатлыйлар. Беләм, миңа охшарга тырышалар. Бәләкәе гел минем белән тракторга утырып йөри. Йортка күчкәндә ламинатны Раян белән икебез җәйдек. Уртанчыбыз Рияз – иң шугы. Анысы бигрәк тә авыл җанлы булып үсә. Кайвакыт авылда тракторны сорап торалар да, биреп җибәрәм. Урамда күреп, танып ала шуны. «Әти, безнең тракторны кем алды?» – дип сорый кайткач. Сенаж әзерләгән вакытта бик зур өмә була бездә. Унлап техника эшли: ташыйбыз, чокырга бушатабыз, таптыйбыз... Риязның үзендә урак өсте: безне кабатлап, уенчык машина-тракторлары белән ул да сенаж әзерли. Уенчык КамАЗ машинасы белән алып кайта, үзе ясаган чокырга бушата, таптап тыгызлый, өстен пакет белән яба, ташлар белән бастыра. Икенче көнне ачып, сыерларга шул сенажын бирә. Көтүдән кайткан сыерлар урыннарын бутап бассалар да, шундук сизеп ала ул.

Җәен бергәләп сыерларны көтүгә куалар. «Электропастух» белән әйләндереп алган урынга алып барып ашаталар, саклыйлар. Балаларны дөрес тәрбияләүнең бердәнбер дөрес юлы – үз үрнәгең. Эш белеп үсәләр дип куанабыз. Сыерларга сенаж бирәләр, асларын чистарталар. Кечкенәдән кул арасына кертергә тырышабыз. Шәһәр малайларын бәбәй урынына тоталар бит әле бу яшьтә! Мондый хезмәт мохитен авылда гына тудырып була. Улларыбыз бары тик татарча гына сөйләшә. Әби тәрбиясенең дә җимешләре бу. Аларга күз-колак булып торыр кешебез һәрвакыт янәшәдә. Өй каршында бик иркен мәйданыбыз бар. Шунда дуслары белән җыелышып уйныйлар. Ә шәһәрдә... Балалар өчен аерым бер кеше кирәк.

Өч малай – бик зур байлык! Әти исән булса, бигрәк куаныр иде бу байлыкка. Шулай да бер кыз да яратып карыйсы килә. Кызларның исе үк икенче була, диләр...

Кәсеп

– Үзем җыйган беренче «ЮМЗ» тракторын сатып, МТЗ-80 тракторы алдым. Бераздан иске генә сараебызга сыерлар алып кайтып бастырдык. Яшь чактагы хыялымны барыбер тормышка ашырдым бит – ветеринар курслары үттем. Ассимилятор эшен дә үзем башкарам. Токымлы орлык белән үзем йөгертәм сыерларны. Хайван белән эшләгәндә төрле хәлләр була. «Сыер котырса аттан яман» дигән мәкальнең туры мәгънәсенә тап булырга туры килде. Бер абзый белән Арчадан сыерлар алып кайттык. Минем сыер машинадан әйбәтләп кенә төште, алып кереп яптык. Икенче сыерны төшерергә дип менгән идем, сөзде. Алай гына да түгел, котыра ук башлады. Бавын кисеп машинадан төшерсәк тынычланыр дигән идек. Нинди ул! Безне куарга тотынды. Тотып кына булмый: кулларны сыдырып, шештереп, имгәтеп бетерә язды. Шофёр егетне үтерә дип торабыз, каен агачы артына качып котылды. Аны коткарырга дип сыерның артына сәнәк белән сугуым булды, мине куарга тотынды. Трактор чүмеченә абынып егылдым, сөзеп җибәрә, малай! Сыер басуга чыгып чапты. Ике айдан бозаулый торган сыер бу! Басуда трактор белән тоттык. Фараларны ватып, тракторны, «ГАЗель»не яньчеп бетерде. Кире илтеп бирдек. Хуҗабикәсе: «Кил, әйдә, тилемсә, китәсең килмәгән икән», – диде дә, җитәкләп алып кереп китте сыерын. Шаккаттык!

Сыерларның файдасын күрдек без. Зур ферма турында хыяллана башладым. Бәрәңге бакчасына казыклар какканда ук җиңел булмыйсын аңлаган идем инде. Ләкин уйлаган эшемнән кире кайта торган кеше түгел. Башлагансың икән – ахырына кадәр җиткер!

Ферма салгач, аны буш тотасы килми. Сыерлар санын арттырдык. Бернәрсә дә җиңел генә бирелми... Берсендә унөч тана алырга уйлап, аларны сайлап, карантинга куеп кайттым. Банк кредитка рөхсәт бирде, бөтен документларга да кул куелган, инде акчаны гына аласы калган иде. Ышанычлы, имеш! Ләкин бу сәяси вакыйгалар башлану белән мартта акча бирүне туктаттылар. Ә минем таналар





алынмаган, 700 мең аванс түләнгән! Калганын йә түлисең, йә танасыз да, акчасыз да каласың. Ничек итсәм иттем, танышлардан акча алып торып, таналарны алып кайттым. Бүгенге көндә бер кредитыбыз да юк. Тракторлар, комбайн, машиналар бар. Фермабызда – 45 баш сыер. Бозаулаганнарын да камерадан гына карап торам. Дөньялар тыныч булса, тагын да зуррак планнар бар әле!

Нигез

– Бу яңа йортыбызга ике атна элек кенә күчендек. (380 квадрат метрлы, бөтен җирдә – хәтта верандада да җылы идәннәр, мунчасы, барбекю зонасы каралган. Һәр бүлмәсе бер бүлмәле фатир кадәр дип, бәхетләрен яшермиләр. – *Авт.*) «Башкарып чыга алмабыз, тотынмыйк», – дип шикләнгән иде Алия. Аңлашыла инде, эш күп, вак-төяк мәшәкате дә чыгып тора: йә комбайн ватыла, йә уттай кызу сенаж әзерләү вакыты килеп җитә. Шул арада өй эшләүчеләр өчен материалын алып кайтырга кирәк. Хәзер менә куанып бетә торган түгел. Апаларның да төп йорты бит бу. Бай безнең әни – унөч оныгы, ике оныкчыгы бар. Бөтен кешегә урын җитә бездә хәзер.

Яшьләрне авылда калдыру өчен йорт мәсьәләсен хәл итәргә кирәк. Безнең районда кайбер авылларда төпләнеп калган яшь гаиләләргә йорт төзеп бирү практикасы бар. Бик зур ярдәм дип саныйм мин моны. Һәр авыл шул үрнәк белән эшләсә, авыл җирлеге өчен файдасы да булыр иде. Йорты бар, балалары туа, бакча, мәктәп кул астында. Әнә шулай төпләнеп тә калалар аннары. Хәзер авылларда иң кыйммәт ресурс – кеше. Кеше табуы авыр. Ә эшлим дигән кешегә беркайда да эш бетми. Ферма белән эшлисең килмәсә, кибет ач, башка әйбер уйлап тап. Без менә унга якын егет – яшьтәшләр – авылда төпләнеп калдык. Беребез дә югалып калмады әле. Нигезгә, йортка бәйле авыл кешесенең тормышы. Өе булса, гаиләсе дә, балалары да, эше дә була, бакчасы да, мәктәбе дә саклана.

Тырышлык

– Иртәнге дүрттә эш көнем башлана инде. Шуннан да озак йокласам, көнем бушка узган кебек була. Машинага утырып сөт җыярга чыгып китәм. Авылда миннән башка да сөт җыючылар бар иде барын. Сыерлардан дәвам иткән тагын бер кәсебебез бу хәзер. Шулкадәр сөт җитештереп, аны башкаларга бирәсе килми. Үземә дә файдасы бар, сөт бирүче авылдашларга да. Мин җыя башлагач, сөт бәяләре дә артты. Сөт – авыл кешесенең төп кереме. Бер сыер тоткан йорт сирәктер Субашта. Гомумән, авылыбыз район буенча иң күп хайван тотучы авыл. Өч йортның берсендә – трактор. Халык тырыш бездә.

Һәр чорның үз авырлыгы, үз матурлыгы. Җитешергә, өлгерергә дип тырышасың. Ел саен җәй көне берәр төзелеш бездә. Ферманы бик тиз эшләгән идек. Стеналарын бер көндә күтәреп бетердек. Быел өй белән мәшгуль булдык. Хыяллар бар... Бер ел булса да ял итегез әле, ди әни. Булыр микән? Техника урамда тора – аларга гараж булдырасы иде бит...

Вакытында ял итмәсәң, тормыш үзе туктата кайчак. Узган ел юл һәлакәтенә очрадым. «ГАЗель»нең эшкә яраклы бер төзек җире дә калмады. Ә үзем баш мие селкенү һәм берничә җөй белән котылдым. Шул вакыйгадан соң минуты белән бертуктаусыз өйгә, минем кесә телефонына, әнигә, Алиягә шалтыратып хәлемне белгәннәр. Бөтен районнан! Телефоннар тынмады ул көннәрдә. «Сине никадәр кеше хөрмәт иткәнен шул көнне аңладым», – диде Алия...

Исәнлек-саулык, тазалык – болар авылда яшәүчеләр өчен генә түгел, һәр кешегә кирәк. Калганы безнең кулдан килә!

Ял

– Кешегә ял кирәк. Төзәтеп, карап тормасаң, техника дә эштән чыга. Элек ауга йөри идек. Хәзер аңа да вакыт юк. Менә шушында үзебезнең беседкада дуслар белән җыелып, шашлык, уха пешерсәк, бик рәхәт ял була инде. Уйласак, Казанга аквапаркка да менәбез. Балтачка бик күп концертлар килә, анда да еш йөрибез. Балаларны кем белән калдырырга дигән уй тумый – әни алып кала.

Авылда куйган концертлар да чын артистларныкыннан ким булмый бездә. Андыйларга кеше дә күбрәк чыга. Элегрәк авылда урамнар арасында ярыш формасында концертлар уза иде. Менә иң кызык концерт кайда иде ул! Күрше-күлән белән җырлашып, биеп, сәхнәдә ут уйнаттык инде.

Элек кул көрәше белән шөгыльләндем. Авылда үскән малайлар волейбол, баскетбол, футбол кебек күмәк уеннарны да оста уйный. Без Алия белән тагын бер ял формасын керттек әле. Атнага берничә көн мәктәп спорт залына барып, волейбол уйныйбыз. Безгә башка гаиләләр дә кушылды.

Эшеңнең уңышлы баруы, аның нәтиҗәсен күрү канәгатьлек хисе бирә. Аннары башкаларга ярдәм итүдән дә рәхәтлек табам. Ярдәм сорап килгән бер кешене дә кире борганым юк. Гомумән, авыл кешесе ярдәмчел, намуслы, гади ул. Шәһәрдә күршеләр дә еллар буе берберсен белмичә яшиләр. Ә авылда син һәрвакыт кеше күз алдында. Әти-әнинең йөзенә кызыллык китермәү, намус белән хезмәт итү төшенчәләре буенча авыл һәрвакыт алда булачак.





Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз. Фото һәм видео: Анна Арахамия.



НИЧЕК ТҮЗӘРБЕЗ СОҢ САГЫНМЫЙ?



Эльмира ЗАКИРОВА

Легендар җырчы, РСФСРның атказанган, Татарстанның халык артисты Әлфия Авзалованың тууына – 90 ел. Миңа бик тә җаваплы эш тапшырылды: аның турында язачакмын! Шатландым… Ни дисәң дә, «үдебеднең» Әлфия апа бит – Актанышныкы, якташым. Актанышка кайтса, тәмам актанышлашып, «бед», «нәмә», «җырлаем», «малайкаччаем», дип сөйләшә торган Әлфия апа. «Туган авылым» комплексында урнашкан Әлфия Авзалова үзәгенә, үзе дә яңа гына 60 яшьлек юбилеен билгеләп үткән кызы Зөлфия Авзалова-Нигъмәтҗанова белән очрашуга ашыгам. Әлфия Авзалованың иҗатын саклау һәм үстерү фонды президенты ул – юридик белемле сәнгать кешесе, инглиз телендә иркен сөйләшә… Һәркемнең үз Әлфия Авзаловасы бардыр, минемчә. Беркемнекенә охшамаган, башкаларны кабатламый торган… Минем дә күңелдә әллә никадәр истәлекләр йөгерешә.

«Үдебеднең» Әлфия апа

Мин, 12 яшьлек кыз, беренче тапкыр авылыбыз клубына Әлфия Авзалова концертына бардым. Андагы тәэсирләр әле һаман суынмаган. Ул тавыш, ул җырлары, ул чибәрлеге!.. Беренче бүлектә киң итәкле озын ак күлмәктән, кара чәчләрен артка өеп куйган! Баянга кушылып җырлап өздерә генә. Икенче бүлектә – кыска җиңле кара күлмәктән. «Казан утлары» вокаль-инструменталь ансамбленә кушылып, «Чыгарсыңмы каршы алырга», «Сөясеңме дип ник сорыйсың?», «Тамчылар», «Яратам дисең син…» дип җырлый.

Башлангыч класс укытучыбыз Вәсирә апа белән Әлфия апа дуслар булган, Актаныштa бер фатирда яшәгәннәр икән дип белә идек инде. Вәсирә апаның кызы Фәйрүзә мәктәпкә килеп: «Бүген Әлфия апа бездә куна!» – дип, серне дә тишә, җитмәсә. Классташ кызлары җырчыдан автограф яздырып алуны сорап, Фәйрүзәгә открыткалар биреп җибәрә. Икенче көнне матур теләкләр язылган открыткалар мәктәптә зур вакыйгага әйләнә… Университетта бергә укыган авылдашым Фәйрүзә сөйләгәннәр күз алдында яңара. Әнә, мичтә бәлеш пешә. Мунчадан чыккан Әлфия апа Фәйрүзә янына яткан да: «И-и, салкын

клубларга төшәсе дә килми. Микрофонны гына китереп бирсеннәр иде дә, шушыннан гына җырлар идем», – дип шаярта... Бер килүендә Авзалованың концерт бригадасы Хәнәви Шәйдуллин авылы Табанлы Күлгә китеп бара. Ә Әлфия апаның шарфы Байсарда Фәйрүзәләрдә онытылып кала. Артларыннан куып җитеп, шарфны тапшырулар... Әлфия апа Финляндиядән алып кайтып бүләк иткән джинсы тукымадан Фәйрүзә тектереп кигән матур итәк тә күз алдында һаман...

2005 нче еллар. Бер автобус халык – якташ язучылар, журналистлар, артистлар – Актаныш Сабан туена кайтабыз. Арада Әлфия апа да бар. Төрле кызыклар сөйли. Ялындырмый, җырлап та җибәрә, кызык итеп Илһам абыйны яратып йөрүләрен искә төшерә. Яшь чагында ябык, чандыр Әлфия Илһам Шакировлар белән бер авылга концерт куярга бара. О, артистлар килде дип, зурлап каршы алалар, ә Әлфияне бала-чага дип белеп, клубка кертмәскә маташалар. Кыз югалып кала, ә Илһам: «Керсен, ул безнең фатир хуҗасының төпчек кызы», – дип ирештерә икән. Баянчы Зиннур Гыйбадуллин үзе сизмәгәндә, портфеленә кирпечләр тутырып, юри авырайтуларын, бер фатирга урнашкач, карават астында утырган каз юрганын тартып төшергәннәрен, йөк машинасында авылга килеп төшкәч, чегәннәр дип кабул итүләрен анекдот итеп сөйли. Эч катканчы көләбез. Аның белән озын юллар да кыска тоела – шәп кәеф белән кайтып төшәбез туган якка. Иртәгә Сабантуй буласы көнне кич район мәдәният йортына җыелабыз. Талантлы балалар чыгышы, «Агыйдел» җыр-бию ансамбле концерты... Сәгать төнге унбердә затлы кунак – Әлфия Авзалова чыга сәхнәгә. «Сагындым авылымны, / Кайчан кайтырмын инде?» Зал җыр канатында оча. Гадәттә дәрәҗәле җырчыны аккорд рәвешендә иң ахырдан чыгаралар да шулай, концерт тәмамлана. «Концерт бетә дә инде», – дип өтәләнәм. Янәшәмдә төрле авылларның хуҗалык җитәкчеләре утыра иде. Минем сүзләрдән соң дәррәү көлеп җибәрделәр: «Нәмәдәй бетү?! Әле башлана гына!» – диләр. Һәм, чынлап та, Әлфия апа рәхәтләнеп, сәхнәдә килеш халык белән аралаша-аралаша, сөйли-сөйли җырлый – тәмам түгелә! Ә залдагылар таң атканчы тыңларга да риза!

Шул елларда Актаныш районы хакимияте урынбасары булып эшләгән Фәнис Газетдиновка һәрчак якташ җырчыны каршы алу, озатып йөрүләр йөкләнә.

«Һәр авылда олылап каршы алалар, хөрмәтләп озатып калалар. Китәр вакыты җиткәч: «Әлфия апа, нишлибез инде? Сине бер машина белән алып кайткан идек, күчтәнәчләреңә тагын бер машина кирәк хәзер», – дип шаяртабыз. «Юк, җегетләр, күчтәнәчләремне калдырмыйм! Ике машина белән озатасыз инде», – ди. Ул күчтәнәчләр үзенә эләкми дә! Күршеләр, танышлар, ятимнәр, мохтаҗлар, балалар йортлары, картлар йортлары – һәммәсен Актаныш күчтәнәчләре белән сыйларга ярата иде ул!.. Берсендә хәтта юлда Минзәлә инвалид балалар йортына тукталган да, күчтәнәчләрен өләшә башлаган. «Фәнис балакаем, сезнең күчтәнәчләрнең яртысын таратып бетердем инде. Машина җиңеләйде. И сөенде инде сабыйлар!» – ди. Шундый инде ул Әлфия апа! Балалар белән – балаларча, әбиләр белән – әбиләрчә, председательләр белән председательчә сөйләшә. Кирәк булса, председатель дип тормый, пыр туздырып ташларга да мөмкин! Нишлисең, Әлфия апа бит...»

«Тейлорлар бер читтә торсын! Әлфия Авзалова – үзенә бер!» – дип куям.

...Шул матур хатирәләргә күмелеп, Әлфия Авзалова үзәгенә килеп керәм. Түрдә – сөекле җырчыбыз портреты. Яраткан кызыл күлмәгеннән. Елмайган... Битләре чокырланып тора. Янымда – ике тамчы судай әнисенә охшаган Зөлфия. Ул төс-кыяфәте белән генә түгел, холкы, тавышы, сөйләшүләре, хәтта мәзәк сүз әйтеп көлдерүләре белән үк Әлфия апаны хәтерләтә.

Диварларда – Әлфия Авзалованың төрле еллардагы фотолары. Яшь, чибәр! Ул причёскасы, күлмәкләре... «Эдита Пьехага охшаган!» – дим. «Үзем турында» дигән китабында «Эдита Пьеха минем кумирым иде. Сокланам, кызыгам, их шулай җырларга иде дип хыялланам. Аның кебек озын, яңа модалы күлмәкләр киясем килә...» – дип тә яза бит әле ул. Әнисен тирәннән белгән Зөлфия: «Пьеха гынамы соң! Элизабет Тейлор!» – ди, яратып. Җырчы турында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Казан шәһәре мэры Илсур Метшин әйткән сүзләрне укып, Әлфия Авзалованың бөеклегенә кат-кат инанасың. Каршы якта... Әлфия апаның без көненә әллә ничә мәртәбә тыңлап, сүзләрен ятлап бетергән унбер җырлы пластинкалары. Якташы Минтимер Шәрипович бүләк иткән «Ямаха» япон аппараты. Әлфия Авзалованың тормышы һәм иҗаты турындагы татарча, русча, инглизчә китаплар... Җырчының уникаль артефактлары коллекциясе, фото-аудио, видеоматериаллар... Ә бүген Зөлфия ханым «Сөембикә» журналы өчен әнисе турында эксклюзив хатирәләрен сөйли.

Мин – бәхетле: тач әнигә охшаганмын!..

– 28 декабрь – минем туган көнем. Әни шул көнгә гастрольләрдән кайтырга тырыша иде. Бер атна алдан шалтыратып та куя: «Балалар, Алла боерса, Зөлфиянең туган көненә кайтам», – ди. Ләкин берничек тә әйткән көненә кайтып җитә алмый: йә концертларын сорап куйдыралар, йә машиналары кышкы юлларда батып, ватылып, тоткарланалар. «Кайта алмыйм, тагын ике көнгә калам», – дип хәбәр биргәч, и елыйм инде! Мин бит бала-чага гына, шул 12 яшьләр булгандыр. «Кызым, Яңа елга кайтам! Җәяү булса да кайтам!» – дип юата ул. Һәм менә шундый картина: 31 ендә кайтам, диде бит, дип, апам Гүзәл белән үлә-үлә әнине көтәбез. Кыңгырау шалтырауга инде: «Ура! Әни кайтты!» – дип, атылып барып әни кочагына ташланабыз. «Тукта, туктагыз әле, балакайлар, әйберләрне урнаштырыйк әле», – ди ул. Музыкантлары башта күчтәнәчләр ташый, аннары чыршы күтәреп керәләр! Без тизрәк чыршы бизәргә тотынабыз, әни кухняга ашыга. Менә ул

Репертуарында унҗиде телдә җырлар бар. Тамашачы аңласын өчен, бер-ике куплетын татарча да җырлый.



Әлфия Авзалова биюче Гүзәл Вафина, кызы Зөлфия һәм оныгы Ләйсән белән. 1988 ел.

иттарткычтан фарш чыгара, бергәләп пилмән ясыйбыз. Әни фирменный пәрәмәчләренә дә вакыт таба. Беренче табаны шундук ялт иттерәбез. Зур-зур пәрәмәчләр бит әле! Ул бервакытта да бәләкәй итеп ясамый иде. Балачагында туйганчы ипи ашарга да тилмереп үскәнгә ул! Кәстрүлдә сыер сыйраклары кайный: холодец та ясый әле. Өлгерәме-юкмы – анысы мөһим түгел, ә менә Яңа ел рухы шундук сизелә инде! Әле яңа гына юлдан кайтып кергән әни бит! Ял да итә алмаган. Аклы-каралы телевизордан Образцов театры концертын йә «Божественная комедия»не карый-карый, Яңа елны каршыларга әзерләнәбез! Әнинең бердәнбер яраткан бәйрәме ул. «Голубой огонёк»лар карап, соң гына ятабыз. Ә икенче көнне әни уята: «Кызла-а-ар! Әйдә торың! Яңа ел белән!» – ди. Чыршы астына бүләкләр кую юк иде без үскәндә. (*Көлә.*) Пилмән белән чыршы булгач соң! Әни үзенең туган көннәре тирәсендә тагын гастрольләргә чыгып китә. Бик моңсу булып кала.

* * *

«Характерың белән Әлфия апага охшагансың», – диләр миңа. Әлбәттә, охшаганмын! Характер буенча гына түгел, тышкы кыяфәт белән дә! Гүзәл турында ул: «Бу минем фәрештәм!» – дип әйтә иде. Гүзәл ул тыныч, ашыкмыйкаударланмый. Ә без әни белән йөгерәбез, чабабыз. Безгә тиз булсын! Әни минем турында исә: «Бәләкәй кызым нәкъ үзем: җенгә охшаган!» – ди. (*Көлеп җибәрә.*)

* * *

– 6 яшькәчә русча гел сөйләшмәдем. Әни ике серияле һинд киноларына Гүзәлнең үзен генә җибәрми, мине дә аңа тага. Фильмның бер сүзен дә аңламый утырам. Җитмәсә, нәрсә дип әйтте ул, дип, туктаусыз Гүзәлне аптыратам. «Аннары сөйләрмен, комачаулама!» – дип пышылдый. Ә өйгә кайтканда инде, тегесе яратты моны, монысы яратты шуны, ди дә – вәссәлам! Менә шундый тәрҗемә! «Ничек соң, матур кино булдымы?» – дип кызыксына әни. «Бик матур булды караганда, мин генә бер сүзен дә аңламадым», – дим. «Нишләп, апаң тәрҗемә итмәдемени?» – диюенә каршы, Гүзәл: «Әни, анда йә тәрҗемә генә итеп утыр, йә кино кара инде! Тамашачылар янында сөйләшеп утыру уңайсыз», – дип куя.

* * *

– Мин Равилгә кияүгә чыкканда, әни Әстерханда гастрольләрдә иде. Кайтам диган иде, әмма кайта алмады. Әни Илһам абыйга шалтыраткан. «Карале, Илһаметдин, мин гастрольдә. Зөлфияне котларга һичьюгы син бар инде», – ди икән. Ул чакта туй үткәрмәдек. Өйдә генә утырдык. Әнинең беренче ире – Гүзәлнең әтисе – хатыны белән килде. Гөбәдияләр, пироглар күтәреп килгәннәр. Табынны тулысынча алар әзерләде. Менә шулай дусларча, туганнарча мөнәсәбәт. Булган, үткән, без дус булып калырга тиеш, ди иде әни. Иремнең дуслары, минем иптәш кызым Инга килде. Илһам абый чәчәкләр күтәреп керде. Матур итеп сөйләшеп утырдык. Әни әйтмешли, чын туебыз унөч елдан соң гына булды. (*Елмая.*)

* * *

– Әнине чагыштыралар инде Хәния белән дә, башка җырчылар белән дә... Хәния ул хет җырлары, таланты, тырышлыгы белән акча эшли алды. Ә болар бит?! Шыгрым тулы зал! Көнгә ике-өч концерт. Менә Төмәндә булган хәл. Үзем алып барган идем концертларны. Анда коточкыч зу-у-ур, 2 мең тамашачы сыйдырышлы Нефтьчеләр сарае бар. Советлар Союзында андыйлар юк иде әле 80 нче елларда. Биш концерт көнгә! Безгә биюче Ирина Сабитова килгән иде, аның беренче гастроле. Биш концертта чыгыш ясыйсын ишетеп, телсез калды! «Мин юлдан гына, юынмаган да», – ди. «Нинди юыну?! Менә үтүк, бар йөгер!» – дибез. «Чәй эчәләмме соң?» – ди бичара. «Тиз генә эч!» – дип ашыктырабыз. Ышанмассыз! Беренче концерт иртәнге унда башланды, соңгысы төнге бердә тәмамланды. Спорт сарае директоры: «Әлфия апа, бераз кыскартмассың микән?» – ди. «Юк, кеше акча түләп килгән бит», – ди әни. Ул акчаның бераз проценты үзенә булса икән! Юк бит! Ике сәгать ярымлык концертта сәгать ярым берүзе җырлый! Бер минут та кыскартмый.
Биш сеанс концерт, шыгрым тулы тамаша залы! Җитмәсә, анда әле руслар да килә иде. Запискалар ява сәхнәгә.
«А вы не знаете какую-нибудь русскую песню? Нам нравится как вы поёте». Әни кычкырып укый да музыкантларына ым кагып ала: «Егетләр, әйдәгез «Волга-речка»ны», – ди. Аннары төрле милләт кешеләре утырганын белгәч, һиндча да, гарәпчә дә, казакъча да, үзбәкчә дә, марича да, хәтта чехча да җырлый. Башкортчасын әйтеп тә торасы юк инде. «Шәл бәйләдем», «Их, Өфө калаһы», «Әлмәлек»ләр... Ул чәчәкләр! Кыш көне! Төмәндә бит әле! Нindиләре

генә юк! Әни кочагы белән колонка өстенә куя бара… Менә бу колонканы Минтимер Шәрипович биргән иде… Беренче концерт тәмамланды гына. Кешеләр чыкканчы ук икенче сеанснықылар кереп тула. Икенче концерт – тагын чәчәкләр! Әни әйтә: «Тукта, бу чәчәкләрне мин күрдем бит инде… Шушындый ук букет, шул ук розалар…» Бактың исә барабанчы Марсель теге концерттагы чәчәкләрне алып чыгып, тиз генә сатып керә икән! Менә шундый бизнес! Әни өченче концертта гына серен төшенде. Музыкантын шелтәләп тә алды. Ә Марсель: «Нәрсә булган, Әлфия апа, алар шиңә бит хәзер», – дип аклана. «Ярар алайса, кергән акчага бөтен бригадабыз белән бергә ресторанга барырбыз», – диде әни. Әнә шул керем акчасына икенче көнне ресторанда ашап чыктык.

* * *

– Түбәннән киттек Тобольскига. Минем белән 5-6 яшьлек кызым Ләйсән дә йөри иде әле гастрольләрдә. 1987 нче еллар бу. Ирем Равил Әфганстанда. Кабулдагы үзәк госпитальдә реабилитация буенча баш белгеч иде ул. Күңелсезләнеп ятмагыз, дип, әни гастрольгә дәште. Бик киң күңелле, юмарт иде әни. Колхозларда йөргәндә бирәр бот ит бирсәләр, шуны чаптыра һәм берәү дә үпкәләмәслек итеп тигез итеп бүлешә. Арты белән борылып баса да, бу кисәк моңа, монысы шуңа, дип, төркемендәгеләрне атап чыга. Урта Азияләргә гастрольгә чыгып китсәк, ким дигәндә ике ай ярым кайтып керми йөри идек. Икешәр көн поездларда барабыз. Ашарга юк, су юк… Әни спиральле бәләкәй генә плиткада пәрәмәчләр пешереп, бөтен коллективны ашата иде. Камырлар куеп, уксустан бушаган шешәне уклау итеп җәеп пешерә!

* * *

– Әнине Финляндиягә татарлары үзләре чакырган иде! Ә әни: «Нигә үзем генә, әйдә тагын берничә кешене алыйк», – ди. Ахыр килеп, әнине калдырдылар, үзе тәкъдим иткән кешеләр китеп барды. Менә шул чакта әнинең бик хәтере калды – бик үрсәләнеп елады…

Ике мәртәбә күрдем әнинең елаганын. Берсе – шушы хәлдән соң, икенчесе… Әнинең бик яраткан кешесе бар иде. Шул өйләнгәч елады ул. «Аның белән бергә буласыбыз юк», – дип, үзе үк әйтә иде инде. Соңыннан очрашырга теләмәде әни: «Миңа кирәкми, Аллам сакласын, кешенең каргышы төшәр», – диде. Бик порядочный иде әни! Гайбәт сөйләмәде, кеше сүзен йөртмәде. Үзбәкстан, Әрмәнстан, Азәрбайҗан – кайларга гына бармады. Һәм һәрчак яңа җырлар белән сөендерде. Узган ел боларын җырладым, хәзер икенче җыр кирәк, ди иде. Чирләгәндә дә эшли иде, температуралы килеш сәхнәгә чыга. Бервакыт мин Сәмәркандта бик каты авырдым. «Әни, башым авырта», – дим. «Даруларыңны эч. Кеше акча түләгән. Синең чирләвең беркемгә кирәк түгел», – диде әни. Үзенә дә, безгә дә бик таләпчән булды ул.

* * *

Кулаткыда ике концерт куйдык та, автобуска аппаратураларны төяп, Ульяновскига киттек. Анда поездга утырып Уфага, Татарстан әдәбияты һәм сәнгате көннәренә барырга кирәк иде. Автобуста барабыз. Җәй булса да, төннәр салкын. Әнинең аягы туңа башлады. «Арыдым, мин артта ятып барыйм әле», – ди. «Әлфия апа, анда кәгазь капчыклар бар, аягыгызны шуңа тыгыгыз, без салкында шулай эшлибез – булыша», – ди шофер. Берзаман арттан әни: «Әй, чуәкләр! – «Чуваки» сүзен шулай татарчалаштыра – карагыз миңа», – дип кычкыра. Ул капчыкка тәмам чумган! Шул кыяфәте белән безне дә көлдермәкче. Бөтенесе арыган инде. Ә әни арый торганнардан түгел. Аңа һаман шаяртырга, көлдерергә булсын! Гел юмор белән сөйләшә иде ул. Кәефе юкларның да күңелен күтәрә белде. «Уйга чумгансыз, ярый аннан чыгып булса, ә булмаса, нишләрсез», – дия иде. Үзе борчылса да, башкаларның күңелен күрергә тырышты. Ульяновскида ике сәгать поезд көттек. Аппаратураларны калдырып булмый бит. Әни ял итә ала иде югыйсә. Юк, ул һаман музыкантлары арасында. Берзаман игълан итәләр: поезд икенче юлга килә, тукталыш ике минут, диләр. Күтәренеп, рельслар аркылы йөгерәбез. Ике минут эчендә бөтенесен вагонга ташып бетерергә кирәк. Тамбурда атлар урын да юк: тонналы аппаратуралар белән тулган. Поезд кузгала. Әни: «Барысы да утырдымы?» – дип, бөтенесен барлый. Интегә-интегә, чәйгә дә тилмереп, бер тәүлек дигәндә, ниһаять, Уфага килеп җитәбез. Ә анда: «Хәзер Белорецкига очачакбыз», – дип каршылыйлар. Вокзал, аэропорт. Тагын ашык-пошык самолетка төялүләр… Арып йоклап киткәнбез. Берзаман ишекләр ачыла, Сәйдәш маршы яңгырый, пионерлар басып тора. Кымыз белән каршылыйлар. «Уф Аллам! И Ходаем! – ди әни. – Нинди кымыз?! Егылам бит хәзер!» Белорецк кунакханәсе, озын завод, чакрымнарга сузылган цехлар, һәйкәлгә чәчәкләр салу, кич – концерт. Икенче көнне Учалыга – Европа белән Азия кисешкән җиргә алып киттеләр. Юрталарга алып керделәр, атларга атландырып йөрттеләр… Әни Башкортстанны бик ярата, андагы табигатькә соклана иде. Ләкин ахырдан барыбер сагынып Казанына кайта. Үлеп ярата иде Казанны!..

…Зөлфия ханым Әлфия Авзалова иҗатын саклау һәм үстерү фонды эшчәнлеге белән таныштыра. Фондның шигаре дә үзенчәлекле: «Музыка – дөнья халыклары теле» дип атала ул. 2021 елның җәендә ачылган Әлфия Авзалова исемендәге үзәктә җырчы исемендәге вокал студиясе эшләп килә, анда укыту һәм дөньякүләм сәхнәгә күтәрү өчен талантлы яшьләрне кабул итәләр. Бөек җырчыга багышланган Халыкара талантлар фестиваль-конкурсы ике елга бер тапкыр уздырыла. Беренче фестиваль лауреатларын, әнә, Зөлфия ханым Лос-Анджелеска ук алып барган. Яшь җырчылар – Әлфия Авзалова варислары – Сабантуй күрсәтеп, Американың 38 иленнән килгән катнашучыларны таң калдырып кайтканнар. Анда, әлбәттә инде, Әлфия Авзалова җырлары да яңгырагандыр! «Туган ягым – гөлләр иле», *«Яшьлектә – сөйгән яр, / Сагындым, килеп ал»* дип тә, *«Күрешергә ничә еллар бар, / Ничек түзәрмен соң сагынмый?»* дипләр дә… Ул җырлар, ул моң, Әлфия апага гына хас аһәң, аның ритмнары һаман безнең күңелләрдә яңгырый. Сагындыра…

Фотолар: гаилә архивыннан.



Флёра ШӘРИПОВА

Композитор, рәссам, шагыйрә, автор-башкаручы... Әнә шундый бәхетле иҗатчы ул Флёра Шәрипова. Башкортстанның кыялы, урманлы гүзәл табигатеннән – илһам, җырга оста әти-әнисеннән – моң, хаҗ кылган бабаларыннан иман алып үскән кызга бу дөньяда кешеләргә яктылык, матурлык өләшү вәкаләте тапшырылган, күрәсең. Балачакта укытучы булырга, дүрт бала табып үстерергә хыяллана Флёра. Бер баласын, һичшиксез, композитор, икенчесен – рәссам, калган икесен җырчы һәм шагыйрь итеп күрәсе килә. Һәм ул хыяллар чынга да аша! 300 дән артык җыры, ике шигырьләр китабы, күп картиналары бар. Аның җырлары Айдар Галимов, Алсу Әбелханова, Резеда Шәрәфиева, Элвин Грэй кебек популяр җырчылар репертуарын бизи.

САГЫНАСЫМ КИЛМИ... САГЫНАМ!

Назлы күңел

Минем күңел сабый бала кебек:
Йолдыз күзләп, күккә үрелә.
Яхшы сүзгә көлә чишмә кебек,
Каты дәшсәң, яшькә күмелә.

Минем күңел диңгез өсте кебек:
Тын дулкында кояш йөгерә!
Каты дәшсәң, күтәрелә давыл,
Үксеп елап, ярга түгелә.

Минем күңел күк гөмбәзе кебек:
Иртә таңнан нурга күмелә!
Каты дәшсәң, кара болыт каплый,
Яңгыр булып хисләр түгелә.

Минем күңел гөл-чәчкәдәй назлы:
Ачы җилдәй каты тимә син.
Салкын сүзләр белән дәшә күрмә,
Сакла берүк, кырау тимәсен.

Соңладың...

Ачы җилләр җанны кыерсытты,
Шул чакларда янда булмадың...
Җылы сорап хәзер килдеңмени?
Күзләр җитте инде... Соңладың...

Явызларның сүзе җанны өтте,
Яклар өчен сүзең булмады.
Дәшми генә яннан карап үттең,
Авыр чакта бирми кулларың...

Яланаяк бозлы җирдә тордым –
Җан өшеде, ләкин туңмадым.
Күңелемнең якты нуры һаман
Гел эретә килде бозларын.

Тозакларын салып, читен тормыш
Сынаганда янда булмадың.
Җылы сорап нигә килдең әле?
Кирәкмисең инде! Соңладың!

Кемдер ярата

Өзелә дә төшә җиргә яфрак,
Болыт каплап алган күгемне.
Сизелми дә үтеп киткән җәйләр,
Күзләр килеп җиткән түгелме?..

Салкын җилләр тота иңнәремнән,
Җылылыгы җәйнең сүрелде.
Сорап тормый килеп җиткән дә көз,
Яңгыр белән юа күңелне.

Сорап тормый яңгырлары көзнең,
Барыр юлны буйый сагышка.
Язлар, җәйләр ерагая бара,
Гомер кышкы якка авыша.

Җитте көзләр, якынайды кышлар,
Яфракларны җилләр тарата...
Чәчем агара дип үкенмим, юк,
Кышны да бит кемдер ярата!

Сагынам...

Куркам синнән... Син тагын да мине
Эретерсең, җанны исертеп...
Ялгыз калдырырсың җилләреңнән
Әчесенә мине, илертеп!

Җан тартыла сиңа, нигә икән?
Ә йөрәктә – сөю кузлары...
Эрер микән, эри алыр микән
Сагышларның сары бозлары?

Ышаныйммы сиңа? Ышанмыйммы?
Очрашыйммы? Әллә юк микән?
Синең кебек җанга кергән кеше,
Җан әрнеткән кеше юк бүтән!

Синең сүзләр, күзләр, иреннәрең
Нигә икән шулай исертә?
Җылы назын биреп алдата да,
Салкын бозы җанны илертә...

Тик нигә соң, онытырга булгач,
Сине исләп, канат кагынам?
Нигә генә кердең син җаныма?
Сагынасым килми... Сагынам!

Йөрәгемә кагылдың

Җанны җылытырлык сүзләр белән,
Йөрәгемә килеп кагылдың.
Җандагы боз кинәт ватылды да,
Ташу булып хисләр агылды.

Әллә уты өтә йөрәгемнең,
Әллә бозы шулай яндыра?
Агыла да хисләр йөрәгемдә,
Тырный-тырный эзләр калдыра.

Аңлау кыен... Әллә уяна ул,
Әллә куркып, өшеп, калтырый?
Әллә боз кылчыгы яна анда?
Әллә яшь тамчысы ялтырый?

Кагылдың да кинәт йөрәгемә,
Хәзер анда хисләр ташкыны.
Шул ташкыннар арасында ташлап
Ялгызымны гына калдырма!

Күзгә калган хисләр бозлы шул ул...
Эретүе аны кыендыр...
Татлы да ул, газаплы да икән,
Сөюләргә күзен сыену.

Сөю балкышы

Син йөрисең үзең еракларда,
Янәшәмдә тоям сулышың.
Җаным ялгыз, ләкин хыялымда
Синең белән үтә тормышым.

Әлдә мәхәббәт бар бу дөньяда,
Ләззәтләрен тоеп янарлык!
Хисләремнең нуры шундый якты –
Йөрәкләргә юллар салырлык!

Төн шомнарын ерып тарата да,
Синең җанга барып бәйләнә.
Аңламаслык серле сихри моңда,
Оҗмахларга дөнья әйләнә.

Серле төннең сихри әкияте,
Җаным сагышының алкышы!..
Чынбарлыкта син юк, син – еракта,
Тик йөрәктә – сөю балкышы!

Табигать тә елый

Яңгыр кебек назлы хисләр яуды,
Болыт булып сөю килде дә.
Җанкаема күлдәй сөю коеп,
Сагыш салып китте күңелгә.

Әллә җилләр урман белән уйный,
Әллә минем җаным дулыймы?
Тәрәзәдән әллә тамчы тама,
Әллә җаным үксеп елыймы?

Пыяладан сулар агып төшә,
Сагыш карый җанга, үрелеп.
Сөю ачыларын татыгандай,
Табигать тә елый, түгелеп.

Пыяла

Ватык пыяла без икәү,
Ялтырыйбыз кояшка.
Син бер якта ут янасың,
Мин ялтырыйм бу якта.

Ватыгын шәйләми кеше,
Балкышын гына күрә.
Пыяла ничек телгәнен,
Бары безнең җан белә.

Син дә ватык бер пыяла,
Мин дә ватык пыяла.
Бездән башка ярчыкларын
Кем соң бергә җыяла?

Кырларын туры китерсәк,
Бер бизәк булыр иде.
Төрле төскә кереп янып,
Нурларга тулыр иде.

Бәлки, күз явын алырдай
Бер савыт булыр иде.
Мөлдерәмә булып аңа
Тик бәхет тулыр иде...

Ерактан ялтырап ята
Җирдә ватык пыяла...
Кырлары җанны телсә дә,
Кояш төшсә, нурлана...

Ватык пыяла без икәү...
Пыялабыз, пыяла...

Үткәннәрдән сөю эзләмә

Синең үткәннәрең, минем үткән –
Ике сукмак, ике юл икән.
Кушылгандай кебек иде язмыш,
Ялгышканмын, аерым икән.

Синең язмыш җебең башка ярга
Өзелмәслек итеп бәйләнгән.
Адашкан да сөю үткәннәрдә,
Хатирәгә хәзер әйләнгән.

Яшьлек белән бергә үткән сөю
Матур җырдай калсын исләрдә.
Син яратам диеп ялгышасың,
Тик хатирә синең хисләрдә.

Моңсуланып, җаным, моңсуланып,
Үткәннәрне берүк күзләмә!
Моңсу, җаным, миңа...
Моңсу, җаным...
Үткәннәрдән сөю эзләмә.

Яратам сине, тормыш!

Җаным белән җирне кочып алып,
Сөюемне күккә очырам!
Бары гөлләр ишетерлек итеп
«Мин яратам!» – диеп кычкырам.

Ашыкмаска иде, ашыкмаска...
Бу дөньялар тулы могҗиза!
Тик тизлекне әзәйтәсе иде,
Калганына күңелем риза...

Без дөньяда бары кунак, беләм,
Мәңгелеге көтә тупсада...
Тик күңелнең һич китәсе килми
Өермәдәй җилләр купса да.

Ашыктырма, тормыш, ашыктырма,
Акрын гына атлыйм юлымнан.
Кошлар сайравыннан моңга тулып,
Яшәү ләззәтенә коенам.

Яланаяк әле үтәсем бар,
Сукмакларны барлап узасым...
Яңгыр җирне тазартканда җырлап,
Җилләр белән дулап тузасым!

Ялмап алып җирнең назлы сутын
Саласы бар җанга тутырып.
Ашыктырмагызчы! Бер елыймчы
Сәхрәләрдә ялгыз утырып.

Янам диеп канатланган була
Җан төбендә калган очкыннар...
Күзге җирне кочып: «Тормыш, сине
Мин яратам!» – диеп кычкырам.

Икебез ике ярда

Аралар да ерак түгел кебек,
Теләгәндә була узарга.
Бары адым гына ясарга да,
Бары кулны гына сузарга.

Икебез ике ярда,
Уртада – язмыш елгасы.
Сиңа – минем ярга,
Миңа – синең янга
Ничек йөзеп чыгасы?

Ике ярда икәү ялгыз гына,
Моңсуланып суга багабыз.
Теләгәндә үтеп булыр кебек,
Тик үтәлмәс ерак арабыз.

Язмыш агымнары көчле шул ул,
Каршы йөзеп булмый агымга.
Төнне ярып яна ике учак
Язмышларның ике ярында.



БОРЫНГЫДАН КИЛГӘН ГАДӘТ УЛ...

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе белән «Сөембикә» журналы ел дәвамында «Килен һәм кайнана» бәйгесен уздырды. Бәйгенең бурычы – милләт анасы булырдай киленнәрне, зирәк, акыллы кайнаналарны барлау; килен белән кайнана мөнәсәбәтләре аша матур гаиләләрне укучыларга күрсәтү иде.

Редакциягә килгән хатларда акыллы киңәшләр дә, әби-бабалардан күчкән традицияләрне саклау үрнәкләре дә бар иде. Ул хатлар журнал битләрендә, сайтта урын алды. Җиңүчеләр ике номинациядә билгеләнде.

«Икенче әнием» номинациясендә җиңүчеләр:

Рәхилә Зәйнуллина һәм аның кайнанасы Фоадия апа (Балтач районы, Кариле авылы);

Равия Шәймуллина һәм аның кайнанасы Клара апа (Арча районы, Курса Почмак авылы);

Гөлнара Ибраһимова һәм аның әнисе Гөлсәрия апа (Арча районы, Кышкар авылы).

«Килен – кайнана туфрагыннан» номинациясендә җиңүчеләр:

Энже Фәйзрахманова (Казан шәһәре);

Диләрә Гыймранова (Әлмәт районы, Кичүчат авылы);

Ләйлә Галимуллина (Чаллы шәһәре).





Татарстан Халыклар Дуслыгы йортының концертлар залында әнә шул җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы узды. «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе урынбасары Эльвира Әхмәтова җылы сүзләре белән котлап, бәйрәм чарасын ачып җибәрде. Җиңүчеләргә затлы оренбург шәлләрен һәм дипломнарны Татарстан Дәүләт Советы депутаты Камил Ногаев тапшырды. Камил Әсгать улы һәр катнашучыны җылы итеп котлады, үзенең дә гореф-гадәтләр сакланган ишле гаиләдә үсүен искә алды. Бәйрәмебезгә Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Готыф улы Әхмәтов үзе килә алмаса да, бәйгедә җиңүчеләребезне котлап, шәхсән үз исеменнән махсус бүләкләр җибәргән иде. Жюри рәисе Татарстанның халык укытучысы Камәрия Хәмидуллина, хатларда язылган йөрәккә үтәрлек юлларны укып, бәйрәмне тагын да җылытып җибәрде.



Асия Дирзизова (Биектау районы, Күлле бистәсе), Фәнзилә Хәйриева һәм аның кайнанасы Халидә апа (Актаныш районы, Иске Байсар авылы), Римма Җаббарова (Әгерҗе районы) махсус бүләкләргә ия булды. Аларга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Мәрхәмәт-Милосердие» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе бүләген – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, «Бала-Сити» мәктәбенең генераль директоры Альбина Насыйрова, Бөтендөнья татар конгрессы бүләген – Бөтендөнья «Ак калфак» татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы рәисе Кадрия Идрисовна, Бөтенроссия «Татар гаиләсе» иҗтимагый фонды бүләген аның директоры Миләүшә Гайфуллина тапшырдылар. К. Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театры да Эльвира Идиятуллина һәм аның кайнанасы Фидалия апага (Казан шәһәре) үз бүләген бирделәр.



1994 елда «Сөембикә» журналы уздырган «Киленбикә» бәйге-тамашасында катнашкан Зөлхия Миңнеханованың килене – җырчы Гүзәлем дә «Килен һәм кайнана» проектында катнашты. Килен һәм кайнана – Зөлхия ханым белән Гүзәлемнең чыгышлары безнең җиңүчеләребезгә тагын бер җылы бүләк булды.

Айгөл Бариева, Гөлшат Имамиева, Рөстәм Асаев җырлары исә бәйрәмне тагын да ямьләде.



Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.
Фото: Анна Арахамия.























Дилбәр БУЛАТОВА

Дилбәр Булатова хикәяләре матур теле, ихласлыгы, җылылыгы белән үзенә тарта – йотылып укыйсың, язучы тудырган дөньяда рәхәт мизгелләр кичерәсең, геройларын яратып өлгерәсең. Китаплары, кулдан-кулга йөреп, тәмам таушалып бетә – язучы өчен бәхет шулдыр! Дилбәр рәссам да, психолог та булып әсәрләрендәге якты дөньяга алып кереп китә. Сагындырган балачакка, кышкы авылга кайтасыгыз киләме? «Кунак мунчасы» хикәясен укып карагыз әле. Күңел халәтегезгә бик тә туры килер ул.

КУНАК МУНЧАСЫ

(Хикәя)

Ә без кунакка китеп барабыз. Аръякка. Нәнәйләргә, мунча керергә.

Кинәт... Зәңгәрсу-кара күк йөзе тибрәлеп китә, эре-эре йолдызлар урыннарыннан кубып җиргә коела башлый дисәм... әти мине күтәреп үзенең иңбашына утырткан, имеш. Миңа, 5 яшьлек олы кызга, әти җилкәсендә бару оят та кебек. Тик бу хакта бөтенләй онытам да, тәү күргәндәй, якягыма күз салам. Моңарчы астан, җирдән баш күтәреп, авыз ачып карап барган дөнья кинәт кечерәеп калган! Минем түгел, әтинең дә колачы җитмәс каеннар тәбәнәкләнеп җиргә чүккәннәр; әллә кайда, аста, әтинең сүчинкәләре астында, баш әйләнерлек түбәндә җемелдәп яткан кар, миңа ачуланып теш шыгырдата.

Безнең янәшәдән атлаган, кышкы пәлтә, башына бәйләм башлык кигән әниемә күз салам. Ул юрганга төрелгән энемне күтәргән. Беләбез юрган хәлләрен – кысыклыгы аның, уңайсызлыгы... Ә әтинең иңбашында юрган михнәтләренең берсе дә юк.

Салам, силос кисәкләре чәчелеп яткан чана юлы тап-такыр. Ара-тирә тупчыклар – ат «койрыгыннан» төшеп калган шарчыклар очрый. Әти кайчак аларны тибеп-тибеп җибәрә. Әтинең муенына ныграк ябышам, танавым аның колакчынлы, зур төлке бүрегенә килеп төртелә, тик мин куркып та карамыйм. Ник куркыйм, минем әти – авылдагы иң көчле, иң озын кеше. Һәрхәлдә, мин белгән кешеләр арасында. Иң кырысы да. Шуңа күрә мин сыңар өн дә чыгармаска, әтиемнең ачуын кузгатмаска, югарыдагы рәхәт мизгелләремне ничек тә озаккарак сузарга телим.

Кинәт йолдызлар тагын урыннарыннан куба, тик бу юлы алар дәррәү өскә чөеләләр – әтинең озын куллары мине юл читенә төшереп куя. Кар өстендәге юка гына бозлы ялтыравык элпә мине күтәрерлек түгел. Батуым бер хәл, атлап китә алмый этләнәм. Әни кулындагы энем әти кулына күчә, әни мине кар эченнән тартып алып, әйләнә-тирәдәге бердәнбер таяныч – көндезге җепшектән соң төнгелеккә катып киткән юлга бастыра.

Елга аша чыгасыбыз бар, шуңа төшерделәр инде мине кулдан. Уң якта өңрәеп, кап-кара шәүлә булып тегермән өе кала. Ул күперне тегермән күпере дип атыйлар, ат күпере дә диләр, чөнки аңардан җигүле ат белән дә чыгып йөрмәле.

Безнең инеш, бәләкәй генә булса да, бик йөгерек, бик җитез үзе. Шуңадырмы, ярларын уеп, ашап бетереп, әллә кайдан, төптән агып ята. Шуып төшәргәрәк исәп бар, тик картәтием быел гына алып биргән өр-яңа кара пималарым тыңлап та карамый. Ирексездән, йөгереп төшеп китәм.

Егылмыйм, абынмыйм – белəм бу төшнең холкын. Дөбер-дөбер килеп, такта күпердəн чыгабыз. Күпер астыннан, кар каплаган инешнең чылтырап агып яткан тавышы ишетелə. Үзалдына нидер сөйлəнə-сөйлəнə каядыр китеп барган эшлекле генə, үз-үзеннəн бик канəгать кенə тере бер җан ияседəй тоела ул миңа. «Прибет!» дим аңа, дус кызларыма дəшкəндəй иттереп.

Карасам, əтилəр теге ярга инде менеп җитеп баралар. Җан-фəрманга мин дə алар артыннан чабам. Бая шумый тискəрелəнгəн пималарым хəзер таеп интектерəлəр. Əтилəр инде яр башында. Безнең əти дə, əни дə бик иркəлəп, мəмилəнеп тора торганнардан түгел, көтми китеп барулары да бар. Ашыгудан абынып егылам, гарьлəнеп елап җибəрəм, үзем һаман мүкəлəп булса да өскə үрмəлим.

Менеп җитүемə, их, нинди бəхет (мин əлегə бу сүзне белмим, лəкин аның ни икəнен, нинди икəнен əтинең киң җилкəсендə тоям), йолдызлар тагын елпылдап җиргə коела; ярның ике ягын тутырып үскəн, өнсез генə, сабыр гына утырган каеннар тагын кечерəеп калалар...

Ат «дубыр»ын уң яклап урап, нəнəйлəргə турыдан киттек. «Бу як басудагы салам эскертлəрен ачтык», – ди əти. Əни үзебезне кайгырта: «Халыкка салам бирмилəрме əле?» – ди. Мин əтинең ни дип җаваплавын ишетмим, ат абзарын тыңлыйм. Əчкелтем силос исе аңкый. Утардагы берничə каракучкыл шəүлə, бездəн өркеп, пошкырынып, аргы башкарак күчеп баса. Дубырның бүрəнə стенасы аша дөпелдəгəн, кешнəгəн, тибешкəн тавышлар ишетелеп кала.

Нəнəйлəргə барып җитүебез сизелми дə. Йортның урам як өч тəрəзəсе ялт итеп балкып тора, мунча тəрəзəсендə ут яна, күтəрмə өстендəге, тыштагы лампочканы да кабызганнар.

– Башыгызга менгерегез əле баланы, – ди, гөр-гөр килеп безне каршыларга чыккан нəнəй. – Төшерəлмəссез дə аннары...

«Тəхет»емнəн колак кактыралар. Күтəрмə төбендə яткан каз канатын алып, əтиемнең сүчинкə йөзенə кунган, сары кайры тун чабуына ябышкан карларны себерергə тотынам. Əнинең буркиларына бозланып кар сарган. Канатның сырты белəн дə алдыралмагач, себерке сабы белəн кыргычлыйм. Үземнең пималар да шул рəвешчə тазартыла. Аякларыбызны бер-берсенə бəрə-бəрə, пима төплəрендəге карны идəндəге паласка коеп калдырырга тырышып, караңгы чолан аша үтеп, өй ишеген ачабыз.

Һəм якты, җылы, парлы дөнья кочагына чумабыз. Токмачлы аш, бəлеш, компот исе, тагын əллə нинди тəмле ислəр болыты чорнап ала. Тунымны, башлыгымны салып элгечкə элəм дə түргə йөгереп кереп китəм.

– Салма пимаңны! – дип кычкырып кала нəнəй. Əйтмəсə дə белəм инде, кышын пималарны нəнəйнең мəңге салдыртканы юк, «идəн суык, шул килеш йөрегез», дип, чыккан саен тукый.

Олыларда минем кайгы түгел хəзер. Əни түрдəге караватта энемне юрганнан арындыра. Əти өстəл артына кереп кунаклаган. Табын белəн кəбəркə арасында бөтерелгəн нəнəйнең бөтен игътибары əти белəн əнидə. Ирек! Азатлык! Ачуланучы да, «тегелəй ит, болай ит», дип тарткалап торучы да булмаячак беразга!

Бəлəкəй як белəн олы як арасындагы пəрдəне аерып, ике якка ачылмалы ишекне этəм һəм биек тупсадан олы якка атлап төшəм. Пəрдəдəге кып-кызыл алмалар, мəмрəп пешкəн чиялəр коелырдай булып тибрəнеп калалар. Сары шифоньер башындагы шахмат тактасы белəн гармун идəнгə төшеп кунаклаган. Əй лə, идəнгə түгел, идəнгə җəелгəн юрганнарга, пальто-фуфайкаларга. Идəн суык булгач, без кунакта чакта нəнəй аларны идəнгə түши. «Җəллəп торырга əле, аунагыз рəхəтлəнеп», – ди.

Чүпрəк-чапракка безнең нəнəй кебек һушы киткəн башка кеше бар микəн? Биек, зур итеп салынган йортының бизəлми калган җире юк диярлек. Олы як тəрəзəлəрдəге пəрдəлəрдə җилəк-җимешлəр тагын да җетерəк. Мич өсте тирəли һəм урта стенада ике яктан да кыска пəрдə – кашагалар, караватларны чит-ят күздəн яшереп, шау чəчəк чыбылдыклар элелгəн. Почмакларда – җете сары җирлеккə кып-кызыл эре мəклəр төшкəн, чегəннəрдəн сатып алган япмалар. Тегү машинасы өстəлендəге телевизор, түр өстəлдəге зур сары радиоалгыч өстендə ялтыравык яулыклар.

Мин туп-туры гармунга таба атлыйм. Ул да түгел, əни бу якка кертеп җибəргəн энем дə ава-түнə гармунга килеп тотына. «Көтебрəк тор əле, апаем, сиңа хəтле апаң бар монда!» Лəкин тарткалашып, елашып өлгермибез, əни безне быжгытып мунчага җыя башлый.

Кызарып-пешеп абыйлар кайтып керə. Олы абый, гадəттəгечə, җитди итеп, кул биреп күрешə. Кечесе үчеклəргə, ирештерергə бик маһир:

– Һо-о, аръяклар чыккан! Нишлəп утырасыз, таегыз мунчага! – ди. «Таегыз» – аның иң яраткан сүзе. Мəгънəсен генə аңлап бетермим. Тая-тая барырга ихатада боз юк та инде!

Мунча керергə яратмыйм мин. Ыс, төтен исе! Идəненең салкынлыгы! Чəч юганда əбизəтелне күзгə кергəн шампуне! Мунчаласы тимерчыбыктан, себеркесе таяктан ясалгандай тоела башлый азакка таба.

Əни мине юындырып, коендырып, өстемə тастымал каплап, ишек төбендəге киң эскəмиягə утыртуга ишек ачыла. Түргə йөгереп кереп киткəн куе пар болыты өстендə энемне күтəргəн əти күренə. Энем дə мунчаны өнəми: юрган эченнəн тоник кына булып елау тавышы ишетелə. Аның урынына мине яткыралар.

Кечкенə юрганга аякларым сыймый. Сузмыйча бөклəп кайтырга кушалар. Түземлегем ярты юлга гына җитə – тəпилəремне салкын һава өтеп-пешереп ала.

Без кайтканны нəнəй ишек төбендə көтеп торган. Əти мине караватка илтеп сала да чыгып китə.

– Парланып ят бераз! – ди миңа нəнəй. Юрганнан серəеп чыгып торган аякларымны күреп, кеткелдəп көлə: – Үстең инде, үстең. Сөбханалла! – Һəм миңа алмаш киемнəремне кидерə башлый. Əни күлмəгемне оныткан. Ыштаннан гына булуыма гарьлəнеп елап җибəрəм. Малай кебек йөримме инде хəзер? Бəлəкəй абый клубтан кайтып керсə, «малай, малай, бер бидрə тоз ялый» – дип, күземне дə ачырмаячак. Нəнəй мине юатырга була, капкачлы зəңгəр эмаль бидрəдəн компот салып бирə. Чынаяк төбендə төшлəре дə бар. Йөземнəр, балан-милəш, əллə нəрсəлəр! Тагын компот соравыма:



– Җитәр, мунчадан кайту белән күп эчмиләр, – дип кырт кисә. Ул үзе, мунчадан аһ-ваһ килеп кайтып керүгә, бер-ике чеметем тоз кабып, түшәгенә авучан.

– Бар, олы якта ятып тор, – ди миңа да.

Яталар димени инде! Күпме кызыклар көтеп торганда! Шахмат сыннарын өсте-өстенә тезеп башня төзисе, гармунда «аһа-һай, карабай» көен уйнап моңланасы… Абыйлар өйдә юкта аларның «хәзинә»ләренә дә күз салырга кирәк.

Ике тәрәзә арасындагы өстәлнең авыр тартмасын көчхәл белән тартып чыгарам. Изолента, машина мае, тагын әллә нинди ят исләр бөркелеп китә. Һу-у, мондагы байлык! Радиодетальләр, шөреп-кадак, келәшчә-кыскычлар! Әһә, әнә иске фотопленка тасмасы! Аны тыгызлап урап, бер читеннән тартсаң, мушкетёрларныкыдай шпага хасил була!

Эш күп. Бик күп! Энем кайтып җитсә, шахмат чиртешле уйныйсы бар, әбәкле, качышлы, тәкмәч атышлы, парланган тәрәзә пыялаларына бармак белән сызып рәсем төшерешле.

– Рәхмәт, инәкәй! – дип, әнинең кайтып кергәне ишетелеп кала, «мунча харап шәп булган, әби, йөз яшә», дип, әти кайта.

Уйнап арып, йокы килә башлауга безне бәләкәй якка аш эчәргә чакыралар. Калай тәлинкәләрдә мул өреле, куе, токмачлы аш. Учак плитәсендә чүлмәктә озак кайнаткангамы, шулай гел куе пешерә нәнәй ашны. Мул итеп әпекәй (бездә ипине шулай диләр) телеп куйган. Өстәл уртасындагы зур сай тәлинкәдәге бәрәңге, кишер өстенә ит турап өелгән, читендә суган бөҗралары. Нәкъ минем якка карап торган, искиткеч тәмле күренгән каз ботына кул сузам. «Чәлт» итеп беләгемә катыклы кашык килеп төшә.

– Олылардан алда кая үреләсең? – ди нәнәй. Ботны әти алдына куя. Арадан бүтән ит кисәген сайлап алып, миңа суза. Мин, турсаеп, әнигә мөлдерәп карыйм. Аның миңа исе дә китми, тезендә утырган энемә балкашыктан шулпа чөмертә. Өстәл башында тирләп-пешеп аш эчеп утырган әти миңа хәйләкәр генә күз кыса: «эләктеме?» янәсе.

Берәүнең дә мине яклашырга җыенмавын аңлап, язмышыма күнәргә туры килә. Өлешемә төшкән кисәк тә харап тәмле күренә алай. Нәнәй кәбәркәдә мич авызыннан йөзем бәлеше алып маташа. Юк инде, анысына көч җитмәс. Компот эчәм дә менә, бик һуш.

– Амин тот, барып кулыңны чайка, – ди нәнәй, урындыктан төшәргә җыенып борсалануымны күреп.

Житешмәгән җире юк бу нәнәйнең! Табынны да карый, әни белән әти алдында кояштай балкып, алларына ризык этә-этә сыйларга да өлгерә. Безне, бәләкәйләрне: «тегеләй итмә, болай итмә» дип куырса да, алар алдында язын бәбкәләрен көтеп тыпыр-тыпыр биегән каздай өлтерәп кенә тора.

Кулбашындагы чигүле сөлгегә тирен сөртә-сөртә мәтрүшкәле чәй эчкән әтиемнең канәгатьлелеге йөзенә чыккан. Шулай булмый ни! Хөрмәтнең, игътибарның иң олысы аңарга.

– Кияү, баллап эч! Менә, кагыннан авыз ит! Тәбикмәкне ашамадың да… Катыгын да капмадың. Менә төчесен кабып кына кара әле…

Мин инде урындыктан төшеп китәргә җыенган җиремнән, кашыгымны кулга алып, чөгендерле кызыл катыкның уртасына батырам.

– Үзеңә якын читеннән ал, – дип, тагын төзәтеп куя нәнәй. – Ризыкның уртасына тыгылмыйлар алай.

Әни кулында йоклап киткән энемне уятмаска тырышып, аны сак кына олы як диванга кертеп сала. Минем дә күзләр йомылып бара, корсак та пух итеп тора. Ниндидер бер калын китапны актаргалап утырам да, үземнең урыныма, түр почмактагы тар караватка барып ятам.

Чыбылдыкны томалап ябып куям, дымсурак булып тоелган ак тышлы мендәргә битемне терим. Лампочканың сүрән уты, чыбылдыкның кызгылт-сары тукымасы аша саркып кына кереп, андагы эреле-ваклы йортлар, әкәмәт замок-башнялар тулы әкияти шәһәргә тылсымлы бер төс бирә. Үземне өч яктан әйләндереп алган шул могҗизави патшалыкка кереп китәм, таш җәелгән урамнар буйлап атлыйм, үрелеп тәрәзәләрдән карыйм. Йортлары бөтенләй безнең авылдагыча түгел. Кайбер башняларның очларына калай әтәчләр кунаклаган, кайберләрендә сәгать. Тик шунысы мәзәк – беркем дә юк урамда. Йоклыйлармы, әллә менә безнең кебек кунакка китеп беткәннәрме? Бу уй соңгы уем була, мин, тирән коега төшеп киткәндәй, сабый чакның татлы-баллы, гамьсез йокысына чумам. Утны кайчан сүндерүләрен, әниләрнең кайчан кереп ятуларын, иртән ничек торып китүләрен дә сизмим.

…Мин уянганда яктырган иде инде. Мичтә шарт-шорт килеп утын яна. Мич, янып кына киткәндә, бар җылыны үзенә суыра – өй суык, идәнгә басмалы түгел. Кая, тышта ни хәлләр бар икән? Ихата ягына караган бердәнбер тәрәзә диван өстендә. Диван читенә, йоклап яткан энем егылып төшмәсенгә, мендәрләр өелгән. Аларны ах-ух аралап, диваннан тәрәзә төбенә үрмәләп менәм.

Нәнәй «тук»тан кайткан, мал эчерергә әзерләнеп йөри. Ул анда «бодай себерәм», ди. Бүгенгә себереп бетергәндер инде. Яшел шәльяулыгын ияк астына төшереп бәйләгән, мал караганда кия торган зур кесәле кара итәген, фуфайкасын кигән. Кулына онлы калай тәлинкә тотып, мунча ишегалдыннан чыгып килә. Утар капкасы ачык. Кичә без мунчада утырып юынган зур «корыто»дан бөтерелеп пар болыты күтәрелә. «Төтен!» дияр иде энем, күрсә. Нәнәй башак пешергән, димәк.

Утар капкасын ачып җибәрүгә, сарыклар кемузардан чабышып чыгып башакка ябыштылар. Хәйләкәрләр, чукынмышлар, өстәге онын гына чемченәләр. Нәнәй, араларына кереп, таягы белән башакны болгатып җибәрә.

Алар туйгандай булуга бозауга чират җитә. Аннары, башак өстәп салуга, олы җиленен селкетеп, озын мөгезләрен куркыныч селтәп, кара-кызыл сыер чыга, һаман көрпә ялманган сарыкларына ачуланып, аларны сөзеп-сөзеп җибәрә. Абау, корсакларын тишә инде! Тегеләре дә әрсезләр. Ашап туймаганны, әллә ялап туярбыз диләрме икән?

Ихатаның бу башында «каз өе». Тактадан корылган бер куыш инде ул. Казларны да тышка чыгарганнар. Өшиләрдерме, бахырлар, ап-ак кар өстендә тәпиләре кып-кызыл булып янып тора. Ата каз, гадәттәгечә, тирәндәге кечкенә күзләрен усал чекрәйтеп, түшен киереп, муенын сузып, тирә-якны күзәтә. Ана казларның кечерәге, кара-соргылты, салам бөртекләрен томшыгы белән әрле-бирле

күчерештергән була. Кәкре юан томшыклы кытай казы сыңар аягын мамыгы эченә яшергән. Бераздан томшыгын да канаты эченә төртте.

Мин, аңардан күрмәкче, бер аягымны күтәрәм дә, башымны кыегайтып изүемә тыкмакчы булам, һәм, әлбәттә инде, чайкалып диванга барып төшеп, энемне уятам. Тәрәзә төбендә бүтән бер кызык та күренми. Бәләкәй якка чыгам. Кичә бик якты тоелган өй эче бүген томса, тыныч бер халәттә. Чүлмәктә кичәге аш кайнап утыра. Плитәнең зуррак түгәрәгенә чәйнек куйганнар. Кыш көне газ баллонын сирәк китергәч, газны саклап кына тота нәнәй.

Менә ул үзе дә күренә. Кочак тутырып утын күтәргән.

– Тордың дамыни-и?.. – дип суза, мине күреп. – Корсагың ачкандыр инде, шул гомер йокы симертеп ни...

Утыннар гөбердәп мич алдындагы калайга ята. Утын яркаларына ияреп кергән кар кисәкләре, кайнар чәйдә эрегән шикәр шакмакларыдай, теләр-теләмәс кенә, агач тәненә сеңеп юкка чыгалар.

Бүген иң зур кунак – без. Кичәге «ярамый»ларның берсе дә юк. Нәнәй, үзе әйтмешли, «вуле» куя безгә бүген. Озак кайнаудан өйрәгә әверелгән ашны бик тәмләп ашап алабыз да, энем белән уенга керешәбез. Юрган, толып, гармуннар тагын идәнгә төшеп кунаклый. Нәнәй бәләкәй яктагы түшәгенә ятып черем итә. Без, дөньябызны онытып, тагын уен тылсымына чумабыз.

Көн кичкә авышуга мәктәптән абыйлар кайтып җитте.

– Кәҗә маеңны чыгарыйммы? – ди бәләкәй абый, – керә-керешли үк, сумкасын өстәл астына ыргытып.

– Миндә кәҗә мае юк! – дим турсаеп, аның тагын бер-бер этлек эшләсен сизеп.

– Бар, бар! Әллә ышанмыйсың? Әйдә, күрсәтәм!

– Миңа күрсәт, – ди энем, зур күзләрендә кызыксыну катыш самими ышаныч балкытып.

Бераздан инде ул, кызарган маңгаен ышкып, акырып еларга тотына, бәләкәй абый, нәнәйдән өлеш эләгүдән куркып, өйдән чыгып сыза, олы абый, энемне юатырга була, чөйдә эленеп торган фотоаппаратны алып, безне төрлечә кыландырып фотога төшерергә керешә.

Баягы тавыш-гауганың үзе өчен зыян-зәүләтсез тәмамлануын чамалаган бәләкәй абый бу шөгыльгә дә килеп кысылмый булдыра алмый:

– Менә монда гына карагыз, ташбашлар, чыпчык очып чыгачак хәзер!

Күзләр яшьләнеп бетә, башлар авырта башлый, әмма фотоаппарат «күз»еннән чыпчык түгел, чебен дә күренми.

«Әй лә!» дидем дә бәләкәй якка чыктым. Нәнәй дә кичкелеккә малларын карап бетереп (үзе әйтмешли, «сыйлап») кергән икән. Чәй куйган, кичәге бәлеш төпләрен җылыткан. Кечкенә табакта компот төшләре. Алар, бүртеп, тагын да тәмләнгәннәр.

Кичке аштан соң абыйлар дәрес әзерләргә утыра. Нәнәй олы абыйга зур яктагы лампочкаларның ишек төбендәгесен борып куярга куша: «берсе җитәр, акча ашамасын», ди.

Бәләкәй абый безгә сумкасына тияргә рөхсәт итми. Хәер, ул дәресне озак әзерләп интекми, сумкасын тотып, ишек төбендәге чөйгә элеп куя да, шытыр-пытыр



Рәсем: Наталья Васильева



китереп радиоалгычны боргаларга тотына. Без, энем белән, хәзинә сандыгындай күреп, олы абыйның сумкасын актарбыз, китапларын укыгандай итәбез, дәфтәрләрдә кызыл белән куелган билгеләрне санныйбыз.

Ул кичне әле без аръякта кунабыз. Әти белән әни көнозыны эштәләр барыбер. Энем ятар алдыннан көйсезләнеп елый. Нәнәй аны үз янына алып ята һәм нидер көйле-көйле сөйли башлый. Мин ул сүзләрнең берсен дә аңламыйм. Шигырь дә түгел, җыр да.

Тышта кичләтеп купкан буранның ыжылдап улаганы, ябылмый калган тәрәзә капкачын йолыккалап шак-шок бәргәләгәне ишетелә. Нәнәй татарчага күчә. Әллә кем, әллә кемнәрнең исемнәрен, этиләренең исемнәрен атап, «сезләргә дога багышладым», ди. Боларны сөйләгәндә, аның нечкә тавышы калтырап-калтырап китә.

Миңа күңелсез. Мин үземнең иксез-чиксез ялгызлыгымны тоям. Көндез шундый шат, барысын да белүче, бар нәрсәгә көче җитәрдәй күренгән нәнәмнең бөтенләй башка, ялварулы, үтенүле халәтенә шаһит булып, аны кызганудан буынсыз калам. Ник алай сөйләнә ул? Кемнән курка? Кемнән үтенә? Әрвахлар алар кемнәр?

Күз алдымда шундый сурәт пәйда була: нәнәйнең йорты, торбаларыннан төтен чыгара-чыгара, очсыз-кырыйсыз кар яланын ерып, зур бер кораб сыман каядыр йөзеп китеп бара... Ул корабка без төялгәнбез, ләкин аның каян килгәнен дә, кая китеп барганын да белмибез... Дөнья караңгы. Буранның шомлы сыкрануы аша еламсыраулы тик бер аһәң яңгырый: «лә иләһә иллаллаһ, лә иләһә иллаллаһ...»

...Үзгәреп тә карамаган иде мунча. Яңасын салгач биредә күптәннән мунча кермәсәләр дә, бар да элеккечә. Сул як түр почмакта казанлы мич, ишек төбендә ләүкә. Хәтта тәрәзәдә дә шул элекке, кызыл чәчәкле ситсы пәрдә. Уң яктагы озын эскәмия урынына ике карават кына куелган. Аларга искерәк мендәр-юрган, пальто-фуфайкалар өелгән.

– Исәнгенәме, нәнәй? – дим. Тезләнеп казан астына йомычка тутырып булашкан нәнәй, торып баса да, гадәттәгечә, күзләрен кыса төшеп, бар йөзе белән яктырып:

– И-и-и... – дип, миңа таба килә. Кашлары өтелеп көйгән. Битендә пешкән яра эзе. Аны кочаклап алам.

– Нәрсә пожар чыгарып ятасыз монда?! – димен һәм өмет белән күзләренә багам.

Өметем бушка түгел. Ул көлә! Караңгы мунча, утыз еллап элек без юынып йөргән мунча эче, кояш чыккандай, яктырып китә.

Өе янды бит нәнәйнең. Яз сулышы аңкыган зәңгәр апрель кичендә берничә сәгать эчендә янган да беткән. Гомер буе бөртекләп җыйган дөньясы, кадерләп бизәп кенә тоткан йорты үзенең үк күз алдында көл-күмергә калган да куйган.

– Әлдә үзең исәнсең!

– Ишекне ачып җибәрүем булды – йөземә ялкын бәрде, – ди ул, яра эзен бармаклары белән капшаштырып. – Үзем дә янган гына булсамчы шунда! – ди аннан, баягы кәефе кинәт үзгәреп.

– Сөйләмә юкны! Әле син өр-яңа өй салачаксың! Зурны, тагын да яхшыракны! Һәй-й, син мондый гына кайгыларны үткәргәнме!

– Әйе шул, – ди нәнәй, ничектер, бик тиз генә ризалашып. Аның үзендә дә шул ук уй булган. Аръякка, ягъни безгә, энигә, чыгып, ике генә төн кунган янгыннан соң. «Кода нигезендә ни йөзем белән ятыйм, ихатамны ятим итеп!» – диган, ди. Һәм аның бу карарын беркем үзгәртерлек, аның ихтыярын берни какшатырлык түгел иде. Иске мунчаны җылытып, карават корып, шунда тора башлады. Бераздан Казаннан олы абый кайтып төште иптәшкә.

Күч анасы йортсыз калса, күч нишли? Балалары бер җәй эчендә йорт күтәрделәр. Үзенең гомер буе елныңелында, бер калдырмыйча страховка түләве дә юкка булмаган – шуның акчасына бура кайтарттылар. Бәләкәй абый бигрәк тырышты: осталарны да ул сөйләште, материалга да ул чапты. Техника кирәк чакта авылдагы оныгы – яшьли авариягә очрап үлгән улының улы – тракторы белән килеп ярдәмләште. Уфада яшәгән уртанчы улы ике малае белән һәр ял саен кайтып эшләшеп йөрделәр. Әни белән җиңгиләр аш-су ягын, азык-төлеген карадылар.

Иң көтелмәгәне шул булды: үзебезнең авылдан гына түгел, күрше авылдан да исемлек белән җыеп, нәнәйгә акча китереп бирделәр. Әллә кайдагы нәсел очы тиешле кешеләр, Себердән җәйге ялга кайтучылар, нәнәйне күреп белүчеләр, каза хәбәрен ишетеп, кулларыннан килгәнчә ярдәм итәргә тырыштылар.

...Хәер, болар әле соңрак, алдагы ярты ел эчендә булачак хәлләр... Әле исә, әнә, баганалары күмерләнгән, кыйшайган бәләкәй капкадан кемдер кереп килә...

– Синдә дә ут, миндә дә ут! – дип, нәнәйне кочаклап ала Заһидә апа. Күзләре челт-челт килә, ике яңагыннан чөбердәп яше ага. Аның минем белән яшьтәш улы быел яз токка сугылып вафат булды.

– Нишлибез соң инде, Заһидә, нишлибез! Ходайдан узмыш юк, сабыр итәргә, сабыр, – дип, гөр-гөр сөйләнә нәнәй.

Заһидә апа кулындагы төргәкне нәнәйгә суза. Гәзит эченнән шакмаклы ап-ак озын тастымал килеп чыга.

– Менә бусы – оекбашлар. Менә бу пакетта май. Бүген иртән генә бастым. Сөтне кая, базга куярсыңмы, коеңа төшерерсеңме – үзең кара. Кичә Рәйсәнең дә хәлен белергә бардым, – ди ул. – Зарлы хәлен зарлы белмичә, кем белсен... Аңа да оекбаш бәйләп илттем.

Яз башында берьюлы ике сабые боз астына киткән Рәйсәне исемә төшереп, йөрәгем өшеп китә. Күрше апа сәдака итеп китергән ап-ак тастымал, оекбаш, сөтмайларда – кара кайгыларга бирешмичә ак күңел белән картайган авыл карчыкларының җан чагылышын күргәндәй булам. Күңелем тулып, читкәрәк китеп басам.

Янгын урынын тазартканнар, җыештырганнар инде. Эшкә ярардайрак бүрәнәләр бер читкә өеп куелган. Бакча ягында савыт-саба өеме. Табалар, тәлинкәләр кап-кара. Мичне кемдер агартып булашкан, эчендә тимер мунчала ята, буй-буй ак эзләр сызылып калган. Тегү машинасы эреп, гарип кыяфәткә кергән. Өстәл-урындык, эскәмияләр яртылаш күмерләнгән, җыерылып эрегән клеенка кисәге аунап ята. Кайчандыр шыплап тутырулы, нәнәйнең үлемтеккә дигән әйберләре сакланган олы сандыкның каерылган капкачы каз куышы өстендә ята.

Чүпрәк-чапракның барысын бергә мунча ишегалдына өйгәннәр. Яртылаш янып, корымга баткан юеш тукымалар чүмәләсе... Алмалы-чияле пәрдәләргә, әкияти шәһәрле чыбылдыкларга янгын мөһере кыздырып басылган. Әйтерсең лә ниндидер явыз зат аларны чатлы-ботаклы куллары белән өзгәләргә-ерткаларга мәтәләнгән, утлы тынын өргән...

Тыкрыктагы карт каенга да янгын сулышы кагылган: кәүсәсенең йорт ягы күмер генә, астагы ботаклары юк. Һаман яфрак ярып азаплана үзе. Өске чукларындагы сыек яшел нәфис яфракчыклар көл-күмер, корым баскан ихатага сабыйларча гаҗәпләнеп, «ник болай булды соң әле бу?» дигәндәй мөлдерәп карыйлар кебек...

...Мин тагын аръякка чыгып китеп барам. Нәнәйне мунчага чакырырга. Әни ягып калды. Энемнәр бу ялда кайтмады. Иптәшем:

– Әйдә, машина белән генә урап керәбез, – дисә дә, баш тарттым. Иркенләп, ялгызым гына үтәсем килде балачак юлларын.

Кучтәнәчләрне алдым да, киттем тыкрыктан төшеп. Элекке ат күпере юк хәзер. Уртадагы зур күпердән йөриләр. Дөрес, бер читтәрәк басма бар. Җиргә сеңеп бетсә дә, тегермән йорты исән икән әле.

Каеннар картайганнар... Агачларның да картлыгы була. Калын тупас кайрыларын тирән җыерчыклар яргалаган. Өске ботакларының да тузлары купшакланып, аларны кара шадралар таплаган. Җил-давылданмы, үзләренең вакыты җитепме, кайберләренең ботаклары каерылып төшкән. Ике як ярда да адәм буе кычыткан, әрем, әрекмән. Авыл көтүе биредән йөрми инде хәзер.

Елга гына шул килеш, һаман кәефле генә, күңелле генә чылтырап, ару-талу белми үз юлыннан йөгерүен белә. Кайбер урыннарда ярлары ишелеп, юлын гына үзгәрткән. Уң якта, элекке күпер убылып, тирән чокыр хасил булган, черек бүрәнә калдыклары арасыннан каен, зирек үсентеләре үреп килә.

Тар сукмактан биек текә ярга күтәрелеп, клуб турына килеп чыгам. Аның нигез урынында берничә бүрәнә калдыгы аунап ята. Сул якта ындыр табагы, амбар келәтләре. Ат «дубыр»ы урынында кычыткан гаскәре. «Дубыр» артындагы алма бакчасында сыңар алмагач. Уйдык-уйдык ат кузгалагын искә алмаганда, кая карама – тездән үлән! Хәтта урамда да. Печән итеп чабарлык, билләһи! Бу очлар сыер тотмаганны аңлата инде.

Һә-әй, бар иде вакытлар, печәнгә төшәр көн якынлаша башласамы? Урман юлына тузан да кундырмаслар, һәркем үзенең ызанын дәүләт чиген саклагандай керфек тә какмый саклар иде. Күршеңнең өлешенә бер генә покос кереп кара – күрсәтерләр күрмәгәнеңне!

Урмандагы бер покос печән өчен тарткалашып дөнья көтәргә мәҗбүр ителгән гайрәтле агайлар, һәй, кайда сез? Улларыгыз, оныкларыгыз кайда? Кайсы калаларның кайсы таш йортларында көн күрәләр микән нәселләрегез?! Урам тутырып йөргән каз-үрдәкләр, тавык болгавына кушарга ат кузгалагы җыеп йөргән карчыклар кая? Үлән түгел, әремен дә төбенә кадәр кимереп кырып үтә торган атлар кая, көтүләре белән күккә ашканнармы? Нинди зилзиләләр ялмаган безнең авылны?

Нәнәйнең койма алдындагы үләне чабылган алай. Покосларда кибеп ята. Сыерын бетерсә дә, чапмый түзмәгәндер инде.

Эчтән терәү салган бәләкәй капканы ачып, эчкә үтәм. Ихатаны бәрхеттәй булып кәрлә ромашка үләне баскан, элекке сукмак урыннарындагы бәбкә үләне өстендә үрдәк бибиләре чемченеп йөри. Үскәннәр инде, күгәрчен хәтле булганнар. Сул кулдагы алма бакчасында яшь үсентеләр ачылып килә. Быел яз картларын төпләп, яшьләрне утырткан бәләкәй абый. Элекке нигез урынында чәчәк түтәлләре. Уртада дәлия куагы, кояштай булып пәйгамбәр тырнаклары балкый, кашкарыйлар чәчәккә бөреләнгән.

Әнә, нәнәй үзе дә күренде. Ялтырабрак торган бит алмалары елмаюга җәелә, күз читләрендә җыерчыклар нурлана. Яулыгын төзәткәләп, кулын алъяпкычына сөртеп, нәкъ элеккечә көйләп, җырлагандай итебрәк, «и-и...» дип, кочак җәеп миңа таба килә.

Елдан-ел кечерәя барып, орчык кадәр генә калган нәнәмә ике баш югарыдан каравыма кыенсынып, аның корышып беткән, бер бармагын бозау арканлаганда өздерткән кулын учыма алам.

– Үзең генәмени? – ди ул. – Кияү кая? – ди, капка тарафына караш ташлап, инде оныгының иренә дә кияү хөрмәте күрсәтергә әзер булып. Үзенең бердәнбер кияве – әтиемнең җир астына кереп ятуына егерме ел быел.

– Сине мунчага чакырырга чыктым, – дим. – Әни томалап калды. Әзерләп. Көтү кайткач, машина белән чыгып алырбыз.

– Кичә үзем ягып кердем, – ди ул, кулын селтәп. – Интеккән бар әллә? Кое ихатада булсын, моторы гөжләп торсын! Шатланып бетә алмыйм, кызыкаем, бүгенге тормышка! Рәхмәт укып йөрим! Газы гөрләп янып торсын, пенсиясен китереп бирсеннәр, әпекәй кайтып торсын! Утын вуле! Әкәмәт бит, ә! Чәй куям хәзер! Эчми китмисең! Теге буш умартага күч килеп керде бит быел, өченче көн бал аерттым. Баллап чәй эчәбез!

Ул, бал алыргадырмы, гадәтенчә вак-вак атлап, келәткә таба китә. Алъяпкыч кесәсеннән бавы кат-кат төенләнеп беткән ачкыч бәйләмен чыгарып, бихисап ишләре арасыннан кирәкле ачкычны эзли.

Мин келәт янәшәсендә иске мунчага күз салам. Аның ишегалдын нәнәй хәзер бәбкәләр ябарга көйләгән. Сул як алма бакчасына сузылган кер бавында мунча керләре кибә. Янгын сарысы сеңеп калган яулыклар, көек эзе тигән тастымаллар... Яңалары шкаф тулы булса да, искене кимә дип тукып торсак та, шулардан аерыла алмый ул һаман...

Яңа йортның биек, киң күтәрмәсенә утырам да, янәшәмдәге алмагачтан баллары тамардай булып пешкән алма өзеп алам. Өлгерүе җиткән кып-кызыл алмалар, шуны гына көткәндәй, дәррәү тупылдашып җиргә коела. Аякларымны ваемсыз селки-селки, чертләтеп алма тешлим. Йорт ышыгыннан «чыгып» икендегә юнәлгән кояшка күз кысам, кунак килүгә шатланып үрле-кырлы сикергәләгән сары көчеккә кул болгыйм, һәм, нәнәмнең эше бетеп, мине табынга утыртып сыйлаячак, кунак итәчәк тансык, хозур мизгелләрне көтә башлыйм...

ТАҢДА ИСЕП КУЯ ҖИЛ

16 апрель таңы. Җылы көн вәгъдә итеп кояш чыгып килә. Булачак әти-әни – Талия белән Минҗан «скорый»га каршы чыкканнар. Әмма Талиянең бәбие «скорый»дан да тизрәк. Кояшны күрергә ашыккан бала урам чатында, ипи кибете янында ук туып та куя. (Шуңадыр инде Гөлшат бик тә ипи ярата.) Дежур ипи кибетенең сатучысы да ашыга. Кендек җебен кисәргә дип, пычак кыздырып чыгып килүе икән. Әле генә әни булган хатын исә кендек җебенең очын учында кысып торткан да сабыр гына табиблар килеп җиткәнне көтә. Шушы хәлдә яшь әти нишләсен икән? Өр-яңа пиджагын өстеннән салып, сабыен төреп алырга акылы җитә тагын. Сабыйның шәрә тәнен салкын алырга өлгерми кала. Кендек җебе киселгән, инде өйгә кайтасы... да бит. Казан түрендә җәйрап яткан Саин (Савиново бистәсенең татарчасын шулай әйтү дөрес) бистәсе өстендә, әйткәнемчә, апрель хакимлек итә. Сазлык өстен сулышны кыса торган дымлы, томанлы һава сарган. Йорт ышыгына бала бишеген кояшка чыгарып куяр идең дә, язгы нурлар бөтен чир-зәхмәтне таратыр иде. Әнисе өйдәге эшләрен эшли торыр иде. Сабыр итми чара юк әлегә. Таралыр ул сазлык өстендә яткан тымызык томан, таралыр. Әнә бит шәһәр өйләрендәгеләр инде тәрәзә юалар...



Асия
ЮНЫСОВА



БЕР КӨННЕ ТАҢДА ҖИЛ ИСЕП КУЙДЫ. Тылсым белән дигәндәй, бистә өстенә ябылган ябынча юкка чыкты. Сазлык өстен зөбәрҗәт яшеллек каплады. Сары, алсу, зәңгәр төстәге эреле-ваклы чәчкәләр җиләс җилдә җитәкләшеп йөгерешә башлады. Шат күңелле бакалар уянды. Адәм балаларына да җан керде. Бистә хәрәкәткә килде. Түтәлләр күтәрелә, нәркисләр, лаләләр уяна. Кешеләр, кыш буе җыелган түлләрен егәргә әйләндереп, җир эше белән мәшгуль. Һәр өйдән ишегалдына чыгарылган радиоалгычылардан ял концертлары яңгырап тора. Дөнья җыр-моңга коенып уяна, җыр-моңга төренеп йокларга ята. Гомергә җырдан аерылмаган, шәһәр кешесе булабыз дип тырмашкан авыл балалары яши монда. Кешеләр өчен иң рәхәт бер халәт инде ул җирдә казыну. Чәчү, утырту дигән Хезмәт бәйрәме.

Гөлшатны тыңлаган чит кавем кешесенең **татар телен өйрәнәсе килер** иде.

Бистәдә эштән курыкмаган, хөрлек сөйгән, төн эчендә мич чыгарып, өй туе уздырырга өлгергән халык яши. Шәһәр эченнән фатирга тиенгәнче, шушы – Казанның йөрәк турысындагы, әмма сазлык уртасындагы өең-не карарга кирәк. Ара-тирә бистәне балкытып янгыннар чыгып ала. Сазлыктан чыгуның бер юлы инде бу! Гөнаһлы ысул. Тик гаеп итүче юк. Чарасызлык. Алга таба да хезмәт куярга өмете калмагандыр инде берәүнең...

Зур шәһәр кемне дә ымсындыра. 3 яшьлек Гөлшат та бер көнне тәвәккәлли. Бистәдән чыгу-кайту өчен ерганак өстеннән әмәлләнгән тар басмадан зур йортларга карап чыга да китә бала. Ярый әле эштән кайтып килүче күршеләр танып ала үзен. Бу юлы сәфәр чыккан кечкенә кыз ниятенә ирешәлми кала. Ә бит ирешүнең башка юлы да бар икән.

ТАҢДА ИСЕП КУЯ ҖИЛ. 1980 елның 1 сентябрь таңы кызны 49 санлы мәктәпкә китерә. Анда Роза Мифтахова дигән татар теле һәм әдәбияты укытучысы, милли университет хыялда гына гамәлдә булган заманда, татар балаларына мәдәни гыйлем биреп ята. Сыйныфтагы кырык баланың утызы татар баласы. Шул утыз арасында берсе – шагыйрь Зөлфәтнең улы Фазыл. Ә татар теле дәресләре һаман да мәктәпнең коридорында уза. Соңрак Роза ханым аерым татар теле кабинеты даулап алуга ирешә. Татарчалары чатнап торган балалар белән әдәби кичәләр оештырыла, спектакльләр куела. Казан шәһәрендәге иң беренче Тукай музее да шушы мәктәптә, Зур Тукай музееннан да алданрак эшләп китә. Гөлшат та кулына каләм тотып, иҗат итеп карау рәхәтен тәүге тапкыр монда татый.

Сазлыктагы бистәдә камыштай зифа буй җиткергән озын толымлы кызның бер көн килеп, халык каршына җырчы сыйфатында чыгып басуында, шәхес булып өлгерүендә, әлбәттә, шушы укытучы ханымның өлеше зур. Һәм... Кама Тамагы төбәгендәге Каратал авылының... Туфан Миңнуллин якташы икән лэбаса Гөлшат. Җәйге каникул айлары шунда узган икән – чөгендер басуыннан чүп утап, бәрәңгедән корт чүпләп. Аның каруы, бөтен артистларны күреп үскән! Авылның нигъмәте артистлар юлында яту гына түгел бит әле. Чын табигате, риясыз кешеләре, тәмле-рәхәт сөйләме. Бәрәкәтле байлыклар Гөлшат исемле шундаен да садә кыз күңеленә түкми-чәчми күчкән дә куйган. Җыр кадәресе исә аларның нәсел юанычы булса кирәк. Дәү әнисе дә мөнәҗәт көйләп йөрүчән. Әнисе Талия гомумән дә баянчы, композитор Тәлгат Вәлиев төркемендә җырлап йөргән. Казан музыка училищесына килгән кыз да тәгаен җырчы буласын белә. Аның бәхеткә юлы ноталар белән тамгаланган. Аның уенча иң зур бәхет – сәхнәгә чыгып ялгыз җырлау. Фәридә Кудашева кебек, Хәдичә Гыйниятова яки Зилә Сөнгатуллина кебек. Шуңа да кыз академик вокал юлын сайлый.

Училище ишегенә үрелгән кулы икенче бер кулга тиеп китә. Башын күтәреп карауга, Дамир белән маңгайга маңгай бәрелешә. Әлбәттә, очкыннар чәчри! Бу очкыннан кичә генә мәктәп бетергән 18 яшьлек кыз белән, армиядән генә кайткан 20 яшьлек егетнең инде көмеш юбилее билгеләп узылган мәхәббәт тарихы кабынып китә. Бу юлны ике кадерле зат – уллары Әмир белән Дюймовочка кызлары Әминә бизәп тора. Ә бит юлның өзелеп калу ихтималы да булган. Башында ук.

Декабрь аенда кавышалар. Пәһлеван кебек көрәшче, атлет егеткә күз тигәндерме – май аенда, Сабантуйга әзерләнеп йөргәндә Дамирны Республика клиник хастаханәсенә күренергә барган җирдән алып калалар. Рак!!! 24 яшьтә диген. Дамир яткан палатада Генрих Дәминов та, Николай Юкачевның әтисе дә ята. Артистлар палатасы диярсең. Шулар янында Гөлшат атналар буе яши. Егетләр уен-көлке сөйләшәләр. Имеш, сер бирмиләр. Ә Гөлшатның күзендә яшь. 22 яшьтә тол калу ихтималы булганда елмаеп кара син! Тол калырга һич ярамый аңа. Туасы улы хакына ярамый! Көрәшергә кирәк. Дамир алдында сер бирмәскә. Хәзер биш вакыт намазын калдырмый догада булган яшь хатын, бәлки, шул көннәрдә иманын дөресләгәндер дә, «өлгереп җиттем» дип уйлагач, «Казан нуры» мәчете каршындагы мәдрәсәгә Гөлсем абыстайдан дәресләр алырга киткәндер.

ТАҢДА ИСЕП КУЯ ҖИЛ! Май җиле аңа сөенечле хәбәр китерә. Дамирның операциясе уңышлы чыккан. Начар юрамыш расланмаган! Гөлшат хастаханә янындагы бакчага чыгып җырлап җибәргәнен абайламый да кала:

Уяна таңы илемнең, / Ачыла гөл керфекләре. / Җемелдәп яфрак өстендә / Уйный чык бөртекләре...

Җырлары яшәтер аларны. Шул көннән әлеге җыр Гөлшат Имамиева репертуарында «Казакъ вальсы», «Былбыл», «Көтәм сине» кебек онытылмас җырлар белән янәшә урын ала. Аларны тормышка кайтарган җыр лабаса ул. Оркестр белән җырланырга лаеклы җыр! Консерваториядә укыганда мәшһүр остазы – Хәйдәр Бигичевның да остазы Владимир Воронов вафатыннан соң бишенче курста аның «Гөлҗамал»ын һушлары китеп тыңлый торган Зилә Сөнгатуллинаның шәкерте булып киткәч, остазының репертуарындагы әлеге җырны отып алган иде. Инде гомерлек юлдашы итте.

Гөлшат Имамиеваны моңа кадәр сәхнәдә күреп кенә, ялгыз гына да, оркестрга кушылып та җырлаган җырлары аша гына (минем дә ике җырымны җырлый ул оркестрга кушылып) белә идем. Аның белән сөйләшү үзе бер рәхәт, татар теленнән мул сулы көмеш елгадай агылган, камил яңгыраган сүзләр аһәңен тыңлау үзе бер ләззәт икән! Нигә бу байлык радио яки телевидение киңлекләрендә файдаланылмый, татар дөньясына ирештерелми икән дип сызланып куям. Элек тә язганым булса да, бер тормыш гыйбрәтен искә төшереп үтәсем килә. 1995 елда Мәскәүдә узган татар сәнгате декадасы вакытында булган хәл инде бу. «Россия» концертлар залында Илһам Шакиров «Кара урман»ны җырлаган иде. Шунда янәшәрәк утырган бер швед кешесе: «Это великий народ!» – дип, бөтен татар халкына бәясен биргән иде. Илһамның бер җыры белән! Бөек Айрат Арсланов та татар сүзен патшалар сүзе кимәленә китерә алган иде. Димәк, «җыр гына, сүз генә, сөй-

Фото: Анна Арахамия

Яшь кешедә иҗат дәрте ташып торырга тиеш!

ләм генә бит ул, бөек гамәлләр дә кирәк», дип, ашыгыч нәтиҗәләр ясарга ярамый. Таңда үзгәреш җиле искәнен сабыр гына көтеп яту да дөрес түгел.

Без көтеп ятканда татар халкын җиңел генә урап уза торалар. Әнә бит Казан консерваториясеннән кызыл диплом белән чыккан җырчыны Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет академия театрына юллыйлар. Бик шатланып каршы алганнардыр дип уйласагыз, бик ялгышырсыз. «Алтынчәч»тә (Н. Җиһанов, М. Җәлил) дүрт Алтынчәч чират көтә. Син бишенчесе булырсың!» Шундыйрак перспектива булганга күрә талантлы кызлар-егетләр (исемнәрен барыгыз да беләсез булыр) Санкт-Петербург, Мәскәү, Вена операларына китеп, дөньяга танылa тора. Гөлшат Имамиева исә «Казан» милли мәдәният үзәгендә оеша башлаган шәһәр филармониясен сайлый. Әмма югалып калмый.

Бер мәсьәләдә Гөлшат белән гамьнәребез тәңгәл килә икән. Әйтик, мин Рөстәм Яхинның аулакта утырган һәйкәлен уңышлы урнашкан дип саныйм. Шул һәйкәл эргәсенә музыкаль автомат көйләп (рестораннардагы сыман), күпмедер тәңкә түләү бәрабәренә рәхәтләнеп композиторның үзең теләгән берәр җырын тыңлап киңәнергә мөмкин булыр иде. Бу фикерем Гөлшатка да ошый. «Чынлап та, Рөстәм Яхинның 400 ләп җыры бар. Теләсә нинди зәвыкны сөендерә торган җырлар бит алар. Шундый ук музыкаль автоматны Салих Сәйдәшев һәйкәле янында да көйләп булыр иде. Казанга кунаклар күп килә хәзер. Казанның мәгънәви бизәге булыр иде ул урыннар».

Сүз сәнгатебез, рухи байлыгыбыз тирәсендә куергач, борчыган урыннар тагын да булуына офтандык: «Менә 25 еллап бардыр, яшьләр белән эзлекле мәдәни сәясәт алып барылмый. Ниндидер өзеклек, бушлык сизелә, – ди Гөлшат ханым. – Ул моны халык арасында еш аралашучы җырчы буларак кына түгел, бәлки Казан мәдәният һәм сәнгать университетында укытучы буларак та әйтә. – Студентларымны күзәтүдән чыгып та раслый алам сүзләремне. Башка милләттән булган шәкертләрем белемне йолкып алырга әзерләр. Тагылгандай ияреп йөриләр. Ә минем татарларым, безгә булганы җиткән дигәндәй, битарафлык дулкынында йөзәләр. Бездән булмый инде дип, пошмаслану ят булырга тиеш татарга. Реаль, җирле мәдәниятне үстерүгә юнәлдерелгән проектлар күренми. Колач, тирәнлек җитми. Рәшит Ваһапов фонды талантлар табу җәһәтеннән күп тырышлык куя. Менә шуларга «Яңа гасыр» яки «Мәйдан» каналында нигә беркадәр вакыт бирмәскә ди».

Бу төшенкелек, бәлки, урынсыздыр да. Бәлки, рухи төшенкелек татар авылының егәре китүнең, татар мәктәпләренең саны кимүнең бер кайтавазыдыр. Бәлки генә түгел. Тәгаен шулай бу. Рухи елгалар саега бара. Татар сәнгатен «Үзгәреш җиле» генә коткарып кала алмаска охшаган. Таң җиле кирәк анда да!

Моннан ике-өч ел элек тышауның яңасы пәйда булды. Пандемия дигәне. Берара сүз белән, җыр белән көнен күргән сәнгать әһелләре аудиториясез, гавамсыз калды. Җырчы бер көн җырламаса да, тавышы утыра. Бер атна, бер ай ачылмаган тамакта тавыш, гомумән дә, тутыга. Тамашачысының алкышын ишетмәгән күңел боега. Нишләргә соң, нишләргә? Дөрестән дә, **ТАҢДА ИСЕП КУЯ ҖИЛ.** Пандемия богавын өзәрлек Әмәл табыла. Инде янә Гөлшатны тыңлыйк.

– Пандемия вакытында өйләргә бикләндек бит. Эшсез кул кушырып утырудан да авыр нәрсә юктыр ул. «Казан филармониясе»ндә эшлибез бит. Безнең анда шундый очкынлы коллектив тупланды. «Чулпан» үзәгендә җыелыша торган идек. Йөзгә битлекләр япкач, җыелышулар бетте. Һәр кеше үзалдына юләрләнеп ята. Без иҗатташ дусларым белән бу юләрләнүләргә юнәлеш бирергә дип килештек. Моңынчы да артистлар тормышыннан «Көтегез, без киләбез!» дигән театраль тамаша куеп караган идек. «Яңа гасыр» каналында еш күренә ул. Алсу («Фәридә–Алсу дуэтының Алсуы), Ләйсән Мәхмүтова, мин өчәүләшеп сценарий яздык. Ләйсән режиссёр булды.

– «Казан» милли мәдәният үзәгендә үк тупланган коллективыгыз бик егәрле шул сезнең. Теләсә кайсы спектакльне академия театры белән ярыштан куярдай. Сиринә Зәйнетдинова, Резеда Шәрәфиева, Гөлназ Гафурова, Фәридә, Алсу, Ләйсән, Зөлфия Вәлиева... да кушыла торгандыр. Алар белән «Зәңгәр шәл»не кую да мөмкин эштер.

– Куйдык та без аны! Мин әби булып чыктым. Фердинанд Фәтхи ишан хәзрәт булды. «Көлсылу» спектаклендә дә мин явыз Үги ана идем. Сиринә Зәйнетдинова – үз кызым, Гөлназ Гафурова үги кызым булды... Бездә бит Рөстәм Асаев, Рөстәм Закиров, Вәис Бәйрәмов, Рафаэль Якупов, Рөстәм Насыйбуллин, Илгиз Зәкиев кебек шәп тавышлы егетләр дә эшли. Алар җыйнаулашып «Йолдызлы егетләр» дигән тамаша әзерләделәр. Идеясе дә бар – Бердәм булыйк, бергә булыйк! Спектакльгә әйләнеп, сәхнәгә менәчәк тамаша булып чыкты ул. «Австралиягә – Сабантуйга!» дигән тамашага сценарий язып ташладым.

– Сөбханалла! Яңадан-яңа талантларың ачылып киткән икән. Болары пандемиядән котылгач ирешкән казанышлардыр инде. Ә теге – җәйге эсседә мех якалы бишмәтләргә төренеп, шкаф эченә чумып яздырган мини тамашалар үзләре бер кызык, үзләре бер уникаль күренеш бит әле.

Тавыш (ят тавышлар) ишетелмәсен өчен тапкан хәйлә инде бу.

Кызлар кызык итәләр пандемияне. Һәрберсе үз шкаф эчләрендә тавышларын яздырып, оператор егеткә җибәреп торалар. Рөстәм Уразаев анда аерым картиналардан мозаика туплый. Шул рәвешле әлегә исеме табылмаган жанр – могҗизаи мини фильмнар хасил була. Габдулла Тукай язган «Су анасы»ның кул арты җиңел булып чыга. Ә бит бу төр иҗатның башында да мәктәптәге Роза ханымның укыту ысулы ята.

Камал театрының мәшһүр (кызганыч ки, инде мәрхүм) директоры киңәше белән ялгыз сәхнәгә чыккан Татарстанның атказанган артисты Гөлшат Имамиева да тиздән алтын юбилеен бәйрәм итәр.

«ТАТАР ҖЫРЫ-2022»

Казанда «Казан Экспо» халыкара күргәзмәләр үзәгенең Илһам Шакиров исемендәге концерт залында «Татар җыры» премияләрен тапшыру тантанасы узды. Бу чара 23 ел дәвамында тулы заллар җыеп килә, дөньяның төрле төбәкләрендә яшәүче татарлар исә концертны туры эфирдан карау бәхетенә ия. «Татар җыры» фестивале беренче мәртәбә 2000 елда Республиканың Беренче Президенты Минтимер Шәймиев ярдәмендә уздырылган иде. 2003 елда фестиваль халыкара статуска ия булып, татар шоу-бизнесы үсешендә яңа этапка керде. «Татар җыры» фестивале татар эстрада музыкасын яратучы берничә чорның, татар һәм башкорт кумирларының музыкаль олимпына менүенә дә сәбәп булды. Шушы зур милли проект аша 530 дан артык лауреат узды, 1750 дән артык җыр яңгырады. Фестиваль музыкаль талантларны үстерү мәйданчыгына әверелеп, берничә буын профессиональ артистлар тәрбияләде. Башкаручылар Татарстан Республикасында, Россиянең күп кенә төбәкләрендә концертлар куйдылар. Илһам Шакиров, Ренат Ибраһимов, Хәния Фәрхи, Зөлфәт Хәким, Зөлфия Камалова, Идрис Газиев һәм башкалар төрле илләрдә «Татар җыры»ның мактаулы кунаклары булды.

Быелгы фестивальне Гөлназ Сәфәрова һәм Искәндәр Хәйруллин алып барды. Ләйсән Гыймаевага «Татарстанның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелү турында билгеле булды. «Алтын барс» алучылар исемлегендә Зөлфәт Хәким, Айдар Галимов, Филүс Каһиров, Иркә, Әнвәр Нургалиев, Салават Фәтхетдинов һәм башка җырчылар бар.

Фото: Барс Медиа компанияләре төркеме

16+

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА



Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

Туган авылым Иске Урыссу тарихына 2022 ел вакыйгаларга бай булуы белән кереп калачак. Шуларның берсе – мәктәпнең йөзьеллык юбилее. Бу тантанага җыелган авылдашларны, ераклардан кайткан кунакларны авыл мәдәният йорты көчкә сыйдырды.

Бәйрәм барышында сәхнәгә күтәрелгән чал чәчле кичәге укучылар мәктәп бусагасын тәүге тапкыр атлап кергән көннәре, беренче укытучылары, ул вакытларда аеруча җанлы уза торган бәйрәм иртәләре турында сәгатьләр буе сөйләргә әзер иде. Инде арабыздан киткән укытучылар да кадерләп искә алынды.

«45 ел гомерен мәгарифкә багышлаган авылдашыбыз Рабига апа Камаеваның кызы Миңлегөл ханым Субаева да бәйрәмебез кунагы...» – дип дәвам итте очрашуны алып баручы.

Миңлегөл ханым бәйрәмгә буш кул белән кайтмаган. Ул әнисенең исән чакта башкарырга өлгерми калган иң олы хыялын тормышка ашырган – тыл хезмәтчәне, мәгариф ветераны, җәмәгать эшлеклесе Рабига Камаева турында китап бастырган. Хатирәләр, мәкаләләр, кулъязмалар, шигырьләр, фотосурәтләрне бер җыентык итеп туплаган китапны бер гасырлык мәктәпкә бүләк иткәндә аның күзләрендә бәхет тамчылары җемелдәште.

Рабига апа Камаева 1921 елның 1 июлендә Акбаш авылында туа. Шул ук елны Миргасыйм ага гаиләсе белән Ютазыга күченә. Укымышлы, хәлле крестьян була ул. Үз җире һәм атлары булган Миргасыйм Камаевны кулак дип атап, мал-мөлкәтен тартып алалар. Тик ул совет властена каршы бармый. Колхозга керә. Шул рәвешле гаиләсен саклап кала. Озак еллар умарта тота, авылда алма бакчасы үстерә.

Ютазы мәктәбен 1941 елны тәмамлый Рабига апа. 21 июнь көнне кулларына өлгергәнлек аттестаты алган егет һәм кызларның шатлыгын кара сөрем каплый. Шул ук елны кыска сроклы укытучылар курсын тәмамлап, Рабига



Миргасыймовна Кызыл Яр авылында хезмәт юлын башлый. Бер елдан соң аны Иске Каразерек мәктәбенә татар һәм немец телләрен укытырга җибәрәләр. «Бу елларда Көрәш Бүләк, Әптекәш, Колчан, Яңа Юл, Ермак авылларыннан укучылар килеп укыды. Классдар салкын. Балалар кара савытларын өреп җылытты. Мәктәпкә эвакуацияләнгән балаларны да китерделәр. Фронттагы кебек, тылда да хәлләр бик киеренке иде...» – дип яза ул көндәлекләрендә. Сукыр лампа яктысында төннәр буе дәфтәр тикшереп, алдагы дәресләргә әзерләнү белән берրәттән, сугыш чоры укытучылары җилкәсенә халык арасында политукулар алып бару да, фронтка җылы кием җыю һәм заем яздырулар да төшә.

Соңрак бер-бер артлы ике югары уку йортын тәмамлый Рабига апа. Җирле матбугат белән гел элемтәдә тора, үзе дә «Намус» газетасы редакторы була. Авыл советы депутаты, Хатын-кызлар һәм ветераннар советы рәисе, Район советы президиумы әгъзасы... Сугыштан соң Оборона министрлыгы архивларына хатлар язып, яудан кайта калган авылдашларының язмышларын барлый.

Халык хөрмәтен казанган, балалар тәрбияләүдә зур хезмәт куйган данлыклы укытучы Рабига апа тормыш иптәше Шәмсулла абый белән бер ул, өч кыз үстерделәр. Уллары Зәйтүн – Татарстан Эчке

эшләр министрлыгында өлкән тикшерүче, кызлары Миңлегөл һәм Альбина – педагоглар. Өченче кызлары Илһамия – «КАМАЗ» заводында эколог.

– Китапны әзерләгәндә бик күп кешеләр белән аралашырга туры килде. Әниебез турында матур фикерләр ишетү иңнәребезгә канат куйды, – ди Миңлегөл апа. – Аның кульязмалары, сценарийлары, радиотапшырулар дәфтәрләре, юморлы шигырьләре һәм күпсандагы истәлекләр – ниһаять, бер китапта! Ләкин иҗат хәзинәсе тулысынча кереп бетмәде, матбугат архивларында эзләнүләрне дә дәвам итәбез.

Олпат язучы Марат абый Әмирханов та хезмәткә югары бәя биреп: «Бу китап киләчәк буыннар өчен рухи тәҗрибә үрнәге, яшәү мәктәбе булсын иде», – дип яза.

Минем дә журналистиканы сайлавымда Рабига апаның өлеше зур булды. «Булачак журналистлар клубы» бәйгесендә катнашырга теләвемне ул чын күңелдән хуплады һәм ярдәм итте. Нәтиҗәдә, республика күләмендә өченче урынга чыгып, ул чордагы Казан дәүләт университетының журналистика факультетына имтихансыз керү мөмкинлегенә ия булдым. 27 елдан артык «Ютазы таңы» газетасында хезмәт куя алуымда олы йөрәкле, ярдәмчел, шәфкатьле Рабига апаның тырышлыгы әйтеп бетергесез!

Илмира ГАЛИЕВА,
Иске Урыссу авылы
мәктәбенең 1993 елгы чыгарылыш
сыйныф укучысы.

Авыр чакта ярдәмнең артыгы булмый. *«Егетләребезгә ничек ярдәм итәргә?» Мөгаен, бу көннәрдә күпләр үз-үзенә шушы сорауны биргәндер.*

Кемнәрдер җылы оекбашлар бәйли, кемнәрдер ризык, кирәк-яраклар туплый...

Илдә өлешчә мобилизация игълан ителгәннән соң бу хакта үзем дә күп уйландым. Хәрби операциядә катнашучы егетләребезгә чын күңелемнән булышасым килде. Алар – безнең улларыбыз, ирләребез, абыйларыбыз, энеләребез бит.

Маскировка ятьмәләре ясау идеясе көтмәгәндә туды. Казандагы Мәрҗани мәчетенең имам-хатыйбы Мансур хәзрәт Җәләлетдин дә бишкуллап хуплады бу тәкъдимне. Мәчеткә йөрүче ханымнар белән әлеге идеяне озакка сузмый тормышка ашыра да башладык. Баштарак берничә генә кеше идек, ләкин сафларыбыз бик тиз артты. Кемдер радиодан ишетеп, кемдер газетадан укып яки интернет аша белеп, «кулдан килгәнчә булышырга телим» дип килде. Көзге каникул вакытында укытучы апаларына ияреп, мәктәп укучылары да килеп булышты. Студентлар килә. Казан шәһәренең технология һәм дизайн колледжы студентлары хәтта тәҗрибәне дә монда узарга булдылар. Бу бит чып-чын патриотик тәрбия үрнәге!

Мәчетнең вакытлыча остаханәгә әверелгән бүлмәсеннән хәзер бер дә кеше өзелми. Апалар, кызлар, ханымнар, берсен-берсе алыштыра-алыштыра, иртәдән кичкә кадәр ятьмә ясау белән шөгыльләнә. Ялларда да тукталып тормый эшебез. Һәр ятьмәне үргәндә ихлас теләкләребезне телибез, ир-егетләребез берүк исән-имин әйләнеп кайта күрсеннәр дип, чын күңелебездән догалар кылабыз. Никадәр мөһим эшкә алынганыбызны һәрберебез аңлый. Һиндия Габдуллина, Энҗе Әхмәтҗанова, Гөлсинә Шаһиева, Гөлфия Таҗиевалар инде беренче көннән диярлек биредә. Хәзер алар үзләре яңа килгәннәрне өйрәтә.

Бу эшебездә Казан халкының гына түгел, районнарда, авылларда яшәүчеләрнең дә ярдәме бик зур. Кемнәрдер ятьмә ясау өчен тукымалар алып килә, кемдер вакытын, көчен кызганмыйча, станок артына үзе утыра. Ул станокларны агач борыслардан егетләр ясап китерде. Ятьмә өчен барлык төр тукыма да туры килми, тюль, капрон, вуаль ише синтетик тукымалар яхшы. Синтетика үзенә дым сеңдерми, тиз генә тузмый да. Әлегә без маскировка ятьмәләрен, кышкы чор өчен дип, ак төсләрдән ясыйбыз. Язга таба, кар эрегәч, аксыл көрән



төстән башлап, караңгы көрән төстәге тукымалар кирәк булачак. Модасы чыккан, инде кулланылмый башлаган тәрәзә пәрдәләрен ташламасак, берьюлы берничә файдалы эш башкарабыз бит – табигатьне чүпләү дә беркадәр кимиячәк. Аннары бергәләп эшләү, аралашу тынычландыра, күңелгә юаныч та бирә.


Чик сагындагы егетләребезгә дип, мәчеткә җылы киемнәр, перчатка-бияләйләр алып килүчеләр дә күп. Авылларда яшәүче гаиләләр, өлкән яшьтәге апаларыбыз, ярдәмебез булсын, өлешебез керсен дип китерә аларны. Киемнәрне төргән вакытта ихлас теләкләре язылган хатлар да куеп калдыралар. Барысы да егетләребезнең исән-сау әйләнеп кайтуларын тели. Бүген барыбызның да күңелендәге иң зур теләк, мөгаен, шулдыр.

Эльмира ХӘНИЕВА.
Казан шәһәре.

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Сездән хатлар көтеп калабыз.
Безнең адрес: Казан,
Декабристлар урамы, 2.
e-mail: ssuum@yandex.ru

КОҢГЫРТ КҮЗЛЕ КЫЗЫЙ







Гөлнур САФИУЛЛИНА

«Мин саргаям, имеш, синең өчен
Елыйм, имеш, көн-төн, беткән көчем,
Коңгырт күзле кызый.
Гайбәтләргә берүк ышана күрмә,
Минем юлым илтә һаман үргә,
Коңгырт күзле кызый.

Нигә кайтып киттең икән соң син? Ахрысы, мине яратмый торгансыңдыр... Мин кайчагында үземне синең урынга куеп карыйм, юк, мин кайтып китмәс идем сине калдырып... Мине дөнья куптарып ята дип уйлый торгансыңдыр. Пычагым да бернәрсә эшләгәнем юк. Син Казанда булгач кына яза алам, ахрысы. Бер генә юл да язмаган әле, ә ял инде үтеп бара. Вак-төяк эшләр, бәләкәй мәшәкатьләр белән үтә шунда көннәр. Кулларыңа бодай исе, бал исе, җылы сөт исе сеңгәндер инде. Кил инде, ярыймы, Эльмира. Ә мин нишләтәсен белермен ул кулларыңны...»

Озын бу хат. Бик озын! Мөгаен, хатны ул аның тавышын да ишетеп укыйдыр. (Кызык, кеше инде күптән юк, ә аның тавышы колагыңда яңгырый да яңгырый...) Юк, кемнеңдер хәтерендә яшәгәндә берәү дә әле җирдән китмидер...

Бу язмада – юмор һәм сатира остасы, шагыйрь, прозаик Фаил Шәфигуллин һәм аның хатыны, күренекле татар шагыйрәсе, Саҗидә Сөләйманова, Абдулла Алиш, Каюм Насыйри премияләре лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Эльмира Шәрифуллинаның тормышы. Аларның табышлары, югалтулары, мәңгелек әрнүләре...

* * *

«Әгәр син мине оныткан булсаң... Кайдан килеп тора шундый уйлар минем башыма?! Бетсен иде инде бу отпуск дигән күңелсез көннәр. Баш-аягым белән эшкә чумар идем ичмасам, эшләп арыр идем. Гел сызланса күңелдәге әрсез яра, тешем кысып эшкә тотынам – эш коткара...

Ә хәзер син минем күз алдында. Өстеңдә бик-бик таныш зәңгәр күлмәк. Кара сумкаң. Асфальтка тияр-тимәс... Йөзең караңгы иде, мине күргәч көлеп җибәрерсең дип уйлаган идем, «нигә килдең» дигән салкын сүзләреңне ишеткәч, коелдым да төштем. 3–4 көндә шулай үзгәргән идең. Берничә дистә көндә ни булыр икән? Нәрсә китерер икән миңа бу көз? Бәхетле, шатлыклы ваемсызлыкмы, әллә аерылумы?» Җәйге ялга кайтып киткән Эльмирасына көн дә язган хатларының берсеннән бу юллар. Бик озын ул – конвертка гына һич тә сыя торган түгел: авылга бандероль белән килеп төшә.

...Минзәлә педучилищесында укып йөргән Эльмираны Казанга – башлап язучылар өчен оештырылган семинарга җибәрәләр. Башлап язучы дип... Аның инде шигырьләре әллә кайчан район газетасында басыла. («Коммунизм таңы»нда ул чакта Фәнзаман Баттал эшли, Рәшит Гәрәй кайтып йөри.) Ә бер шигыренә – «Ямьле безнең Минзәләбез»гә композитор Әнвәр Бакиров көй яза. Сабантуйда, Минзәләнең 100 еллыгы уңаеннан оештырылган бәйрәмдә аны мең кешелек хор җырлый!

Бөтен группа әзерләп озата Эльмираны Казанга. Роза дигән группадашы чуклы-чәчкәле шәлен бирә: «Пальто өстеннән сал, хәзер шундый мода», – ди. Алай ук салырга ояла кыз...

Семинарны Нәби Дәүли, Габдрахман Минский, Мөхәммәт Садри, Марс Шабаев кебек олпат язучылар үткәрә. Бала-чага гына димиләр, һәркемнең шигырен тикшереп, анализ ясап, өметләндереп, канатландырып җибәрәләр. Шул ук семинарда Тәүфыйк Камалиев, Фәнис Яруллин һәм Фаил Шәфигуллин иҗатлары да тикшерелә. Алар инде өлгергән шагыйрьләр! Фаилне Хәсән Туфан бик мактый: «Нигез ташларына» дигән шигырен Дәрдмәнднең «Кораб»ы белән рәттән куя.

– Нишләп язмый утырасың?

Фаилнең кинәт кычкырып әйткән тавышына барысы да Эльмирага борылып карыйлар. Үзенә беркетмә язарга кушуларын онытып, Туфанны тыңлап утыра икән бит... Бер мизгелгә генә күзләре очраша. Зәңгәр икән күзләре Фаилнең...

Семинар тәмамлангач, аларны «Ёлочка» кафесына чәйгә алып керәләр. Язучылар йөри торган урын, диләр. Юк, ул көнне Фаил әле аны озатмый.

«Мин синең чибәрлегеңнән курыктым, минеке булмассың дип уйладым, шуңа ашыктырдым», – ди ул.

эшкә алмыйлар икән... Кемдер «Таткниготорг» дигән оешмага кереп карарга куша. Бауман урамы 19 нчы йортта урнашкан була әлеге оешма. Беренче катта – китап кибете. Шунда китапларны төреп, почта белән җибәрергә кеше кирәк икән. Саҗидә дигән бер кыз эшли инде анда, тик җитешә алмый. Эльмира белән икәү эшли башлыйлар, әмма барыбер өлгермиләр. Халык егылып укый, китапка ихтыяҗ шулкадәр зур. Хатлар ява гына. Җибәрергә әзерләгән посылкалар ай ахырында түшәмгә җитә – бүлмәдә кеше үтәрлек кенә урын кала... «Таткниготорг» – язучыларның яраткан җире икән. Товар ташучы Роза апа янына кереп, үзләренә кирәк китапка заказ биреп чыгалар, анныры шуның кайтканын саклыйлар... Яшел Үзәндә яшәүче язучы Идрис Туктар да шакмаклы дәфтәр битен тутырып язган исемлеген калдырып чыга. Ә ул китаплар кайтканмы-юкмы икәнен белешергә... Фаил кереп йөри башлый. Бер керә, ике... Кызны киного чакыра, аннан «Татар ашлары» ресторанына төшке ашка алып керә. (Көндез анда ашханә бәясе генә түләтәләр!) Егетнең үзләрендә – Яшел Үзәндә, «Серго» заводында эшләп йөргән чагы. Аңа – 28 яшь. Ул инде килгән саен: «Өйләнешик!» – дип кыстый... Ә кызга әле 20 яшь кенә. Читтән торып университетка укырга кергән елы. Китапка дип «Таткниготорг»ка килгән җирдән аның шигырьләре белән дә танышкач, Нәби Дәүли Эльмираны кулыннан җитәкләп диярлек «Яшь кын» журналына алып керә. Аны редакциягә эшкә алалар! Кияүгә чыкса, боларның барысын ташларга туры киләчәк... Авылдан кунакка килгән әнисе дә: «Юк, чыкмыйсың!» – дип китә. «Бала да тапсаң, ничек укырсың?» – ди. (Соңыннан ул аңа «безнең кияү» дип кенә торачак әле!)

Ә беркөнне Фаил килеп керә дә: «Җыен, алып китәргә килдем!» – ди. «Минем бер әйберем дә әзер түгел!» – дип каршы төшеп карый. (Фатир хуҗасы – тегү цехында эшләүче Хәлимә апа матрас сырырга вәгъдә биргән була, әле ул да өлгермәгән.) «Аста такси көтеп тора анда! – ди Фаиле кире какмаслык итеп. – Акчаны чутлап тора ул!» Булачак кайнанасы: «Бүген кавышу өчен бик әйбәт көн», – дип санап чыгарган икән... Фаил соңрак: «Мин синең чибәрлегеңнән курыктым, минеке булмассың дип уйладым, шуңа ашыктырдым», – ди.

* * *

1966 елда Эльмира педучилищены тәмамлый һәм өйгә, Актанышка кайтып йөрергә якынрак җир булыр дип, эшкә юлламаны Мамадышка ала. Килүгә Пионерлар йорты директоры итеп куялар, мәктәптә дәресләр бирәләр. Ә күңел... күңел инде Казанга тарта, редакцияләргә барырга, язучылар белән аралашырга кызыга.

Бер елдан соң тәвәккәлли ул. Килә Казанга, торырга фатирын да таба. Тик бит прописка юк, ә ансыз беркая да

* * *

Яшел Үзәнгә, 10 квадрат метрлы бүлмәгә килен булып төшә ул. Шулай яшәп китәләр. Икәү түгел, өчәү! Түрдә – кайнанасының караваты, аныкы белән янәшә – аларныкы. Уртада – чаршау урынына җәймә эленгән. Карават каршында – тар гына өстәл. Тагын – ике урындык, бер табуретка... Бала тугач, колясканы карават өстенә куярга туры килә. Бүлмә мич ягып җылытыла. Туйны Октябрь бәйрәменә туры китереп ясыйлар. Туфлисез, балдаклар-

Фаил минем өчен, кызларым өчен генә түгел, татар әдәбияты өчен дә зур югалту...



■ Сөю-сагадәт белән тулы көннәр. Кызлары Раушания белән.

■ Язучылар гаиләсенең бергә төшкән соңгы фотосы. Кызлары Резедә белән.



сыз гына... Актаныштан Эльмираның әти-әнисе килә, Фаилнең дусларын – Идрис Туктар, Назыйм Ханзафаров, Вил Шәрәфетдиновны чакыралар. Туйга алар бүләк иткән сәгать хәзер Фаил Шәфигуллинның музеенда тора... Ә алдан биргән вәгъдәләрнең берсе дә үтәлми. Аңардан гына торса икән! «Мин – шәһәр советы депутаты, сине яхшы эшкә урнаштырам», – ди ул. Тик редакциядә дә, мәктәптә дә буш урын табылмый. «Өйләнешсәк, фатирны зурайталар», дип өметләнүләр дә юкка була... Яшь хатынга ире янына – заводка, өч сменалы эшкә чыгарга туры килә.

* * *

– Фаил гел малай көтте. Ә мин өч кыз таптым... Шуңа үземне гаепле санап йөрдем... Соңгысында әткәйгә открытка җибәргән: «Бер патшаның өч кызы дип сөйлиләр бит – безнең дә шулай хәзер», – дигән.

Раушаниясе сессия вакытында, дөресрәге, аның беренче көнендә үк туа. Әтиләре аларны Яшел Үзәнгә кайтарып куярга теләсә дә, Эльмира ризалашмый – группадашларыннан ничек калышсын ди?! Актаныштан бала карашырга әнисе килеп җитә, фатир хуҗасы «булышам» дип тора. Фаил дә студент, ул да читтән торып укый, тик бер курска алдарак кына. Шулай итеп сессияне өчәүләп тапшыралар.

Олы кызларына бер яшь булганда Казанга күченеп киләләр – Фаилне «Чаян» журналына эшкә чакыралар. Эльмираны исә иренең дусты Тәүфыйк Камалиев телевидениегә хатлар бүлеге редакторы итеп урнаштыра. «РТИ» заводы тукталышында, берәүләрнең иске генә өендә яши башлыйлар. Үтәли җил йөри, идәнгә баса торган түгел – иртәнгә сулы чиләк бозланып ката. Раушания гел чирли башлагач, аны Актанышка кайтарып куялар – бала кышны шунда чыга.

Тормыш әкрен генә билгеле бер эзгә төшә. Икесенең дә язганнары башта уртак җыентыкларда, аннан аерым китаплар булып басылып чыга башлый. Фаилне СССР Язучылар берлегенә кабул итәләр. Зур вакыйга була ул!

– Ул бик тырыш иде. Күп эшләде. «Яңа ел бусагасында» дигән китабыннан кала, барысын да без өйләнешкәч язды. Иртән торган җиргә һәр көнне диярлек өстәл почмагында яңа язган әйбере була. Әдәби әсәрләрен башта бергә кычкырып укый идек. Дустын – күрше Зөлфәтне чакырабыз, ә ул кешене үсендерә белә... Инде аның хикәяләре сәхнәләргә менде. «Сафура, Бәкер һәм тракторы»н Рәшит Сабиров укый иде. Хәтерләсәгез, андагы вакыйга сугыш вакытында бара, әмма иренең фронттан язган ул хатындагы юмор! Андагы йөгерек тел! Бу классик әсәр, мөгаен, сәхнәдән төшмәс. Ә Фаилнең балалар өчен язган хикәяләре! Тәнкыйтьче Равил Рахмани: «Татар әдәбиятында бала күңелен шулкадәр нечкә аңлап, нәни укучысын яратып иҗат итүче ике генә әдипне күрсәтергә була: берсе – Абдулла Алиш, икенчесе – Фаил Шәфигуллин», – дип язды.

«Әлфинур», «Сыерчык бураны», «Ак маңгайлы бүреләр», «Бер малай, өч аргамак», «Бәхет йолдызы астында», «Өй салуның ние бар?». Фаил Шәфигуллин язып калдырган повестьлар болар. Хәер, соңгысы төгәлләнми кала.

* * *

Фирүзә... Апалары Раушания белән Резедәдән соң туган төпчекләре. Җан ярасы... 100 көнлек чагында аңа «стафилококковая пневмония» дигән диагноз куялар. Ул көнне искә төшерү Эльмира ханымга бүген дә авыр.

– Без аңа бик озак бер дару эзләдек. Дүрт ампула булса да, Фаил аны тапкан да иде инде. Көндәгечә, кызыбызны процедура ясарга алып кереп киттеләр. Култык астында 5 тиен акча зурлыгында тишек тишкәннәр иде – шуның аша зур шприц белән дарулар җибәреп үпкәсен юдыралар. Шулкадәр матур бала иде ул. Зәп-зәңгәр зур күзле. Хәле алай начар да түгел кебек иде...

Палатаның ишеге пыялалы. Берзаман табиблар чабыша башлады. Ишек янына барып бастым, юньлегә түгел бу, дим. Ул арада берсе баланы күтәреп каядыр йөгерде... Башта

кертмәгәннәр иде бүлмәгә, инде туктатмадылар. Карыйм: бала чүпрәкләре кан гына... «Исәнме?» – дим. «Юк, саклап кала алмадык», – диләр. Кан киткән, туктата алмаганнар...

Фаиле «Чаян» рәссамыннан тактага нәни кызының исемен, туган-үлгән көннәрен яздырып кайта. Эльмира ханымның энесе чардуган ясый. Курчак караваты кадәр генә... Яңа Татар бистәсе зиратында май аеның матур бер көнендә яңа кабер калка...

– Ярый әле без бу хәсрәтне бергә чакта кичердек... Аннан соң булса, тагын да авыррак булыр иде...

* * *

Аннан соң... Ягъни тагын ике елдан – 1982 елның 5 октябреннән соң.

Ул көнне Фаил Шәфигуллин өенә кунарга кайтмый. Иртән Эльмира ханым Мөслимгә командировкага китәргә тиеш була. Республиканың иң ерак районы – тиз генә әйләнеп кайта торган түгел. Ә аларның Васильеводагы бакчаларында өмә билгеләнгән – бурадан йорт күтәрергә тиешләр. «Бармыйсың!» – ди Фаил хатынына өздереп.

Шулай аерылышалар... Төн йокысыз – тәрәзәдән тәрәзәгә йөреп уза. Аңа очы-кырые күренмәгән көн кушыла... Кичкә ишекне бер милиционер шакый. «Иregезне кыйнап ташлаганнар», – ди. Парижская Коммуна урамындагы җимерек өйләр арасыннан тапканнар, башта исерек дип айныткычка алып киткәннәр. Икенче көнне кичкә таба гына хастаханәгә озатканнар.

– Ул көнне хәлен белергә барырга соң иде инде. Иртән коймак пешердем дә, сәгать җиде тулганчы ук 15 нче хастаханәнең ишек төбенә барып бастым. Кертмиләр. Ниһаять, эчкә уздым. Сорыйм, эзлим – бер-берсенә йөртәләр, тапмыйм гына. 6 нчы палатага салганнарын белдем. Дүрт кешелек палата, бер карават буш – җыелган. «Шәфигуллин монда ятамы?» – дим палатадагы ирләргә. «Үлгән Шәфигуллинмы?» – ди берсе... Төнге сәгать уникедә үк өзелгән икән... «Берәр сүз әйтмәдеме?» – дип сорый алдым. «Ул татарча нидер әйтте, тик мин истә калдырмадым», – диде янәшә караватта ятучы ир...

Фаил Шәфигуллинның иҗаты гөрләгән чак була бу. Аның инде халык арасына «Яшьлегем тугае» дигән җыры чыккан. Аның инде бөтен җирдә «Яз җыры», «Арышлар», «Мин гармун булыр идем» дигән җырлары яңгырый. Ул ундүрт көн элек кенә Пицундадан – язучыларның иҗат йортыннан кайтып төшкән, өстәлендә – язып бетермәгән яңа повесте... Аңа әле нибары 43 яшь...

* * *

Күзләрең сагышлы, / Дип әйтте бер тугай, / Нишлим соң, тургаем, сагындым!

Әтиләре киткәч, «Яшьлегем тугае»н Эльмира ханым да, кызлары да күз яшьләрсез генә тыңлый алмый. Сүзләре бигрәк үзәкне өзә... Дүрт яшь ярымлык булып калган Резедәсе бик озак әтисен таптыра. Баскычтан җырлый-җырлый менгән әтисен көтә. Менә-менә ишек ачылыр да, ул аңа һәрвакыттагыча аяк киемнәрен илтеп бирер, ә аннары әтисе өстен алыштыруга, ат булып – дүртьаякланып кызларын аркасына утыртып йөртер... Раушания ул көннәрдә бөтенләй сөйләшмәскә әйләнә.

Суд эшләре башлана. Арттан, кизәнеп, башына ике тапкыр яссы әйбер белән сукканнар, диләр. Кемнәр, ни өчен? Айныткычка илтмичә туп-туры табиблар кулына илтеп тапшырсалар, исән калыр идеме? Бәлки, ул аңында чакта ниндидер исемнәр атагандыр? Айныткычта ул көнне кемнәр кабул иткән, кемнәр утырган? Эльмира ханым ул чактагы әлеге кешеләрне эзләп таба. Зөлфәт, аның хатыны Фирая ханым һәм ул – өчәү берничәсе янына барып, сөйләшеп тә кайталар. Тик аңа: «Син безгә тикшеренүне алып барырга комачаулыйсың», – диләр. Гаеплеләр табылмый...

– Суд юлында йөрергә язмасын, диләр, дөрес ул. Куллары калтырый башлады... Балаларны бөтенләй ятим калдырам дип, бер елдан соң туктадым...

* * *

Тагын бер тетрәнү бар әле... Фирүзәнең кабере зират капкасыннан кергәч тә уң якта була.

– Берьюлы шулай Фаил янына бардым да, Фирүзә янына да киттем. Бардым, эзлим – кабер дә, чардуган да юк. Юк! Аптырап, зират идарәсенә кердем. Фирүзәнең урыны өчен документыбыз юк икән бит безнең... «Эзләгез каберне, без кайдан белик», – дип җавап бирделәр. Фаил янына барып бастым да: «Баланың кабере юк, син шуны беләсеңме соң?!» – дим үрсәләнеп... Тапмадык. Бик авыр булды – икенче кат югалткан кебек... Чардуганын алып кемдер саткан, күрәсең... «Изге нәрсә бармы бу дөньяда?» дигән шигырь юллары шул чакта туды...

* * *

Фаил Шәфигуллин Пицундада «Өй салуның ние бар?» повестенең икенче өлешен тәмамлап кайта. Әмма кайткач нибары ундүрт көн яшәп кала... Аның кульязмасын – повестьнең дәвамын иҗекләп, сүзләп җыярга туры килә. Һәрвакыт ашыгып, сүзләрнең ике-өч хәрефен генә куеп язган ул. Эльмира ханымның тырышлыгы белән бу китап 1991 елда дөнья күрә. «Кешелек тавы» дигән китапка исә Фаил Шәфигуллинның газета-журналларда чыккан барлык әсәрләрен берәмтекләп җыя. Иренең вафатыннан соң унбер (!) китабын чыгара. «Фаилне югалткач, күңелемдә аңа багышланган шигырьләр ыргылды гына. Һәммәсен бер китапка тупларга озак хыялландым. Узган ел, ниһаять, «Толларның да җаны бар» дигән ул китапны чыгара алдым. «Туктат инде шул елап язуыңны», – дип әйтүчеләр дә булды. Нәрсә диим... «Гомеремне түләп җырлар яздым, / Шигырь буынына сеңдереп...» Ә Фаил... Ул минем өчен, кызларым өчен генә түгел, татар әдәбияты өчен дә зур югалту иде...»

* * *

Хатирәләргә чума-чума, Фаил абыйның аңа – ямь-яшь Эльмирага язган хатын укыйбыз. Ул аннан – үткәннән – бүгенгегә дәшә кебек:

Син яшәгәч җирдә тау күтәрәм, / Йолдыз ясыйм төнге яшеннәрдән, / Коңгырт күзле кызый. / Сөюем өчен сине өзелеп-өзелеп, / Бирдең, ахры, миңа үлемсезлек, / Коңгырт күзле кызый...

«ИСӘНМЕ, АНА-ТАУ!»

Мөнирә
СӘГЫЙДУЛЛИНА



Мин бу сәяхәтне күптән көттем. «Соңгы тиенемне җыеп булса да, барыбер бер барып күрәчәкмен», дип хыялланып яшәдем. Уллу-Тау турында иң беренче ишетүдә үк, ни өчен-дер шушы тау итәгенә барып башны сәҗдәгә иясе, аннан чиста күңел белән күкләрне күзлисе килгән иде...
Ул чакта барырга ният итсәм дә, төрле сәбәпләр табылып, юл ачылмады. Алтай, Казакъстан, Кырым таулары узылды, челләләрдә чиксез чакрымнар үтелде, җиде пот тир түгелде. Һәм ун елдан соң, һич көтмәгәндә, юллар мине Уллу-Тауга китерде. Гади сәфәр генә түгел иде бу...

Таулар... Горур һәм нык басып торучы, күпне күргән, әмма яшәү көчен югалтмаган мәһабәт таулар. Кеше үз гомерендә бер генә тапкыр булса да тауларга менеп, андагы гүзәллекне күрергә, аларның көчен тоемларга тиештер... Анда тормыш та, вакыт һәм фикер агышы да үзенә бертөрле. Моны бары тик тауларны яратучы гына тулаем аңлый ала торгандыр... Тау итәгендә басып тору да җанга ниндидер рәхәтлек, тынычлык бирә. Күз алдына гына китерегез! Түбәләре белән күкләрне кочкан, ак карларга күмелеп, мәңгелек бозлыкларга ия булган таш кыялар, көчле тавышлы шарлавыклар һәм... син!

Шушы мизгелләрдә таудан агылган энергетик көчне, яшәү дәртен, шарлавык тавышына ияреп иңгән аһәңне берничек тә аңлатып булмый. Бу минутларда син үзеңне икенче – башка бер үлчәмдә хис итәсең... Бу халәтне тою өчен күнегелгән уңай тормыштан баш тартып торырга да була.

Хыялны чынбарлык иткән, тормыш упкыннарын кичеп, бу дөньяга яңабаштан адым ясарга мәҗбүр иткән Уллу-Тау... Инде сулыш кысылып, җаның күккә очарга канат кагынганда, үзенә тартып китерә алган нинди сихри тау булдың соң син?

Кавказда аны Ана-тау дип тә йөртәләр. Эльбрус – Кавказның атасы дип саналса, Уллу-Тау анасы буларак киң танылган. Зур Кавказ тау тезмәсенең үзәгендә, Эльбрус алды җирлегендә урнашкан. Адыр-Су тарлавыгының аргы очында аркылыга сузылып көчле, какшамас бер дивар булып, ике ил – Россия белән Грузия арасын аерып тора. Тирә-якта берсеннән-берсе матур Чот-чат (3780 м), Виатау (3280 м), Тютю-баши (4533 м), Адыр-Су (4370 м) таулары булуга карамастан, 4207 метр биеклектәге чал башлы Уллу-Тау затлылыгы белән әллә каян балкып, игътибарны гына түгел, җанны да үзенә тарта...



■ Бәлки, шушы чәчәкләре – рододендроннары өчендер бу урынны «Феялар аланы» дип йөртәләр. Андагы матурлыкны язып кына аңлата алмам: аны күрергә һәм тоярга кирәк.

Докторский үткеле

Каф тауларына җәяүле сәяхәт Докторский перевалыннан – үткеленнән башланды. Халык теленә ул шулай кереп калган, ә мин аны «Күк баскычы» дип атар идем. Нәкъ шушы урында, беренчедән, кеше үзенең сәламәтлеген, чыдамлыгын, физик һәм рухи әзерлеген сыный; икенчедән – җир белән күк арасындагы аерманы тоемлый. Кыя буенча биеклеккә таба сузылган тимер баскыч... Карап торуга бернәрсәсе юк кебек. Кирәкле әйберләрең тутырылган биштәреңне аркаңа асып, «бисмилләңны» укыйсың да, Ходайга тапшырып, зур тәвәккәллек белән күкләргә күтәргән баскычка аяк басасың. Әкренләп, уңга-сулга карамыйча, култыксаларга тотынып, үз җаең белән өскә үрмәлисең... Менеп җиткәнче берничә тапкыр туктап тын алырга туры килә. Күккә алып менгән 310 баскычны узуы һич тә җиңел түгел. Әмма аларны узуга икенче дөньяга эләгәсеңмени! Монда һавасы да, табигате дә башка, хәтта эчке халәтнең үзгәрүе дә сизелә. Аска карап хәйран каласың. Горурлык хисе били. Сулыш иркенәя. Күңел, очар кошлар сыман, әллә кайларга талпына...

Алда – Адыр-Су елгасы буйлап 14 чакрымга Адыр-Су тарлавыгы сузылган. Тарлавыкның башында – беренче погранпост. Монда паспорт тикшерелә, рөхсәт кәгазен күрсәтеп, теркәү узасың. Тарлавыкның беткән урынында – икенче погранпост. Анда инде махсус пропуск та сорыйлар, чөнки якында – ике ил арасындагы чик буе. Кирәкле документларның барысы да алдан әзерләнә.

Без барасы «Уллу-Тау» дигән альпинистлар базасы үткелдән 12 чакрым ераклыкта урнашкан. Базаның исеме тау атамасы белән йөртелә. Таулар аша сузылган ташлы грунтовка юл акрынлап биеклеккә күтәрелә бара. Чын романтика шунда башлана! Юк, авыр йөк биштәрен асып, хыял артыннан тауларга сәфәргә һәркем чыга алмый...


Көтелгән очрашу

Ниһаять... Ничә еллар буе көтеп алынган очрашу... Менә ул – төшләремдә күреп сагынып уянган Ана-Тау. Әссәламегаләйкем, Уллу-Тау! Аллаһының рәхмәте чиксез – синең белән дә күрешергә насыйп булды бит... Күңелем тулып, хисләрем ташып, бер кәлимә сүз дәшә алмыйча, үземне чорнап алган манзарага сокланып, күкләргә карап торам. Сөйләп тә, язып та бетерә алмаслык гүзәл табигать, биек һәм горур таулар...

Без диңгез өслегеннән 2380 метр биеклектәге наратлар арасындагы «Уллу-Тау» альпинистлар базасында урнаштык. Монда бердәнбер цивилизация – яши торган биналар (аларның уртадагысы – таштан, ике яктагысы агачтан салынган) һәм мунча. Бернинди элемтә, интернет, электр уты юк. Дөрес, кич белән нибары 3 сәгатькә генә «армейский» генератор аша ут биреп



■ Хыял артыннан кыяларны иңләп, балачактан Тукай шигыре аша күңел түрендә үз урынын яулаган Каф таулары үз күзләрем белән күреп кайтуыма Ходаема чиксез рәхмәтлемен. Шөкер, тау юлларын хәвеф-хәтәрсез уза алдым...



алалар. Су шланг аша юыну урынына агып торган тау елгасыннан килә. Боз кебек салкын ул! Кайнар су монда хыял гына... Административ бинада – ашханә. Кирәкле ризыкларны үзебез белән алып килдек: алдан килешенгәнчә, ашарга махсус пешекче әзерләде. Янәшәдә – зур зал, ягъни клуб. Бу – бердәнбер күңел ачу урыны. Анда төрле күнегүләр, дәресләр, кичке очрашулар уздырыла. Тору урыны – ике яки дүрт урынлык бүлмәләр. Атнага ике тапкыр мунча ягыла, анда да душ астында гына юынасың.

Беркем телефоннан шалтыратып, моң-зарын сөйли алмый, ниндидер проблемаларны хәл итәсе, кемнедер юатасы, каядыр ашыгасы, кемгәдер җавап, хисап бирәсе яки кухняда плитә каршында нәрсә пешерим икән дип уйланып торасы түгел... Менә җәннәт кайда икән!

Бер атна – нәкъ җиде көн тынычлык! Бигрәк кызык: ничегрәк булыр икән ул цивилизациясез дөньяда гомер итү? Гомумән, ыгы-зыгысыз, шау-шусыз, интернетсыз, радиотелевизорсыз, кайнар яңалыкларсыз, таныш-белешләрсез, дусларсыз, эшсез? Һаман вакыйгалар үзәгендә кайнарга гадәтләнгәннән соң ничек кабул итәрбез икән моны? Кызык, әмма әлегә күз алдына китереп булмый...

Тауларда яшәү тәртибе

Ничә көнгә, нинди максаттан килүгә карамастан, тауларда яшәүнең һәм үз-үзеңне тотуның кануннары, тәртибе бар.

Без урнашкан лагерь катгый контроль зонасына керә. Әйткәнемчә, таулар артында ил чиге уза: лагерьдан берничә чакрым узуга Гөрҗистанның Сванетия төбәге башлана. Шуңа да таулардагы сәфәр чик сакчылары тарафыннан нык күзәтелә. Маршрутка чыгар алдыннан погранпостка барып, алдан алынган рөхсәт кәгазе, паспорт белән теркәләсең, кая һәм сәгать ничәдә киткәнеңне яздырасың. Кайтканда кабат билгеләнергә кирәсең. Моның икенче ягы да бар. Таулардагы хәлне алдан белеп булмый: кеше бәла-казага юлыкса, вакытында тиешле ярдәм күрсәтү өчен хәрәкәт картасының күз алдында булуы шарт.

Көмеш сулы Изге чишмә

Көнебез лагерьдан өч чакрым ераклыкта урнашкан көмеш сулы Изге чишмәдә коенудан башланды. Суының температурасы – 3–4 градус. Шушы суда коеныр өчен, көн саен иртәнге сәгать биштә йокыдан торабыз да җәяүләп чишмәгә барып кайтабыз. Таң атканны – кояш күтәрелгәнне күзәтәбез. Тиз генә берничә тапкыр чиратлашып чумып чыгабыз: чишмә зур түгел – аңа бер кеше генә рәхәтләнеп чума ала. Тәндә кан йөгергәне сизелеп тора. Кем әйтмешли, яшиселәр килеп китә.

Сәгать җидегә лагерьга кайтып житәргә кирәк, чөнки иртәнге күнегүләр башлана. Соңга каласы килми: көн саен гимнастика ясыйбыз, йога, цигун, сулыш алу алымнарын өйрәнәбез.

Тау юллары

Үзем узган юлларны кызык өчен фотога төшереп бардым. Тауларда йөргәндә тирә-юньдәге матурлыкка сокланып, юлларның нинди икәнлеге сизелми. (Хисләргә бирелү физик кыенлыкларны күрмәскә, сизмәскә булыша!) Соңыннан, фоторәсемнәргә карагач, шаккатып утырасың...

Җирдә йөргәндә меңәр чакрымны да уйламыйча узасың. Тауларда исә һәр метрны узу синнән көч һәм саклык таләп итә. Биек үргә менгән саен, сулыш кысыла. Һава тыгызлыгы азая, шуңа күрә сулау кыенлаша. Кояш ныграк кыздыра, әмма өс киемен салып булмый: көчле ультрашәмәхә нурлар шундук яндырачак. Тәннән тир бәреп чыга. Алай йөрергә күнегелмәгән булса да, һәрвакыт махсус күзлек киясең. Кайчакта аркадагы җиңел биштәр дә артка сөйрәгән кебек тоела башлый...

Тау юллары төрле. Валуннар аша да, вак һәм эре ташлы кабарынкы урыннар, текә кыялар буйлап салынган тар гына сукмаклар буенча, салкын сулы елгалар аша яланаяк уздык. Яшел чирәмгә тотына-тотына текә тауга үрмәләргә, ә аннан – утырып, арт белән шуып төшәргә дә туры килде. Тауда иң мөһиме – игътибарлык һәм сабырлык. Ялгыш адым ясадыңмы, ахыры нәрсә белән бетәсе билгесез...

Тауларда тагын шундый алым бар икән: ышаныч юлы дип атала ул. Бар игътибарыңны җыеп, эчтә булган нindидер киеренкелекне җиңеп, бүлмәдәш кызымның кулына тотынып, тар сукмак буйлап 100 метр чамасы араны бәйләнгән күз белән уздым. Алдан баручы кайда-ничек басасын әйтеп бара, мин исә аның сүзенә таянып атлыйм. Тауларда бу юлны бик азлар уза, чөнки ике яктан да зур җаваплылык таләп ителә. Төркемнән без нибары ике пар (дүрт кеше) генә уза алдык.

Бер атна буе тау юлларында йөреп, шулай «курку терапиясен» үттем. Бу минем өчен үзенә күрә олы бер сынау да, күңелдә кешеләргә карата ышаныч уятуга омтылыш та иде.

Тау башыннан аска карап ятуның рәхәтлеге!..

Тик бу рәхәтлекне тояр өчен ул тау башына менеп җитәргә кирәк әле. Моның өчен алдан төрле яклап әзерләнмичә ярамый, югыйсә тауларга аяк басу хыял гына булып калачак.

Уллу-Тау итәгендә Подушка дигән урын бар. Диңгез өслегеннән якынча 3000 метр биеклектә ул. Иртә белән уянгач, күз карашы иң элек шул кыяга төшә. Югарыдан нindидер бер вәкарь һәм шул ук вакытта зур кызыксыну белән безнең тәрәзәгә карап тора сыман. Ул тауның башы гадәттәгечә очлы түгел, үзенчәлекле – астарак мәйданга охшаган урыны бар. Әйтерсең, ирешелмәслек сәер тау түбәсе.

Гомер дәфтәрендә нәрсә язылганны белмисең, ә җан дигәнең сизгер. Алдагы көннәрнең берсендә шушы Подушканы яуладык бит! Ничек менеп җиткәнне төгәл хәтерләмим. Әмма морадыма ирештем! Гүзәл чәчкәләргә күмелгән, Альп болыннарын хәтерләткән тау түбәсендә йомшак үләнгә сузылып, рәхәтләнеп күкләргә карап ятып тордым. Гәрчә артык фотога төшәргә яратмасам да, бу юлы истәлеккә төшәргә туры килде.

Ул тау түбәсеннән аска карагач нәрсә күренә соң?

Бер якта – Феялар аланы. Кыяга менгәндә искиткеч манзарага тап буласың. Таш кыяларда җәелеп ак төстәге затлы тау рододендроннары үсә – алар «Кызыл китап»ка кертелгән.

Икенче якта – текә тау, аста исә җеп кебек сузылып Адыр-Су елгасы ага.

Ә алда – Уллу-Тауның иң очында – мәңгелек бозлык җәелеп ята. Ул еракта, әмма барыбер аннан салкын бөркелә. Шул яктан искән ачы җиле сискәндерә. Шуңа да карамастан, нindидер бер сихри көч белән игътибарны үзенә тартып тора. Күземне дә ала алмыйча шактый озак карап торам... Аннан, колачымны киң җәеп, сәлам юллыйм да күңелем белән Ана-тауны кочам. Күзләр дымланган, җан нindидер чылбырлардан ычкынган, бар гәүдә мамык кебек... Бу минутларда миннән дә бәхетле, миннән дә көчле, миннән дә нечкә бәгырьле кеше юк... Узган тормышның ачы мизгелләрен оныту өчен Ходай тарафыннан миңа иңдерелгән мөмкинлек, мөгаен, шушы булгандыр...

Тау шарлавыгы

Альп лагерьдан берничә чакрым ераклыкта, якынча 500 метр биеклектә урнашкан. Туры гына агып төшми, баскыч-баскыч ул. Иң өстә, таудан агып төшкән урында – купель кебек урыны бар. Шарлавык астында тору куркыныч: бик көчле агым белән бергә аска тәгәрәп төшү ихтималы да бар. Чәчрәгән тамчылары да битне тешләп-тешләп ала. Суы бик салкын, чөнки ул мәңгелек бозлыктан агып тора. Ташларга тотынып булса да, җайлы урын табып, тау шарлавыгы астында су коендык. Рәхәтлеген белсәгез! Өстән кояш кыздыра, тауларда җил сызгырып уйный, ә без шаулап аккан шарлавык моңын тыңлап, салкын суда коенып рәхәтләнәбез! Суының тәмлелеге тагын!.. Эчеп туйгысыз, гел эчәсе килеп тора...

«Бозлы суда коендылар – бетте болар», – дип уйлап куйдыгызмы? Юк, җәмәгать, берни булмады. Соңыннан борыннан да акмады, тамак та кызармады. Ә менә тән рәхәтләнде ләззәт алып... Шуны да әйтергә кирәк, лагерьдан тау итәгенә кадәр яланаяк уздык. Берничә урында тау елгасын да яланаяк кичтек. (Безнең Себердә «цуцаклап узу», диләр.) Суга керсәң, аяк туңа кебек, ә яшел чирәмгә басуга тәнгә җылы йөгерә. Бу алым – иммунитетны ныгытуга юнәлдерелгән. Табан төпләрендәге махсус нокталар табигый массаж алырга тиеш, ди белгечләр.

Ходаема рәхмәтлемен...

«Кыен булмадымы?» Кайткач иң еш шушы сорауны бирделәр. Урынлы сорау, чөнки мин альпинист түгел, махсус әзерлек узмадым, тауларда туып-үсмәдем, ягъни гади җир баласы. Әмма балачактан тайгада, урман-сазлыклар арасында берничә чакрымнар җәяүләп узып, җиләк җыярга барулар, аркага салып йөк ташулар, кышларын, салкынга карамыйча, чаңгыда чабулар, чөлләләрдә печән чабулар – барысы да, мине ныгыткан, күрәсең. Мин тарткан тормыш авырлыгы да, әледән-әле татыган язмыш тукмагы да, югалтухыянәтләр дә үзенә күрә олы бер чыныгу мәктәбе булгандыр, мөгаен. Шуңа күрә тауларга сәфәр итү минем өчен кыенлык тудырмагандыр...

Тормыш артыннан чабабыз, байлыкка кызыгабыз, үзебезне өстенрәк тотырга тырышабыз, мин-минлек буенча ярышабыз. Нindидер калыпларда яшәргә мәҗбүрбез. Ә вакыт уза тора... Вакытка ияреп гомер еллары да ага. Адәм баласының күзе, уй-фикерләре башка ноктага юнәлгәнгә күрә, чынбарлыкны – тормышның бар матурлыгын күрүдән, тоюдан күпләребез мәхрүм. Әмма күңел бизмәне һәрчак өстен булырга тиеш.

Кабарда-Балкар Республикасы–Казан.

«ТОРМЫШНЫ БЕРГӘ ТАРТСАҢ ҖИҢЕЛРӘК»



Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк Галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик әле.

Илдар КЫЯМОВ, журналист, алып баручы.
гаилә стажы – 28 ел;
балалары – Идел (27 яшь), Ихтыяр (17 яшь).

1 Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Йөзенә игътибар итәм. Нинди хикмәттер ул... Әмма ир-ат күзлегеннән генә карамыйм бугай, иң элек башка: «Карале, нинди чибәр – телевидениедә эшли алыр иде...» – дигән уй килә. Ә Мөршидәгә беренче тапкыр күз төшкән мизгел... Затлы мехлы шакмаклы пальтодан иде ул – пальто якасына бөдрә чәчләре салынып төшкән. Шул бөдрә чәчләренә битараф кала алмадым бугай... Мин инде бу вакытта 3 нче курста укыйм, «Мәгърифәт» газетасында эшлим – фән һәм югары уку йортлары бүлеген алып барам. Ә Мөршидә группадашлары белән редакциягә практика узарга килде. Дөрес, башта күзем бүтән кызга төшкән иде. Ә икенче көнне бүлмәбезгә Мөршидә кабат килеп керде. Шунда нидер булды... Ул бу көн турында әле дә көлдереп сөйли. «Интервью алырга китәсем бар», – ди, ә үзе һаман чыгып китми Илдар. «Бу абый нишләп китми икән соң?» – дип уйлыйм», – ди... Минем үзеннән өч яшькә генә олырак икәнне соңрак белгән әле ул. Аннан очраша башладык. Ул университетның 3 нче тулай торагында тора иде, мин – 5 нчедә. Янына килеп йөрим: Мөршидә коридорга килеп чыкса, бөтен дөньялар нурланып, яктырып китә...

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Гомумән, хатын-кызны яратырга гына кирәк аны һәм ул бөтен очракта да хаклы дип санарга! Әйе, кайчакта онытылып та китә ул, ялгышып та ала... Хатын-кыз бөтен нәрсәне контрольдә тотарга омтыла, шуңа вакыт-вакыт чәүчәләкләнә. Боларның берсен дә явыз нияттән эшләми бит ул: гаилә, балалар хакына тырыша. Ахыр чиктә – ирнең үзе өчен дә тырыша.

3 Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Хыянәтнедер, мөгаен. Әйе, ир-атларның күбесе хыянәтне кичерми. Алар үз-үзләренә нык ышангангадыр да, бәлки. «Монысы белән барып чыкмаса, икенче кешегә өйләнә алам», – дип уйлый торганнардыр. Ә хатын-кызга олы җанлылык хастыр. Кешенең абыну-сөртенүен кичерә, ирнең дә, гомумән, якын кешеләренең ялгышуын аңлый белә, күрәсең.

4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр.

– Мөршидәгә моның икесе дә туры киләдер. Без аның белән коллегалар – бер үк өлкәдә эшлибез, бер үк юлда йөрибез: әдәбият-сәнгатьне яктыртабыз. Ул мине илһамландыра белә: һәрвакыт ниндидер планнар, яңа проектлар белән яна. «Әйдә, моны эшләп карыйбыз! Без аны булдырабыз!» – ди. Комфорт тудыра алуына да сокланам. Ходай Тәгалә тарафыннан миңа җибәрелгән бүләк: яхшы хатын, йорт җанлы, әйбәт хуҗабикә ул. Өч егет арасында яшәсә дә, зарланганы булмады. «Лимоннан лимонад ясый бел» дигән законга таянып, улларыбызны кызлар эшләрен эшләргә дә илһамландырды. «Татар егете» бәйгесендә җиңгәч, Идел: «Кер юган ирләрне ат тибә торган була, дип әйтә бабай, андый хатын-кыз эшләрен эшләргә ярамый», – дип, интервью бирде бирүен. Әмма чынлыкта ул барысын да эшли. Ихтыярны да шулай эшләтергә тырышабыз. Әмма анысы башка буын баласы – дөньяны үзенчәрәк күрә.

5 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була ала мы?

– Әлбәттә! Ир белән хатын булудан бигрәк, хәзер күбрәк дуслар түгелме икән әле без?! Дуслык бездә бик кыйммәт йөри. Икәү үзара гына түгел, балалар белән дә дус без. Кайвакыт дуслар, гаилә танышлары: «Сез нишләп Иделгә «улым» дип әйтмисез, гел исеме белән дәшәсез?» – диләр. Бу аны дус, тиң күрүдәндер дип уйлыйм. Без аның белән коллегалар. Ул да журналистлар берлеге әгъзасы, уртак проектларыбыз бар, без сәхнәдә дә бергә. Ә Мөршидә белән дуслык башка... Аннары балалар чыгып киткәч, башка дустың да калмый бит инде. *(Көлә.)* Соңгы вакыт шуны сиздем: машинада бергә каядыр барганда иң күңел түрендә яткан сүзләр сөйләнә. Машина эче кечкенә, ул – чикләнгән җирлек, шуңа бер-берегезгә ачыласыз дип аңлатты белгечләр. Якынлык аннан да тора икән әле...

6 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме әле?

– Истә! «Әйдә, миңа кияүгә чык әле!» – дидем... Без инде өч ел очрашып йөргән идек. Шаярып сөйләшкәндә Мөршидәдән гел көләм: «Сине курс эше генә харап итте», – дим. Мин университетта әйбәт укыдым, «кызыл диплом»га тәмамладым. Танышу белән үк Мөршидәгә: «Курс эше язганда китапханәгә кил, булышырмын», – дигән идем. Ә аңа нәкъ менә шундый ярдәм кирәк булган икән. Минем белән очрашырга теләмәсә дә, килергә мәҗбүр булды. Бер килде, ике, өч... Шулай дуслашып киттек. 1994 елның җәендә өйләнештек без. Мин инде бу вакытта университетны тәмамлап, консерваториягә укырга кергән идем. Чирмешән белән Яшел Үзән арасы шактый ерак – әниләр гел килеп йөри алмыйлар, шуңа күрә башта «парламентёр» булып үземә кайтырга туры килде. Кызны ничек сорыйлар, нинди сүзләр әйтәләр – берсен дә белмим... Кайттым Шырданга, Мөршидәнең әнисе белән сөйләштем. Инде эш бетте, поездга чыксам да ярыйдыр дип уйлыйм. Ә әнисе: «Әтиегез белән сөйләшегез», – ди... Бабай ишек төбендә утырып тора. Килдем янына, тик сүз башларга йөрәк җитми... Бабай дөнья күргән кеше, аңлады: «Сез бергә булырга уйладыгызмы?» – ди.

7 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?

– Дөрестер ахрысы. Әни вафатыннан соң әти үзе генә дүрт ел яшәде. Ул безнең философ иде, бик күп укыды. Дөнья да күргән: биш ел Казакъстанда яшәп кайтканнар. Безгә белдерергә теләмәгәндә, әни белән казакъчага күчәләр иде... Берсендә ачылып китеп сөйләшәбез әти белән. «Улым, оят булса да әйтим, хатын ул берзаман әнигә әйләнә икән», – ди. Кемдер: «Ярый әле хатыннар бар, / Безне карап йөртергә», – дип җырлый бит – дөрес ул... Әнинең күп кенә сыйфатларын Мөршидәдә дә күрәм. Аларга озак аралашырга гына туры килмәде: без өйләнешеп дүрт ел узуга әни вафат булды. Әмма кайткалап йөрдек бит – Мөршидә аңа килен рәхәте күрсәтергә өлгергәндер.

8 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Моны Мөршидә үзе сөйләсә дөресрәк булыр иде дә... Ахырдан ачыклангача, йөри башлагач, һаман үбешмибез дә үбешмибез икән... Ә ул: «Менә үбешкәч, сезгә туңдырма алам», – дип, бүлмәдәш кызларына вәгъдә биргән. Кызлар шуны көткән – һаман сорап үзәгенә үткәннәр. Һәм көннәрдән бер көнне Мөршидә кыю адымга барды... Безнең мөнәсәбәтләрне тагын да җылытып, нурландырып җибәрде... Беренче адымны кайчак ясау да кирәктер, чөнки безнең татар егетләре, бигрәк тә авыл баласы басынкырак тәрбияләнә. Тик барысы да чамадан гына чыкмаска тиеш.

9 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?

– Ышанычлы терәк, таянырлык җилкә, авыр чакта ярдәмче булудыр... Тагын – матди байлыклар тудыра алу. Мөршидә яшьләргә гел: «Кияүгә чыкканда иң элек бу кеше балаларымның атасы була алырмы дип уйларга кирәк», – дип киңәш бирә. Һәм дөрес әйтә. Бүгенгеләр булачак ирнең беренче чиратта машинасы, фатиры бармы икәнен уйлый – әкияттәге кебек, ак атта шаһзадә килүен көтә. Шулай булса бик әйбәт, әлбәттә. Тик тормыш икенче төрлерәк шул. Аны бергә тартсаң җиңелрәк... Үзеңне шуңа әзерләргә кирәк. Безгә мәктәптә «Гаилә тормышы этикасы һәм психологиясе нигезләре» дигән дәрес керде. Аны укыткан Сания апа Мәссаровага мин гомер буе рәхмәтле. «Гаилә тормышы суыткычтан башлана», – дия иде ул. Киңәшләре ярады! Өйләнештек, этика дәресләре буенча беләм – безгә суыткыч кирәк. Аны ничектер алып кайтырга кирәк һәм бу проблеманы мин – яшь ир хәл итәргә тиеш. Мөршидәнең җизнәсенә мөрәҗәгать иттек ул чакта. Шул суыткычны алып кайтышкан өчен аңа гомер буе рәхмәтлемен.

10 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр. Бу, чынлап та, шулаймы?

– Чибәрлеге куркытмыйдыр аның, ә менә көчле булуы... Мөршидә, мәсәлән, бик тәвәккәл кеше. Аның бу сыйфатына хәзергәчә сокланам. «Главное – ввязаться в бой, а там видно будет», – ди ул еш кына. Тәвәккәл дигәннән, бер очрак гел онытылмый. Ихтыярга биш яшь чагында, Абхазиягә ял итәргә бардык. Анда диңгездә гел дулкыннар. Яр буена ук килгән Ихтыяр, аяк киемнәрен ялгыш суга агызып җибәрде дә, аларны алып киткән дулкыннар артыннан үзе дә диңгезгә керә башлады. Кечкенә баланы әчкә алып кереп китәргә шул дулкыннар җитәр дә иде... Мөршидә кай арада килеп җитте – кай арада улыбызны судан тартып та чыгарды. Ә мин шок хәлендә басып торам... Аның әтисе дә, абыйлары да көрәшчеләр – алардагы батырлык Мөршидәгә дә күчкән.

11 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике Галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.

– Шимбә җиттеме, идән юарга тотына Мөршидә. «Таптамагыз, анда басмагыз – монда басыгыз», – ди... Ул көнне башымны алып кая да булса чыгып китәргә тырышам – тынычлап җыештырсын. «Кайнанаң килми бит, нәрсәгә атна саен юасың ул идәнне?» – дим. «Мин хәзер үзем кайнана, киленем килергә мөмкин», – ди ул... Авылдан киткәндә дә идәнне юып китә ул – чистага кайтып керү күңелле, ди.

12 Шундый очракны күзаллыйк әле: сез, ачыгып, арып-талып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән.

– Кафега чыгып китмибез – алай барыбер озак була. Берәр нәрсәгә заказ бирергә дә мөмкин. Мөршидәнең арыганын күрәм икән, тотам да үзем пешерәм. Бездә ул гадәти күренеш. Гомумән, кайсыбыз алданрак кайта – шул ашарга әзерли тора. Балаларны да шуңа өйрәттек. Пылау да пешерә беләм, фрикаделькалар да ясыйм, омлет та. Ашны әйтмим дә... Савыт-сабаны да юышам. Ишетеп беләм, хәзер авыл ирләре дә хатыннарына шулай булыша. Алар да шәһәр шартларында яшиләр бит.

13 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар соңга калучан.

– Бездә мин соңга калам, ахрысы... Мөршидә ул бөтен җиргә вакытында йөри, хәтта алданрак та барырга тырыша. Мин өйрәнәсе килгән тагын бер яхшы сыйфаты бу аның...

Тулысынча укыгыз »





СОРАУ—ҖАВАП



Сорауларга терапевт-кардиолог, медицина фәннәре кандидаты Ленар КАШАПОВ җавап бирә.

? Әни бер тапкыр микроинфаркт кичерде. Хәзер йөрәге борчый башласа, седатив препарат куллана. Табиблар кан тамырларын киңәйтә торган препаратлар эчәргә куша бит. Алар арасында аерма бармы?

Седатив препарат, гадирәк итеп әйткәндә, тынычландыра торган препарат инде ул. Монда әниегезнең «йөрәк борчуы» дип, нинди билгеләрне атавы мөһим. Бәлки, ул йөрәк түгел, невралгия, остеохондроз, стресс фонындагы билгеләрдер? Седатив препаратларның файдасын тоя икән, бәлки, бу нерв системасы авыруыдыр. Кан тамырларын киңәйтә торган препаратлар күп, аларны бары тик табиб кына билгели. Бу ике группа препаратларын чагыштыру дөрес булмас.

? Әти «күкрәк яна» дип зарлана кайчак. Майлы ашаудан күрә бу авыртуны. Мин йөрәк түгелме икән дип борчылам. Кайсыбыз дөрес уйлый?

Күкрәкнең кызып торуы йөрәк авыруы белән дә, ашкайнату системасы (мәсәлән, гастрит) белән дә бәйле булырга мөмкин. Бу авыру билгесе кайсы очракта килеп чыга – шуны аңларга кирәк. Физик нагрузкадан соң авырта башласа, йөрәк белән бәйле дип фаразларга була. Майлы ризык ашаганнан соң сиздерсә, ашкайнату системасы белән бәйле булырга тиеш. Төгәл җавапны табиб кына әйтә алачак.

? Инсульт башланганын сизгән кеше кулдагы һәр бармагын һәм колак яфрагын энә белән тишкәләсә, инсульттан сакланып була дип укыганым бар. Дөресме бу киңәш?

Без, табиблар, бары тик клиник киңәшләр белән генә эш итәбез, алар авыруны кисәтүгә һәм дәвалауга нигезләнә. Мин бу киңәшне халык методикасына кертер идем. Чөнки ул бернинди клиник киңәшләргә дә нигезләнмәгән.

Кадерле укучылар!
«Сорау–җавап» рубрикасына сездән сораулар кабул итәбез.
Җавап бирүче белгечләр: педиатр, гинеколог, стоматолог, невролог, хирург-ортопед, кардиолог, иммунолог-аллерголог, гастроэнтеролог, эндокринолог, офтальмолог һәм башкалар.

Үзегезнең һәм балаларыгызның сәламәтлегенә кагылышлы сорауларыгызны – 8 (843) 2-22-09-77 телефоны аша, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт адресы буенча яисә ssuum@yandex.ru электрон адресына «Сорау–җавап» дип язып җибәрә аласыз.

Фото: ru.freepik.com



Сорауларга Республика балалар клиник хастаханәсе балалар стоматологы Римма САФИНА җавап бирә.

Газлы сулар һәм соклар баланың тешенә йогынты ясыймы?

Әйе, чөнки аларның составында эмальгә тискәре йогынты ясый, кариес китереп чыгара торган берничә матдә бар. Беренчедән, чамадан тыш күп шикәр. Тештәге элементлар шикәр белән никадәр озаграк контактта булса, шулкадәр зыянлырак. Авыз куышлыгындагы бактерияләр дә шикәр белән туклана. Нәтиҗәдә, тешләргә зыян салучы кислота барлыкка килә. Икенчедән, газлы су һәм сокларның күпчелегендә болай да кислоталар бар: лимон, ортофосфор кислоталары һәм башкалар. Аларның һәммәсе эмальне боза. Нәтиҗәдә, кариес барлыкка килә.

Бала еш кына эчтән яңагын тешли. Аннары шул урында стоматит башлана. Дәвалап кына бетерәбез, тагын шул ук хәл кабатлана. Ничек котылырга бу уңайсызлыктан?

Төгәл сәбәбен ачыкларга кирәк: тешләме дөрес түгелме, өске яисә аскы теш дугалары киңәйгәнме, буккаль яки лингваль тешләм формасымы? Шуны ачыклаганнан соң белгечкә барып, бу кимчелекләрне төзәтергә була.

Балаларга электр теш щеткасын кулланырга ярыймы?

Электр теш щеткаларын 3 яшьтән кулланырга мөмкин. Ләкин баланың тешен сез бары тик үзегез чистартырга тиеш! Чөнки 7-8 яшькә кадәр балаларга үзләренә электр щеткасы куллану тыела. Моны баланың теш эмале йомшаклыгы белән аңлатырга була. Ә төрле якка әйләнеп, пульс биреп торучы щетка файда урынына зыян гына китерергә мөмкин.

Медосмотр вакытында улыбызның тешләме дөрес түгел, диделәр. Минеке дә дөрес түгел ул, шул килеш яшим, зыяны юк кебек. Төзәтмәсәк, нәрсә булыр икән?

Ортодонтка консультациягә барып, әлеге патологиянең төрен билгеләргә киңәш итәм. Тешләм дөрес булмау аркасында өзлегү барлыкка килергә мөмкин: чигә-түбән казналык системасы дисфункциясе (бу казналыкның девиациясенә, колаклардагы тавышка, авызны ачкан йә япкан чакта эләгеп калуына, бруксизм, еш баш авыртуга китерә) башлануы бар, тиз арада эмаль зарарлана, пародонтоз барлыкка килә, сөйләшүдә үзгәрешләр сизелә, сулау һәм йоту кыенлаша.

Нәниләргә күчтәнәч!
Телефон камерасын QR-кодка якынайтып, аудиоформатта язылган әкиятне балагызга тыңлатыгыз.



Республика балалар клиник хастаханәсенең матбугат хезмәте җитәкчесе Зөһрә Гыйбадуллина ярдәме белән әзерләнде.

ТЕЛЕФОННАН СӨЙЛӘШҮ ЭТИКЕТЫ

Смартфоннарсыз тормышыбызны күз алдына да китермибез инде хәзер. Тиз арада кешеләр белән элемтәгә керү җайланмасыннан башка ничек эшкә йөрергә, гомумән, ничек яшәргә кирәк?! Элек ничек яшәлгән икән дип, әледән-әле аптырап куябыз. Соңгы 10–20 елда телефон безнең тормышта зур урын алып тора. Көндәлек тормышыбызга, үз-үзебезне тотышыбызга да бик нык тәэсир итте. Хәзер инде кәрәзле телефоннар куллануда аерым бер этикет барлыкка килде. Әмма күпләребез ул хакта белмиме, әллә белергә теләмиме... Тирә-яктагыларны хөрмәт итү әнә шул телефонны ничек куллануда да чагыла ул. Әдәп-әхлаклы булу укымышлы булу белән генә чикләнми, иң элек үз-үзеңне дөрес тотуда күренә. Телефонны кулга алган саен, дөньяви һәм эшлекле этикет буенча консультант Ләйсән АТНАБАЕВАның киңәшләрен искә төшерик.



Җәмәгать урыннарында телефоннан сөйләшкәндә нәрсәне истән чыгармаска кирәк?

Беренче чиратта шуны истә тотарга кирәк: телефон аша шәхси сөйләшү җәмәгатьчелек өчен түгел. Шәхси темалар яки көнкүреш мәсьәләләре турында тирә-яктагыларга ишетелерлек итеп сөйләшергә кирәкми, моны аулак урында эшләү дөрес булыр.

Сөйләшү кинәт кенә өзелә икән, кем шалтыратырга тиеш?

Бу очракта кагыйдә берәү генә: шалтыраткан кеше кабат шалтырата.

Күп очракта аралашкан вакытта әңгәмәдәшләр телефон шалтыратуына бүленә. Бу дөресме?

Шалтыратучыларга йә смс язучыларга түгел, турыдан-туры аралашкан кешеләргә өстенлек бирегез. Янәшәгездәге кеше кесә телефонына шалтыратучыга караганда күбрәк игътибарга лаек. Әгәр дә бик мөһим шалтырату икән, әңгәмәдәшегезгә аңлатып, гафу үтенегез һәм читкәрәк китеп сөйләшеп алыгыз. Дусларыгыз, якын кешеләрегез белән җыелып, кичне рәхәтләнеп үткәрергә телисез икән, телефоннардан бөтенләй баш тартыгыз. Бу яхшы традициягә дә әйләнергә мөмкин.

Шалтыраткан кешең җавап бирмәсә йә өзеп куйса, нишләргә?

Этикет буенча, берничә кат шалтыратып йөдәтергә ярамый. Звонок дүрт-биш тапкыр барганнан соң да, җавап бирмәсәләр, шалтыратуны өзү дөрес булыр. Берничә сәгать үткәч кенә номерын кабат җыя аласыз. Әгәр дә инде абонент сезнең шалтыратуны өзсә, вакыты булгач ул үзе сезнең номерны җыяр.

Хәзер аудиохәбәр җибәрү популярлашты. Мондый төр хәбәрне кемнәргә җибәрергә ярый?

Аудиохәбәрне бары тик шәхси хат алышуда гына кулланырга ярый. Анда да саннар булмаса. Ышанычыгыз, кирәкле мәгълүматны язып алу өчен, беркемнең дә сезнең хәбәрне ун кат тыңлап утырасы килми. Әдәп саклап, хәбәрне бу очракта текст итеп языгыз.

Телефонның тавышын тавышсыз режимга кайчан һәм кайда күчерергә кирәк?

Гомумән, соңгы вакытларда кайда булуга карамастан, телефонның тавышлы режимын куллану тәрбиясезлек дип санала. Искәрмә өлкәннәр һәм начар ишетүчеләр өчен генә. Төрле чаралар вакытында, утырышларда, эштә (хезмәттәшләрегезгә комачауламас өчен), җәмәгать биналарында телефонны һичшиксез тавышсыз режимга күчерергә кирәк.

Урамда барганда йә җәмәгать урыннарында телефоннан сөйләшкәндә колакчыннар кулланырга ярыймы?

Әйе, ярый. Танышыгызны очратсагыз йә сезгә мөрәҗәгать иткәннәрен күрсәгез, колакчыннарны һичшиксез салыгыз. Моннан кала, куркынычсызлык максатларында, юлдан чыккан вакытта гарнитураны салырга киңәш итәм.

Нәрсә ул «өч метр кагыйдәсе»?

Бу бик шартлы кагыйдә, әмма үтә дә яхшы. Әлеге кагыйдә буенча, телефоннан сөйләшкәндә кешеләрдән өч метр ераклыкта булу мөһим. Дөрес, метрлы тасма тотып, ара үлчәп йөреп булмый. Шулай да аек акыл белән эш итү яхшырак – шәхси сөйләшү икән, читкә китеп дәвам итегез. Яисә сөйләшүне кичектерегез, мессенджердан кулланСагыз, тагын да яхшырак.

ЗАТЛЫЛЫК ХУШ ИСЕ

«Хушбуй – күзгә күренми торган, әмма камил модалы аксессуар. Ул хатын-кызның килүе турында хәбәр итә һәм ул киткәч, аның барлыгын искә төшереп тора...» Матурлык тудыручы бөек Коко Шанель сүзләре белән килешми мөмкин түгел. Нинди генә затлы кием кисәк тә, чәчләребезне матур итеп ясасак та, образыбызга соңгы нокта куяр өчен, кулыбыз хушбуйга үрелә. Хушбуй сибенмичә өйдән дә чыгып китмибез. Хатын-кыз тормышында әнә шундый зур урын алып тора кечкенә генә флаконнардагы затлылык символы. Хушбуй аша үзебезнең асылыбызны, хәтта хыялларыбызны чагылдырырга тырышабыз. Шуңа күрә дә парфюмны озаклап сайлап алабыз. Үз гомеребездә күпме хушбуй иснәп караганбыздыр. «Үз хуш исеңне» табу җиңелләрдән түгел. «PARLI»* парфюмер компаниясе белән танышсагыз, үтә дә катлаулы бу эш җиңеләячәк. Сез, һичшиксез, үз хушбуегызны табачаксыз!

«PARLI» – парфюмерия җитештерүче Россия компаниясе. Коллекцияләрендә парфюм модасындагы классиктан башлап ультразаманча тенденцияләрне җыйган хуш исләр бар. Менә инде ун елдан артык компания атаклы парфюмерия кутюрьелары белән берлектә затлы хушбуйлар җитештерә. Хушбуй безнең тормышка матурлык һәм ләззәт бүләк итә. Продукция белән беренче очрашу секундлары бәһасез. Кибет киштәсендәге йөзләгән хушбуй савытлары арасыннан күңелгә ошаганын алабыз бит. Шуңа да «PARLI» парфюмы матур хуш ис һәм эксклюзив флаконнар кушылмасы.



Пыяланы кулдан шомартып ясалган эксклюзив флакондагы капкачы металл гравировкалы **«MISSION»*** премиаль линейкадагы парфюмны үз итүчеләр дә бар инде. Компаниянең яңа хуш исләре белән таныштырыйк. **«MISSION Liberty»*** парфюмер суының хуш исе сезне беренче секундтан ук ирек дигән дөньяга алып китәр. Кыю, шул ук вакытта үтә дә нечкә хисле ис ул. Чәчәк һәм җиләк-җимеш ноталары бер-берсе белән гармония булдырып, җылы ванильле-пудра шлейфы тудыра. Хуш ис бәйләме композициясен агач нотасы, орхидея, ак мускус тәгәлләр. Романтик стилен күрсәтергә теләгән яшь ханымнарга бик килешәчәк ул.



Компания ир-атлар турында да онытмый. Затлы креатив күн белән бизәкләнгән флаконнарга салынган **«Your Leader Way»*** хушбуйлар сериясе – янәшәгездәге сөеклегез өчен. Тәмле агач, урта диңгез хуш исле бу парфюмны сөрткән ир-аттан затлылык бөркелеп торыр. Тиздән 23 февраль. Бу хушбуй – аның өчен иң шәп бүләк!



«YOUR Look»* хушбуе үтә дә купшы. Әлеге хуш ис нәзакәтле хатын-кызларны чагылдыра. Өлгергән груша һәм алсу борыч исе сезне кочагына бөтерер. Ваниль белән ак мускуска төренгән шлейф, Коко Шанель әйткәнчә, сезне бик озак искә төшереп торыр. **«YOUR Only»*** хушбуе исә сибенгән хатын-кызлардан наз, нәзакәтлелек бөркелеп торыр. Бу хуш ис беркемне дә битараф калдырмас, бигрәк тә ир-атларны. Тәмләткеч ноталы «җылы» исләр, җылы хисләр уятыр.



«PARLI» компаниясе яшь туташларны да сөендерә. Махсус алар өчен **«CRUSH»*** линейкасы булдырган. Махсус яшьләрчә дизайн белән ясалган тартмалардагы бу хушбуйлар кыю яшь буын – кызларыгыз, оныкларыгыз, сеңелләрегез өчен шәп бүләк. Флакондагы баллы җиләк-җимеш, саф диңгез ноталары, хуҗабикәсенең яшьлеген, энергиясен тагын да ассызыклар.

Затлы хушбуйлар кыйммәт булырга тиеш дигән фикерне тамырдан үзгәртте «PARLI». Кулланып караганнан соң сез моңа үзегез дә ышанырсыз. Бу хушбуйларны һичшиксез үз итәрсез! Продукцияләрне маркетплейслардан, Казанда Пушкин урамы, 2 нче йорт адресы буенча урнашкан «Золотое яблоко» кибетеннән, Россия буенча косметика-парфюм сатучы кибетләр челтәреннән, «PARLI» интернет-кибетеннән, сатып алырга мөмкин.

** Парли; Мишн; Мишн Либерти; Юлук; Юонли; Йор лидер вэй; Краш*

Реклама

Тайга бәлеше

Бурятиядәге сәяхәттән кызыклы язмышлар гына түгел, күчтәнәч тә алып кайттык. Тайга бәлешен пешереп караганыгыз булмагандыр әле! Безнең редакция кызлары аны шундук танып алды. «Актаныш бәлеше бит бу!», «Юк, Арчаныкы!» дип, үзләштереп тә маташтылар. Ә сез аны тайга күчтәнәче дип кабул итегез әле менә!
Табигать кырыс булгангамы, Бурятиядә бәлешне бик туклыклы итеп пешерәләр. Ул тамакны туйдыручы гына түгел, җылытучы, энергия чыганагы да булсын. Аны героебыз ЛАРИСА СӘХИЕВА мичтә үк пешереп күрсәтте!
Лариса ханымның әнисе Флёра апа дүрт айлык вакытта – 1940 елда әти-әнисе белән Саба районы Мишәбаш авылыннан Бурятиягә күченеп килгән. Кечкенәдән татарча гына сөйләшеп үскән бәләкәй Лариса. Аларның йортында үзеңне гел татар авылында кебек хис итәсең. Хуҗабикәнең кунакчыллыгы, әниләрчә кайгыртуы, кунакларны сыйларга тырышып, мул табын әзерләп куюы, кыстый-кыстый сыйлавы гел татарча инде менә! Үзе орчык кебек, гел мич белән табын арасында бөтерелә. Йомшак, ипле итеп сөйләшүеннән үк укытучы булуы сизелеп тора. Лариса ханым – этнопедагог, Тэгда авылында «Умырзая» татар мәдәни үзәген җитәкли, авыл балаларын татар мәдәнияте белән таныштыра, төрле бәйгеләрдә катнаша алар. Тайга үләннәрен тукыма өчпочмакка салып, матур, хуш исле сувенирлар да тегә әле ул. Кыстыбый, пәрәмәч, бөккәнне әнисеннән күреп пешерергә өйрәнеп үскән. Әчәгеләрдән ясаган бөккәнне аеруча яраталар бу гаиләдә. Бәлешне дә еш кына әнә шулай пешерәләр. Әмма бу юлы Казан кунаклары өчен бәлешне ит белән әзерләделәр.



Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия



Кирәк

Камыр өчен:
1 йомырка / 1 стакан үсемлек мае / 1 стакан сөт яки су / тәменчә тоз / он

Эчлек өчен:
4-5 бәрәңге / стакан ярым бөрткән дөге / ярты килограмм иттарткычтан чыгарылган сыер ите (майлырак булса, бәлеш тәмлерәк була) / 1 баш суган / тоз









Эш барышы

■ Иң элек бәлешнең эчлеген әзерләп куябыз. Ит янына шакмаклап тураган бәрәңге, суган, дөге салабыз. Тәменчә тоз сибеп, барысын бергә яхшылап туглыйбыз.

■ Йомырканы сытып, өстенә май, сөт (су) салабыз, тоз сибәбез, яхшылап болгатып, камыр басабыз.

■ 2/3 өлешен аерып алып камыр җәябез. Монысы бәлешнең асты булачак.







■ Камырны җайлап кына табага җәябез дә эчлекне бушатабыз.

■ Эчлекнең өстенә 50 г сыер мае салабыз, бәлеш тагын да майлырак һәм сусылрак булачак.

■ Камырның калган өлешен җәеп, бәлешнең өстен каплыйбыз. Матур бизәкләр ясап, өстен тагын бер кат япсагыз да була.



■ Бәлешне мичтә (авыл мичендә) бер сәгать пешерәсе.

■ Пешеп чыккан бәлешнең өстен мул итеп сыер мае белән майлагыз.



ТАТМЕДИА

ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРГА ЯЗЫЛГАН ӨЧЕН КАР КӨРИ ТОРГАН ҖАЙЛАНМА, ТЕЛЕВИЗОР ҺӘМ БАШКА БҮЛӘКЛӘР

Бүләкләр 2023 елның 9 февралендә уйнатылачак



1 языл

«ТАТМЕДИА» АҖнең бер газета һәм бер журналына языл (акциядә катнашучы басмалар белән tatmedia.ru сайтында танышып була)

2 җибәр

«Акция» билгесен куеп, язылу квитанцияләренең копиясен безгә 21 гыйнварга кадәр җибәр (телефон номерыгызны язарга онытмагыз!). Адрес: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

3 от

телевизор, электр иттарткыч, электрогриль һәм башка бүләкләр от. Иң зур бүләк – кар көри торган җайланма!



Әлеге чараны оештыручы, кагыйдәләре, бүләкләр саны, уйнату вакыты һәм урыны буенча мәгълүматны tatmedia.ru сайтында белә аласыз. Акция 2022 елның 22 октябреннән 2023 елның 20 мартына кадәр уздырыла.

Реклама. Яшь чикләве – 16+

тест: аралашучанмы сез?

Аралашучан кешеләр теләсә кем белән тиз дуслаша, һәрчак уртак темалар таба. Ә сез элемтәләрне тиз урнаштырасызмы? Әйдәгез, тикшереп карыйбыз!

1. Сез зур бер җитәкче янына керергә торасыз. Үзегезгә кушылган эшне уңышлы башкару нәкъ менә шушы кешегә бәйле. Кабинетка кергәч, кемне күрергә телә р идегез?

а) керүгә иронияле караш ташлаячак чагыштырмача яшь ир-егетне;
б) сезгә тәнкыйть күзе белән караячак яшьтәш ханымны; в) «бимазалап йөри шунда!» дигән кыяфәт чыгарып утырган төксе бер ир-атны.

2. Паркта буш эскәмия күреп алдыгыз. Сез аңа төрлечә утыра аласыз:

а) бөтен урынны биләгәндәй, уртага җәелеп; б) аркагыз белән борылып, читенә генә; в) ике яктан да буш урын калдырып, уртага утырасыз.

3. Компаниядә танышырга мөмкин булган өч ир-ат бар. Кайсысын сайларсыз:

а) яшь, шаян, үзен ышанычлы тоткан һәм үзенә игътибар иттерергә тырышканын; б) элегант киенгән урта яшьләрдәге вәкарь ирне; в) үз-үзен тотышы белән башкалардан дәрәҗәлерәк күренгән өлкән яшьтәге ир-атны.

4. Кафеда кеше бик күп. Бары бер урын гына буш, ләкин анда таныш түгел ир-ат утыра. Сез:

а) чак кына елмаеп, каршысына килеп утырасыз; б) битараф кыяфәт чыгарып, ул кешегә яныгыз белән борылыбрак утырасыз; в) башка урын бушаганны көтәсез.

5. Чираттагы ялыгызны кайда уздыру турында сүз чыкса, сез:

а) моңа кадәр үзегез булмаган урыннарга туристик маршрут сайлыйсыз;
б) диңгез буена барасыз; в) авылда яки дачада ял итүне кулай күрәсез.

6. Үзегезгә ошаган берәү белән танышырга телисез. Ләкин ул сезгә игътибар итми. Сез:

а) танышу ниятеннән ваз кичәсез (ләкин үртәләсез); б) үпкәлисез, аны эчтән ачуланасыз; в) аның белән аңлашырга омтыласыз.

Балларны саныйбыз:

1. а – 3 балл, б – 6 балл, в – 1 балл.
2. а – 3 балл, б – 1 балл, в – 6 балл.
3. а – 2 балл, б – 6 балл, в – 3 балл.
4. а – 5 балл, б – 3 балл, в – 1 балл.
5. а – 6 балл, б – 3 балл, в – 1 балл.
6. а – 4 балл, б – 1 балл, в – 6 балл.

11 баллга кадәр. Үзегезне генә ярату холкыгызның төп сыйфатыдыр, күрәсең. Башкалар алдында ачылырга ашыкмыйсыз, дөрес аңламауларыннан куркасыз. Кешеләр белән бик сак аралашасыз. Тәнкыйтьне яратмыйсыз.

12–23 балл. Сезгә кешеләр белән аралашу, таныш булмаган компаниядә булу ошый. Ят кешеләр арасында бераз кыенсыну сизәсез. Әдәпсезлекне авыр кабул итәсез. Кайчагында кешеләр турында нәтиҗәне ашыгыбрак чыгара торган гадәтегез бар. Ялгызыгыз гына калырга яратасыз. Холкыгыз күпләргә ошый.

24 баллдан күбрәк. Сез бик аралашучан кеше. Ят кешеләр белән җиңел танышасыз. Командировкага яки таныш булмаган кеше янына бару сезнең өчен проблема түгел. Шулай да кайчагында сез дә кешеләрдән ялыгасыз. Мондый вакытта телефоннарны сүндереп, бераз ял итеп алу комачауламас.

йолдызнамә февраль

Кучкар. Һөнәри өлкәдә иң уңышлы чорларның берсе. Уйламаган җирдән ярдәм булыр. Финанс ягыннан тотрыклылыкны саклар өчен яңа юллар уйларга туры килер, иң мөһиме: мотивацияне югалтмагыз.

Үгезбозау. Җиң сызганып эшләргә туры киләчәк. Аның каравы, нәтиҗәсе сөендерер. Үгезбозауларга хас үҗәтлек аркасында эштә бераз киеренкелек күзәтелергә мөмкин, низаглардан сакланыгыз.

Игезәкләр. Алдыгызда яңа мөмкинлекләр ачылырга тора. Уңышка йөз тоткан Игезәкләр өчен бу ай мөһим сөйләшүләр, очрашулар белән үтеп китәр. Фикердәшләрегезнең, дусларыгызның ярдәмен тоярсыз.

Кысла. Үз рәхәтегезгә яшәп ала торган иркен чор. Яңа эшкә тотынырга ашыкмагыз, ә менә күптәнге мәсьәләләрне хәл итәргә алынсагыз, отарсыз. Килешү, аңлашу, каршылыкларны җиңү кебек эшләр җиңел башкарылачак. Шәхси тормышта күңелле вакыйгалар көтелә.

Арыслан. Көтелмәгән очрашулар, танышулар ае. Яңа белем алу, яңа эшкә тотыну өчен яхшы вакыт. Күптәнге идеяләрегезне тормышка ашыру өчен кулай форсат чыгуы ихтимал.

Сөмбелә. Уңыш һәм яхшы үзгәрешләр вәгъдә итүче ай. Кызыклы һәм актив, ләкин ыгы-зыгылы чор булыр. Моңарчы таныш булмаган эшләр белән шөгыльләнергә туры килер. Ай ахырына таба финанс өлкәсендә күңелле яңалык көтелә.

Бизмән. Амбицияләрегез югары. Үз-үзегезгә артык ышануыгыз аркасында четерекле хәлдә калуыгыз бар. Айның икенче яртысында планнарыгызга ачыклык кереп, артыгызда көчле тыл барлыгын тоярсыз.

Чаян. Күчемсез милек белән бәйле эшләр, сату-алу, финанс операцияләре өчен кулай чор. Моңарчы артык катлаулы булып күренгән проблемалар уңай гына хәл ителер. Ләкин уртак проектларга алынмый торыгыз.

Укчы. Ыгы-зыгылы тормышыгызга акрынлап кына тотрыклылык килеп керер. Карьера һәм бизнес өлкәсендә нәтиҗәләр сөендерер. Ялгыз гына башкара торган эшләргә тотынсагыз, отарсыз.

Кәҗәмөгез. Бер яктан – тотрыклылык күзәтелсә, икенче яктан яңа идеяләр бөтереп алыр. Эшлекле тәкъдимнәр булыр, ләкин аларны кабул иткәнче, яхшылап уйлагыз, оттыруыгыз ихтимал. Бу айда очрашулар күп булыр, файдалы яңалык ишетерсез.


Сукояр. Кыю адымнар ясаудан, вакыйгаларны үз кулыгызга алудан курыкмагыз – йолдызлар сезнең яклы. Шәхси өлкәдә дә, карьерада да уңышка ирешерсез. Көтелмәгән керем алырсыз.


Балыклар. Көчләрегезне тулыландырып, сәламәтлекне кайгыртырга вакыт. Иҗат итү, күңелгә рәхәт эш белән шөгыльләнү уңыш китерәчәк. Күптәннән кул җитми торган эшләрне хәл итү җиңел булачак. Ай ахырына таба һөнәр өлкәсендәге күңелле яңалык сөендерер.

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА, Лилия ГӘРӘЕВА, Алсу ШАКИРОВА әзерләде.









КАЛЛИГРАФИЯ – ХӘЯТЕМНЕҢ БЕР ӨЛЕШЕ

Талантлы каллиграф, мөгаллим Рамил Насыйбуллов Россия Ислам институты карамагындагы «Ән-Намир әл-Мөхаттат» гарәп классик каллиграфиясе һәм көнчыгыш сәнгатьләре үзәгендә 11 ел укыта. Ул – шушы үзәкнең алыштыргысыз директоры, хөрмәтле һәм абруйлы хәзрәтебез.

Аның каллиграфик әсәрләре Татарстан, Россия, Төркия, Малайзия, Индонезия, Германия, АКШ, Таиланд, Канада һәм башка дәүләтләрдәге тупланмаларда саклана. Алар арасында күп кенә Президентларның тугралары да бар.

Рамил хәзрәтнең әнисе – архитектор, әтисе – бина-комплекслар төзү белән бәйле инженер. Хәзер алар икесе дә лаеклы ялда.

Рамил гарәп каллиграфиясе белән 1989–1990 елларда ук җитди кызыксынган. Гомумән, ул Көнчыгыш мәдәниятенә, башка телләрне өйрәнүгә мөкиббән. Шул елларда ук хәтта кытай телен дә өйрәнгән. 1993 елда Бөгелмәдәге төрек лицеена укырга кергән, гарәп теле укытучысы Хәсән Севиль аңа каллиграфия сәнгате юнәлешендәге белемнәрне бирә башлаган. Классик гарәп каллиграфиясенең бөтен ысулына иҗазәтне – дипломны (ә гарәп каллиграфиясендә әлеге ысуллар 12–13 төрдә) Рамил Насыйбуллов 1997 елда Истанбулда алган. Моннан тыш та аның Каманкари – Азия җәясе ясау сәнгате, абру һәм кануни орнаментация – тәзхиб (яки захрафа) буенча иҗазәтләре бар.

«Мин, каллиграфия һәм сугышчан көрәш төрләреннән кала, металл һәм агач эшкәртү ысулларын да өйрәндем. Шәрык милли киемнәрен ничек тегәргә кирәклегенә төшендем. Кайвакыт зәркәнчелек белән дә шөгыльләнәм. Китап ясау сәнгате – җилдчелек, моның белән мавыккач, сәхифәләрне тегү, тышлык ясау технологияләрен дә теләп өйрәндем, – ди әңгәмәдәшем. – Гыйльмуль-хатт – хәреф формаларының сыйфатларын өйрәнеп, аларны камил ясый белү гыйлеме. Аңа төшенү – гарәп графикасын тулысы белән белү дигән сүз түгел әле. Гарәп теле үз эченә 12 фәнне ала, каллиграфия исә шуларның берсен генә тәшкил итә. Бу сәнгать бар кеше өчен дә туры килми. Мәсәлән, «Ән-Намир әл-Мөхаттат» үзәгенә уку елы башында укырга ниятләгән утызлап кеше килсә дә, уку ахырында төркемдә бер-ике генә кеше калырга да бик мөмкин. Үзәк дүшәмбедән башлап җомга көнгәчә эшли. Укыту вакыты төштән соң. Теләге, иҗат потенциалы булган сабыр зыялылар безгә килә ала, укыту бушлай».


«Чит илләрдә каллиграфия – тулы бер фән, һәм ул мөселман сәнгатьләре арасында иң катлаулысы. Гарәп каллиграфиясе – башка төр сәнгатьләрем белән бергә бара торган бер юнәлеш, ягъни минем яшәешемнең бер өлеше генә... Шәхси күргәзмәм 2014 елда Колшәриф мәчетендә, Татар шәмаиле галереясында ачылган иде. Калган әсәрләрем даими рәвештә Казан Ислам университетында экспозицияләнә», – ди мөхтәрәм зат.

Искиткеч талантлы хәзрәтебез Рамил Насыйбуллов әле агачтан ую эшен дә яхшы белә! Бу сәләт аларның нәселендә дә бар. Шуңа күрә борынгы татар кураен яисә ситарны ясау, бизәкле агач җиһазлар иҗат итү аның өчен һич тә авыр түгел. Гаҗәеп хезмәтләрен Болгардагы «Ак мәчет»тә дә күреп куанабыз! Рамил Насыйбуллов эшләре «Ирек» мәчетен дә бизәп тора.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА









РАМИЛ НАСЫЙБУЛЛОВ





2023 ЕЛДА ДИНИ БӘЙРӘМНӘР

(һиҗри исәп буенча 1444–1445 еллар)

23 гыйнвар – Рәҗәб аеның беренче җомгасына каршы кич Рәгаиб кичәсе дип атала. Мөхәммәд пәйгамбәрнең әти-әнисе Габдуллаһ һәм Әминәнең бергә кушылуын искә алу кичәсе. Гомрә хаҗы – кече хаҗ да шушы айда кылына.

26, 27 гыйнвар – Рәгаиб кичәсе.

17–18 февраль – Мигъраҗ кичәсе. Мигъраҗ уразасы 100 көн ураза тотуга тиңләнә.

6–7 март – Бәраәт кичәсе, ягъни «ләйләтүл-Бәраәт». Бәхет, уңышлар, изгелекләр иңә торган изге көн. Һәркемнең ялварып сораган догаларын, үтенечләрен исәпкә алып, Аллаһы Тәгалә кешеләрнең язмышы турында карар кабул итә торган төн.

23 март – изге Рамазан-шәриф ае һәм ураза башланган көн. Коръән иңгән ай.

17–18 апрель – Кадер кичәсе. Кадер кичендә Аллаһы Тәгалә Мөхәммәдне пәйгамбәр итеп сайлаган. Кылган игелекләр мең ай эчендә кылынган яхшылыкларга караганда да хәерлерәк бу көндә. Кадер кичендә үтенеп сораган гөнаһлар гафу ителә, догалар кабул була.

21 апрель – Ураза гаете.

27 июнь – Гарәфә көне.

28 июнь – Корбан гаете. Ураза тәмамлангач, нәкъ 70 көннән соң башлана торган Корбан чалу бәйрәме. Фарыз намазларын укыганнан соң, Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен махсус догалар кылына.

19 июль – һиҗри ел буенча 1445 елның башы. Хәерләр бирелә, изге гамәлләр кылына торган ай. Аллаһы Тәгалә игелек кылучыларның гөнаһларын ярлыкар, савапларын арттырыр.

28 июль – Гашура бәйрәме. Мөнәҗәтләр әйтелә, күп итеп догалар кылына.

17 август – Сәфәр ае.

26–27 сентябрь – Мәүлид бәйрәме. Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с. г. в.) туган көне. Мәчетләрдә вәгазьләр укыла, хәер-сәдакалар таратыла.

Төзүчесе: хаҗи Абдулла ДУБИН.

Казанның Мәрҗани мәчете.
Фото: Мәликә Әсәтуллина.